«Юлдаш» китапханәсе

# ИСЛАМ ДИНЕ НИГЕЗЛӘРЕ

Тупланманы әзерләүче
һәм төзүчесе — **Фәрит Яхин**

КАЗАН
«РАННУР» НӘШРИЯТЫ
1997

Язылу индексы — **78713**

ББК 86.38
И 80
УДК 2

«Юлдаш» газетасының баш мөхәррире
**Ранис Газизов** редакциясендә

*ОСНОВЫ ИСЛАМА*
*Обычаи и нравы Ислама*

Редакторы **Рафис Газизов**
Рәссамы **Нәҗип Нәккаш**
Техник редакторы **Нурания Газизова**
Корректорлары **Фирая Гыймадова, Гөлсинә Төхфәтуллина**

Җыярга тапшырылды 1.06.97. Басарга кул куелды 17.12.97. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе № 1. 60 гр. «Тип-Таймс» гарнитурасы. Офсет басмада. Нәшер-хисап табагы 9. Заказ Н-330. Тиражы 50 000 данә.

«Раннур» нәшрияты. 420066, Казан, а/я 365.
Нәшрият эшчәнлегенә лицензия № 191 (19.06.97).

ТГЖН типографиясендә басылды, 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5-900049-02-7
© «Раннур» нәшрияты, 1997.

# Ислам диненең төп нигезләре бәяне




● Иман китерү ● Шәһадәт сүзләре ● Иманның тәфсилле аңлатмасы ● Китап, нәсел-нәсәп, кыйбла, мәзһәб мәсьәләләре ● Иманның дәлилләре ● Иманның сыйфатлары ● Шәригать дәлилләре ● Бишвакыт намазның тәртипләре ● Намазның шартлары ● Тәһарәт алу ● Госел сөннәтләре ● Хәйз мәсьәләсе ● Тәһарәтнең тәртипләре һәм догалары ● Кыйбла ● Ният ● Коръән уку ● Рөкүгъ ● Сәждә ● Намазның сөннәтләре вә әдәпләре ● Мәсҗид һәм җәмәгать ● Җомга намазы ● Җеназа намазы ● Гайд намазы ● Ураза ● Корбан чалу ● Зәкәт ● Хаҗ ●

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

* Бисмилләһир-рахмәнир-рахим *

# *Сүз башы*

*И мөэминнәр вә мөэминәләр, сез үзләрегезне изгелек юлында йөргән бәндәләрдән исәплисез һәм динегезнең Ислам дине булуы белән мактанасыз. Дөрес эшлисез. Моның өчен барчагызга Аллаһы тәгаләнең рәхмәтләре ирешсен һәм барчагызга да теләгәннәрегезне биреп, сөенеч иңдерсен вә шатлык белән яшәү юлларын күрсәтсен, Ахирәт көнендә Аның ярдәмен татырсыз, Сират күперен үткәндә хәвефтән коткарыр, җәннәтне бүләк итәр. Амин, шулай булсын!*

*Бу язма сез мөэминнәргә багышланды һәм «Хәл гыйлеме» дип аталды. Борынгылар телендәге «Гыйльме халь» дип йөртелгән гыйлем шушы була инде. Ул һәрбер мөселман карендәшебезгә белеп өйрәнергә һәм шуның нигезендә гамәл кылырга сабак бирә торган фән. Гыйлем, фән икән, димәк бу язма Ислам диненең бик нечкә вә катлаулы мәсьәләләренә дә төгәллек вә ачыклык кертер, бик күп сорауларга җавап бирер һәм дәлилләр китерер.*

*«Хәл гыйлеме»н яхшылап өйрәнмичә торып, үзеңне тулы мәгънәдә һәм камил мөселман дип әйтүе кыен. Димәк, бу фән Ислам диненә өйрәтә вә фарызларны белдерә. Дин юлы шундый да нечкә вә нәзек бер юлдыр,— бигрәк тә Ислам,— аз гына читкә чыктыңмы, чак кына ялгыштыңмы, кяферләр арасында калдым дип бел. Шушы четерекле вә тар юлдан адашмыйча барыр өчен күп белемнәр кирәк. Наданлык вә гафиллек бәндәне җаваптан азат итми. «Белмәдем бит»,— дип әйтү белән һичкемгә дә гафу ирешми. Ислам динендәге кешеләрнең наданлык белән акланырга хаклары юк. Шуның өчен дә алар мәгълүматлы һәм гыйлемле булулары ярдәмендә башкалардан өстен торырга бурычлылар. Коръән дә*

*мөэминнәр арасына шуның өчен китерелгән. Мөхәммәд пәйгамбәр дә шуның өчен тырышлыкларын куйган. Боларны һичбер вакыт онытырга ярамый.*

*Ислам диненә керү өчен күп нәрсә кирәк түгел. Моның өчен «Иман кәлимәсен», ягъни «кәлимәи шәһадәт»не белдерү дә җитә. Әмма хак мөселман саналу өчен бик күп гыйлем сорала. Бу гыйлемнәр Исламның бинасын тәшкил итәләр һәм «Биш фарыз» дип аталалар. Бу язма исә менә шушы хакта — Исламның бинасын төзүгә багышланган.*

*Ислам диненең бинасы биш фарыздан тора. Шуларның беренчесе — камил рәвештә иман китерү, икенчесе — һәр көндә биш вакытта биш тапкыр намаз уку, өченчесе — елга бер мәртәбә, рамазан аенда ураза тоту, аны «Рамазан уразасы» дип тә йөртәләр, һәм дә дүртенчесе — байлыгы булган һәрбер мөселманга елга бер мәртәбә малыннан мөэминнәр вә фәкыйрьләр файдасына зәкәт тапшыру, һәм дә бишенчесе — көче җиткән бәндәләргә гомерендә бер мәртәбә булса да хаҗга бару.*

*Фарыз — үтәлүе мәҗбүри булган эшләр. Аны бозсаң яки калдырсаң, син үзеңне тулы мәгънәдә камил мөселман дип атый алмыйсың, кяферлеккә чыгасың һәм бозыклык иясе исәпләнәсең. Шулай итеп, мөселман саналу өчен түбәндәгеләр таләп ителә.*

# *Иман китеру*

Беренче фарыз — *иман китеру,* дидек. Моны үтәгән кеше мөселманлыкка керә. Балигълык яшенә җиткән һәрбер мөселман баласы яки Ислам диненә килгән һәрбер бәндә шәһадәт кәлимәсеннән Мөхәммәд өммәте санала.

## ШӘҺАДӘТ СҮЗЛӘРЕ

Аны «иман кәлимәсе», «иман сүзләре», «шәһадәт кәлимәсе», «тугры юлга кайтарылу» һ. б. рәвешләрдә атап йөртәләр. Ул болардан гыйбарәт:

اَشْهَدُ اَنْ لَا اِلٰهَ اِلَّا اللّٰهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

*Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ*

Тәрҗемәсе: «Ышаныч белдерәм, чынлыкта Аллаһы тәгаләдән башка илаһи зат юк, шулай ук ышаныч белдерәм, чыннан да Мөхәммәд Аның колы һәм Аның рәсүле!»

Адәм балалары шушы сүзләр белән Исламга кереп, шушы сүзләрдән мөселман булалар. Әмма дә ләкин күңелең белән чын мәгънәдә ышаныч кормасаң һәм бу сүзләрнең асыл мәгънәсен тулысы белән белмәсәң, кяфер хәлендә кала бирәсең. Шунлыктан шәһадәт кәлимәсенең мәгънәсен яхшы итеп белү сорала.

## ИМАН КИТЕРҮ СҮЗЛӘРЕНЕҢ АЧЫК МӘГЪНӘСЕ

Кәлимәи шәһадәтнең беренче өлешендә Аллаһы тәгаләнең бердәнбер булуы хакында сүз бара:

أَشْهَدُ اَنْ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللهُ

*Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү*

Бу сүзләрне күңелдән болай дип белергә кирәк: «Мин телем белән әйтеп, күңелем белән ышанам, хакыйкатьтә бер Аллаһы тәгаләдән башка гыйбадәт кылынырга лаеклы һәм тиешле һичбер зат вә кем дә юк, барлык мәхлукатьне яраткан, ягъни бар иткән бөек Аллаһ бар һәм бер генә, иптәше дә, ярдәмчесе дә юк!»

Шушы сүзләр белән, ягъни иман кәлимәсенең беренче өлешендә бәндә Аллаһы тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, табына торган бердәнбер Зат булуына ышанычын белдерә, шул рәвештә Аллаһы тәгаләне тануын һәм бозык кешедән булмавын раслый

Кәлимәнең икенче өлешендә исә үзенең Мөхәммәд өммәтеннән, Ислам динендә икәнлеген раслый:

وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

*Вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ*

Бу сүзләрне күңелдән болай дип белергә кирәк: «Мин тагын да телем белән әйтеп, күңелем белән ышанам, Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам — Аллаһы тәгаләнең колы һәм бәндәләргә дин өйрәтү өчен җибәрелгән илчесе!»

Аллаһы тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, Мөхәммәднең пәйгамбәр булуына шик-шөбһә белдергән кеше мөселман түгел. Монда аз гына да шикләнү ярамый, юкса, аягың таеп китте дә, мөселманнар арасыннан кяферләр ягына тәгәрәдең дигән сүз.

Иман мәсьәләсенә багышланган нечкәлекләр вә тирәнтен гыйлемнәр моның белән генә бетми әле, аларны алга таба җентекләп өйрәнербез. Хәзергә Ислам бинасының төп нигезләрен тикшереп үтүне һәм танышуны дәвам итәргә кирәк табылды.

# КӘЛИМӘИ ШӘҺАДӘТКӘ ИНАНГАННАН СОҢ ТИЕШЛЕ ЭШЛӘР

Мөселманнар өчен Аллаһы тәгалә әмереннән дип, иман китерү белән беррәттән бишвакыт намаз уку, байлыгына карап зәкәт бирү һәм хаж кылу санала. Әгәр дә кем дә кем бу эшләрне Аллаһы тәгаләнең әмере дими һәм әмере булуына ышанмый, ул кеше кяфер исәпләнелә, хәтта иман китерсә дә хак мөселманнар санында йөртелергә тиеш түгел. Биш фарызны тотмау сәбәпле, үзен мөселманнардан санаса да, башка диннәрнең берсенә авышмыйча, ныклык сакласа да, ул кеше денсезлектә кала бирә. Шунлыктан биш фарыздан баш чөерү яки кайсын да булса берсен ташлау — бозыклык. Иман китерү, бишвакыт намаз, зәкәт бирү, хаж кылу — инанылып, чын күңелдән кылына торган күркәм эшләр булып тора. Күңелдән инанып, җаның белән теләп башкармаганда, фарыз, ягъни тиешле вә мәҗбүри булганлыклары өчен генә үтәлгәндә, андыйлар икейөзле, риялы дип аталып йөртеләләр һәм ялганчылардан исәпләнеләләр. Мондый хәлгә Аллаһы тәгаләнең ризалыгы юк, мондыйлар Хак тәгалә тарафыннан җавапка тартылмыйча калдырылмыйлар. Чын күңелдән тәүбә итеп, җан-тән белән фарызга бирелгәндә генә ул кемсәнәләрнең бәхетләре үзләренә кире кайтарылыр һәм Аллаһы тәгалә тарафыннан тәүбәләре кабул ителеп, авыр газаптан коткарылырлар.

Бәндәләр арасында шундый кешеләр бардыр, алар иман китерү, бишвакыт намазны уку, зәкәт бирү, хаж кылу кебек таләп ителә торган эшләрне фарыз дип белерләр, әмма боларның берсен дә эшләмәсләр яки кайсын башкарып та, бәгъзеләрен ташларлар. Ягъни, иман китереп тә, үзләрен мөселман санап та, яки бишвакыт намазны укымаслар, яки намазлы булып та, байлыкларының Аллаһы тәгаләдән булуын белмичә, белергә теләмичә, зәкәт (малның кырыктан бер өлешен мөселманнар һәм фәкыйрьләр файдасына тапшыру) бирмәсәләр, йә булмаса, мөмкин вакытларында көчләре җитеп, хаҗга бармый калсалар, яисә моны теләмәсәләр,

шулай итеп, фарызның яртысын үтәп тә калганнарын ташласалар, андый бәндәләрне «шәрган мөселман» дип атап йөртерләр. Шәрган мөселман дип әйткәндә сүз бу кемсәнәләрнең шәригать буенча, Ислам кануннарына нигезләнеп кенә мөселман булулары күздә тотылыр, әмма Аллаһы тәгалә каршында һәм дә Мөхәммәд пәйгамбәребез йөз нуры алдында алар хак мөселман, хак мөслим исәбендә йөрмәсләр. Бу сыйфатлары өчен әлбәттә Хак тәгалә каршында гаепле булырлар һәм җәзасыз калмаслар, чөнки алар Аллаһы тәгалә әмереннән йөз чөйгән, кайткан, буйсынмаган булып торырлар. Аллаһы тәгаләнең әмерен бозганнарның кайчан бәхетле булганнары бар? Фарызның тиешле икәнлегенә шик белдергән адәм баласы Аллаһы тәгаләнең әмерен бозган саналып, аның кальбе-күкрәгендә дә иман сакланмас. *Иман — төрле җәберләрдән вә уңышсызлыклардан саклаучы иң хикмәтле кәлимәләрнең берсе, аны югалттыңмы, мөселманлыктан чыгарсың, бәлагә вә казага юлыгырсың. Хак тәгалә сине онытыр, таянычың юкка чыгар.* Камил мөселман булу — иң зур бәхет. Аллаһы тәгалә менә шуның өчен дә бәндәләрне җир йөзенә яратты.

## ҖИР ЙӨЗЕНӘ АДӘМ НӘСЕЛЕНЕҢ КИЛҮЕ

Диндә «адәм нәселе» дип кешеләр хакында бәян итү гадәти һәм дөресрәк санала. Кеше дип әйткәндә мәхлукать, җан иясе күздә тотыла, башлангычның Аллаһы тәгаләдән булуы игътибардан читләштерелә.

«Адәм нәселе» дип әйтүдән төп сәбәп шунда ки, җир йөзендә яшәүче халыкларның нәсел башында Адәм галәйһис-сәлам тора. Аллаһы тәгалә хәзрәтләре кешеләрдән әүвәл башлап Адәмне туфрактан кодрәте белән бар кылды, аның сул як кабыргасыннан анабыз Хәува яратылды. Аны Адәм галәйһис-сәламнең хатыны итте. Бер-берсенә кадер күрсәтүләреннән соң балалары булды, алар

җир йөзенә таралдылар, аларның нәселләреннән халыклар барлыкка килде.

Элгәре, бар кылынганнан соң, Адәм атабыз белән анабыз Хәува җәннәттә яшәделәр. Аллаһы тәгалә аларны оҗмах җимешләреннән нигъмәтләндерде. Бары тик богдай агачыннан гына ашамаска боерды. Алар бәхетле иделәр. Һич кайгы-хәсрәт күрмәделәр. Акыллы итеп бар кылынганнар иде, әмма...

Аллаһы тәгалә барлык фәрештәләргә дә Адәм галәйһис-сәлам каршында сәҗдә итәргә боерды. Чөнки алар белән чагыштырганда, җирдән-туфрактан яратылуы сәбәпле, Адәм атабыз шактый зәгыйфь иде. Зәгыйфьләрне олылау һәм аларга хөрмәт күрсәтү шул вакытлардан бирле сөннәт саналды, шунлыктан барча диннәрдә дә мондый эш күркәм сыйфат булып тора һәм тиешле күрелә.

Фәрештәләр барчасы Адәм галәйһис-сәламгә сәҗдә иттеләр, бары тик шайтан ләгыйнь генә Хак тәгаләнең әмеренә буйсынмады. «Мин — уттан, ул — туфрактан яратылды, туфрак утка буйсыныр, ут туфракны яндырыр, туфрак асылы уттан өстен була алмас!» — дип тәкәбберлек күрсәтте, сәҗдәне кире какты, Адәмгә дошманлык итте.

Арабызда хак мөселманнар бар. Аларның күңелендә шик уяныр һәм аптырашта калырлар:

— Бу ничек инде тагын? Сәҗдә ителергә тиешле бердәнбер зат — Аллаһы тәгалә! Нигә фәрештәләр моны белмәделәр, шайтанның сәҗдә итмәве дөрес була түгелме соң? — диярләр.

Сүзләре — хак. Диннең иң нечкә җирләреннән берсе менә шушы да инде. Кемгә сәҗдә итәргә? Ханнар, солтаннар, падишаһлар, әмирләр алдында ничек инде бил бөкмисең? Әмма Аллаһы тәгалә каршында бу да икейөзлек, риялык булыр иде. Ялагайлар белән канәгатьлек иткән һәм шуннан үзләрен бәхетле санаган әмирләр вә солтаннар, падишаһлар вә ханнар, шәехләр вә муллалар, байлар вә идарәчеләр азмы яшәгәннәр җир йөзендә? Берсе дә калмаган. Барчасы киткән, илләрен, байлыкларын, хатыннарын, ялагайларын — барчасын үзләренә ияртеп алып киткәннәр. Мәңгелек һич-

нәрсә юк, Аллаһы тәгаләдән башка. Аллаһы тәгаләнең булуы сәбәбеннән үлемсезлек бары тик җәннәт тормышында һәм тәмугта гына. Шуның өчен дә һәммә бәндә үзенә җәннәт эзләр, тәмуг утының мәңгелек газабыннан качарга өйрәнсә генә моңа ирешә алыр, белсә иде.

Әйе, сәҗдә ителә торган зат — Аллаһы тәгалә. Бары тик шуны искәртергә кирәктер, хөрмәткә лаеклылар, ягъни зәгыйфьләр бар. Адәм галәйһиссәлам алдында сәҗдә итү фәрештәләргә Аллаһы тәгаләдән боерылды. Әмма бу сәҗдәнең рәвеше башкачарак иде. Бу сәҗдәдә маңгайны җиргә сөртү тиешле күрелмәде, бәлки олылау билгесе итеп баш кагу, бил бөгүдән генә гыйбарәт иде. Бәндәләрнең үзара баш кагып сәламләшкәнендәгечә. Бу сәҗдә асылда Адәм галәйһис-сәламгә бил бөгү аша Аллаһы тәгаләне олылау, аның кодрәтенә рәхмәт билгесе иде. Ягъни мөселманнар Кәгъбә тарафына карап сәҗдә итәрләр, Кәгъбәгә хөрмәтләрен күрсәтерләр, әмма бу эшнең асылы Кәгъбә аша Аллаһы тәгаләне олылау, Аңа сәҗдә итү. Адәм атабыз каршында фәрештәләрнең сәҗдәсе дә менә шушындый сыйфатта иде, эчтәлеге менә шуннан гыйбарәт булды. Әмма ни акыллы фәрештә-мәләкләрнең хәлфәсе шайтан, — ул вакыттагы исеме Газазил иде, — моның шулай булуын аңламады. Бу исә үз акылына гына ышанган бәндәләрнең дә нинди аяныч хәлләргә төшәргә мөмкинлекләре хакында сөйли, мәгәр Хак тәгалә әмереннән чыксалар.

Атабыз Адәм белән анабыз Хәува да аяныч хәлгә калганнар, чөнки шайтан ләгыйньнең аларга яманлык теләвен исләренә дә алмаганнар, хәтерләрен кыска тотканнар, Ходай тәгаләнең әмереннән чыкканнар.

Шайтан үзенең җәннәтле булмавыннан гаепле итеп бары тик Адәм галәйһис-сәламне санаган һәм, җаен табып, үзенең мәкерле эшен башкарган, богдай агачының җимеше мәңге үлемсез итә дигән ялган белән нәфселәрендә уйнап, барсын да белеп торучы һәм күрүче Аллаһы тәгаләнең әмерен боздыругаирешкән. Богдай агачының җимешен ашау-

лары сәбәпле Адәм галәйһис-сәлам белән анабыз Хәува хәзрәтләре җәннәттән җиргә куылганнар, шайтан ләгыйнь мәңгегә Хак тәгаләнең рәхмәтеннән өлешсез калган.

Аңлы мөэминнәр сорарлар:

— Барсын да күреп торучы һәм белүче булгач, Хак тәгалә ни өчен Адәм белән Хәуваны бу ялгышлыктан саклап калмаган соң? — дип.

Дөрес сорау, диннең иң нечкә мәсьәләләрен кузгата торган сорауларның берсе. Шикләрдән азат булырга кирәк. Әмма моның сәбәбе шуннан булыр: бәндәләр фигыльләрен үз ниятләре белән башкарырлар, Аллаһы тәгалә алдан ук бозыклыклардан сакланырга кирәклеген пәйгамбәрләре аша, — Адәм мәсьәләсенә килгәндә, аның турыдан-туры үзенә, — белдереп куяр, ягъни тәкъдирнең алдан билгеләнүен (яман кешенең утка керәчәген, яхшының җәннәтле булачагын хәбәр иткән кебек) һәркем өчен җиткерер, әмма фигыльләренә катышмас. Халык арасындагы хикмәтле сүз: «Аллага таян, үзеңә ышан!» — дигәннәре моның ачык дәлиле булып тора.

Аллаһы тәгалә атабыз Адәм белән анабыз Хәувага да, богдай агачының җимешен ашасалар, җәннәттән куылачакларын алдан ук белдереп куйды, әмма фигыльләренә катышмады. Алар әмерне боздылар һәм җиргә төшерелделәр. Тәкъдир хәл ителде, тыелган эш аяк астында калды.

Ни өчен богдай җимешен ашарга ярамады соң?

Бөтен эш шунда ки, бу агач җенесне уята иде. Кайчан Адәм белән Хәува аның җимешен каптылар, җенесләре уянды, күлмәкләре күтәрелде, тәннәре шәрә калды, берсе — ирлек, икенчесе — хатынлык сыйфатына керделәр. Ялангач калулары аркасында бер-берсеннән һәм җәннәтнең башка җан ияләреннән оялдылар, яфрак капладылар.

Өммәтләр сорарлар, шиккә төшүләрендә хәвеф күренер, игътибарсыз калдыру савап саналмаганлыктан, аңа да җавап бирергә кирәктер. Бу да диннең нечкә җирләреннән:

— Әгәр дә богдай җимешен ашамаган булсалар, атабыз Адәм белән анабыз Хәува җәннәттән кайчан да булса чыгарылачаклар идеме?

— Юк, мәңге шунда калыр иделәр, чөнки Аллаһы тәгалә һичкемне җәберләми, гөнаһсызны җәзаламый! Ул — мәрхәмәт иясе!

Адәм атабыз Сәрәндип утравына, анабыз Хәува Җиддә тавына төшерелде, аларның шулай бер-берсеннән ерак яшәүләре исә оятлы булулары аркасында иде. Аларга Хак тәгалә тәүбә мөмкинчелеген бирде, каннар агызып, күз яшьләре белән гафу үтенделәр. Мәрхәмәт иясе аларга миһербан итте, гафу ирешеп, Адәм белән Хәува бер-берсен таптылар, очраштылар. Гафу ителүләре билгесе итеп аларга Хак тәгалә балалар бирде. Адәм галәйһиссәламгә беренче китап — Хак тәгалә китабы иңде, ул пәйгамбәр булды. Хак тәгаләнең китабында ялгыштан сакланырга һәм тугры юлда йөрергә өйрәтелгән иде.

Җиргә адәм аягы менә шулай басты. Балалары ишәйделәр. Җәбраил фәрештә аша Аллаһы тәгалә адәм балалары арасыннан берәрсенә пәйгамбәрлек иңдереп, һаман-һаман алар хакында кайгыртып торды, яхшылыкка өйрәтте. Бу гомерләр эчендә йөзләрчә пәйгамбәрләр килеп, халыкларга күпме тапкырлар яхшылык эшләделәр. Әмма акыллар кыска, күңелләр тарлыгы сәбәпле, бәндәләр, нәфес колына әверелеп, бозыла бирделәр. Барлык газаплар да шул бозыклыклар аркасында өстебезгә йөк булып өелде. Җир йөзендә иң соңгы пәйгамбәр — Мөхәммәд галәйһис-сәлам, иң соңгы дин һәм хакыйкый дин — Ислам дине. Моннан соң башка пәйгамбәрләр китерелмәс. Аның дәлиле Коръәндәдер:

مَا كَانَ مُحَمَّدٌ اَبَا اَحَدٍ مِنْ رِجَالِكُمْ وَلَكِنْ
رَسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ وَ النَّبِيِّنَ ❁

*Макәнә Мөхәммәдүн әнә әхәдин мин рижәликүм вә ләкин рәсүләл-лаһә вә хатәмә вән-нәбиинне*

Мәгънәсе: «Мөхәммәд пәйгамбәр сезнең ирләрегездән берсенең дә атасы булмады, бәлки Ал-

лаһы тәгаләнең пәйгамбәре һәм пәйгамбәрләренең ахыргысы булды!»

## ИМАННЫҢ ТӘФСИЛЛЕ АҢЛАТМАЛАРЫ

Аллаһы тәгаләгә вә пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәламгә иман китерү белән бәндә мөселман булса да, иман китерүнең ни-нәрсә икәнлеген төшенеп җитмәсә һәм тәфсил мәгънәләрен күңеленә беркетмичә калса, ул әле өммәтләргә фарыз кадәрле белем иясе һәм динендә ныклы дип карала алмый. Дөньялыкта вә Ахирәт көнендә иман гыйлеме барча мөселманнар өчен дә даими рәвештә кирәкле булып, без бу урында иман нигезләрен тәфсилле рәвештә аңлатып бирергә һәм дивар ташларын «сүтеп» күрсәтергә кирәкле дип таптык. Болар — иман бинасын тәшкил итүче асылташлар!

*Беренче асылташ:* И бәндә, синең Раббың, ягъни Тәңрең, Ияң кем? Син аны белерсеңме?

Бу сорау ишетелгәндә яисә күңелеңне борчыганда, и мөселманлыкка дәгъва кылучы зат, белеп тор:

— Синең Раббың, ягъни Тәңрең, Ияң — Аллаһы тәгалә!

Раббың кем дип сорадылар икән, болай дип җавап бир:

— Раббым — барча галәмнәрне бар кылган, ягъни яраткан Бөек Аллаһы тәгалә, аннан башка Тәңрем дә, Иям дә булмас. Бары Ул гына минем таянычым һәм яхшы-яманнан сыендыручым. Әгәр дә Ул юк икән, ул вакытта мин дә, барча галәмнәр дә, хайваннар да, күзгә күренгән һәм күренмәгән барча әйберләр дә — берсе дә булмас иделәр. Без бар, чөнки безне Раббыбыз Хак тәгалә яратты. Шуның өчен дә Ул безнең Иябез, шуның өчен дә Ул безнең Тәңребез. Без аның колларыдыр!

Син менә шушы рәвештә җавап бирә алсаң, хуш вә күркәм булыр. Әмма дә ләкин моның белән генә канәгать итмәүчеләр тыелып тора белмәсләр, сорарлар:

— И бәндә, моңа дәлилең нәрсә? — дип.
*Әстәгыйзү билләһи* — диген, «Аллаһы тәгаләгә сыенам!» — диген һәм иң элек болай дип белдер:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۝

*Әл-хәмдү лиллаһи раббил-галәмин* — дип.
Мәгънәсе: «Барча хөрмәт вә данлауларыбыз Аллаһы тәгаләгә генә, ул Хак тәгалә барча галәмнәрне тәрбия кылучы!» Аннан соң:

وَاِلٰهُكُمْ اِلٰهٌ وَاحِدٌ لَا اِلٰهَ اِلَّا هُوَ الرَّحْمٰنُ الرَّحِيمُ ۝

*Вәләһүкүм иләһүн вахидүн лә иләһә иллә һуар-рахмәнүр-рахим* — дип әйт.
Мәгънәсе: «Сезнең аллагыз бер Аллаһы тәгалә генә, Аллаһыдан башка Аллаһ юк, бары тик бер Аллаһы тәгалә генә барчаларга рәхим-шәфкатен китерүче һәм Ахирәттә мөэминнәргә боларны бирүче!»
Син менә шушы ике дәлилне китерерсең вә аларның изге сүзләр, Аллаһы тәгаләнең Коръәненнән икәнлеген белеп торырсың. Хак тәгаләнең сүзенә һичкем каршы чыга алмас, мәгәр каршы чыкты исә, үзенә бәддога вә золым ирешер, зәхмәтеннән котыла алмас.
*Икенче асылташ:* Бәндәләрнең иң әүвәл беренче белергә тиешле гыйлеме — Аллаһы тәгалә булды. Аның барлыгын һәр мөселман да таныр. Әмма кайсы да булса берәрсе Аллаһы тәгалә янында икенче бер илаһи зат барлыгын дәгъва кылса, кяфергә чыгар. Шунлыктан иң саф вә пакь, хилафсыз дин хак мөселманнарда булыр. Бу сәбәптән икенче сорау — динең хакында белешүдер. Әйтерләр:
— Аллаһы тәгаләне таныдың, әмма динең нинди дин?
Җавап бир, әгәр дә син мөселман икәнсең:
— Динем — Ислам дине!

Шушы сүзләрең ирешүгә, Коръәннән дәлил өчен берәр аять сорарлар, җавап бирерсең:

إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ ٱللَّهِ ٱلْإِسْلَامُ ۞

*Иннәд-динә гыйндәл-ләһүл-ислам* — дип.

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгалә каршында хак булган дин — Ислам дине!»

Мәгәр диндә гыйлем эзләүче кеше булсын, иманга килүче бәндә булсын, яки бер сораучы булсын, яисә күңелендәге шиген юучы булсын, барыбер, шушы сораудан соң иман бинасының *өченче асылташына* җитәр, тыелмас, сорар. Ул асылташның нуры моннан соң ачылыр:

— Раббың — Аллаһ, динең — Ислам, ә пәйгамбәрең кем?

— Пәйгамбәрем — хәзрәте Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам,— диген.

Хәзрәт дип әйткәндә аның өммәтләргә Аллаһы тәгаләнең гыйлемнәрен өйрәтүеннән, Коръәнне сөйләп бирүеннән, Мостафа дигәндә Аллаһы тәгаләнең сөеклесе һәм соңгы пәйгамбәре булуыннан, салаллаһу галәйһи вәссәлам дигәнебездә аңа атап Аллаһы тәгаләдән ярлыкау вәссәламнәр ирешүне үтенүебездән икәнне күңеленә сеңдер, пәйгамбәребезне телгә алганда шушы сүзләрне әйтүне гадәт ит, үзең дә сөекле вә рәхмәт иясе булырсың.

Пәйгамбәрең хәзрәте Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам икәнлекне Коръән сүзе белән дәлилләр:

مُحَمَّدٌ رَسُولُ ٱللَّهِ ۞

*Мөхәммәдәр-рәсүлүл-лаһ*

Мәгънәсе: «Мөхәммәд галәйһис-сәлам Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре!»

*Дүртенче асылташ:* Алга таба сине борчыган сорау бу булыр:

— Синең өммәтең кемнең өммәте соң?

Җавабы болайдыр:

— Мин — Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәламнең өммәтеннәнмен!

— Моңа дәлилең нәрсә?

— Моңа дәлилем Коръәне-кәримнең аятендәдер:

كُنْتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ*

*Күнтүм хәйрә өммәтин ухриҗәт лин-наси таэмурунә бил-мәгъруфи вә тәнһүнә ганил-мөнкәри вә түэминүнә билләһ*

М ә г ъ н ә с е: «И Мөхәммәд өммәте, сез башка өммәтләрдән хәерлесе булдыгыз, хәзрәте Адәм галәйһис-сәламнән соң бу вакытка кадәр яшәгән барча өммәтләрдән хәерлерәк һәм артыграк булдыгыз, яхшылыкка өндәп, бозыклыктан тыелып берберегезгә нәсыйхәтләр вә изгелек тарафына дәлилләр сөйләрсез, көферлектән — Аллаһы тәгаләгә берәүне шәрик-тиңдәш итүдән — сакланырсыз, һәм дә Аллаһы тәгаләгә иман китереп, шул иман белән торырсыз, шуның өчен дә өммәтләрнең изгесе сез булдыгыз!»

*Хәбәр.* Дини билгеләмә буенча, өммәтне күрсәткәндә, кайсы пәйгамбәрнең хаклык юлына керүең хакында сүз бара. Димәк, өммәтнең нигезе — дин; тел дә, нәсел-нәсәп тә түгел. Боларны истән чыгарырга ярамый. Шуның өчен дә, кайсы өммәттән, дигәндә, Мөхәммәд пәйгамбәр өммәтеннән дип күңелгә сеңдерергә һәм җавап бирә белергә кирәк.

«Ә кайсы милләттән син?» — дигәндә ничек җавап бирә белергә кирәк? Милләт белән өммәт бер түгел мени?

*Бишенче асылташ:* Мәгәр синнән кайсы милләт булуың хакында белешсәләр, иманың камил икән, ул вакытта:

— Милләтем — Ислам милләте, милләтем — Рәсүлуллаһ милләте! — диярсең, хата булмас, дәлилең шушы булыр:

مِلَّتَ اَبِيكُمْ اِبْرَاهِيمَ هُوَ سَمَّاكُمُ الْمُسْلِمِينَ مِنْ قَبْلُ وَفِى هَذَا *

*Милләтә әбикүм Ибраһима һуа сәммакүмүл-мөслиминә мин каблү вә фи һәза*

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгалә сезнең динегездә киңлек бирде, атагыз Ибраһим галәйһис-сәлам милләтенә биргән киңлек шикелле итеп, Аллаһы тәгалә сезне Коръәннән әүвәл күндерелгән китапларында вә шушы Коръәндә мөслимин (мөселманнар) дип белдерде!»

И мөселман карендәшем, бу хәбәрләрне күңеленә салып һәм аларга хакыйкый рәвештә ышанып, сиңа бирелгән сораулар алдында югалып калмассың һәм ошбу дәлилләр белән Раббың, динең, пәйгамбәрең, өммәтең вә милләтең хакында белдерә алырсың.

## КИТАП МӘСЬӘЛӘСЕ

*Алтынчы асылташ:* Җир йөзенә бәндәләрнең бәхете өчен Аллаһы тәгалә һәртөрле пәйгамбәрләрен китерде һәм аларга Китаплар бирде. Шул Китапларга таянып, хак бәндәләр эш-гамәл кылдылар һәм Аллаһы тәгаләнең рәхим-шәфкатенә ирештеләр, бөтенесе бер карендәш халык булып яшәделәр. Аларның һәрберсе пәйгамбәрләре китергән Китапны белделәр.

Син дә белерсеңме? Сорарлар:

— Китабың кайсы китап? Кайсы һәм кем пәйгамбәргә иңдерелгән китап, белерсеңме? — дип.

Җавабың шушы булыр:

— Китабым — бөек Коръән, Аллаһы тәгаләнең хәбәре рәвешендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламгә иңдерелгән!

— Дәлилең нәрсә?

— Дәлилемдә Аллаһы тәгаләнең бары үзенә генә сыенам һәм бөек Коръәнне исемә алам:

ذَٰلِكَ ٱلْكِتَٰبُ لَا رَيْبَ فِيهِ *

*Зәликәл-китабү лә рәйбә фиһ*

Мәгънәсе: «Бу китап — камил, аның Аллаһы тәгаләдән булуына шик юк!»

Аллаһы тәгаләнең әмере белән Җәбраил фәрештә, күркәм адәм сурәтенә кереп, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламгә авыздан Коръәне-кәримне укыды һәм белдерде. Ә Мөхәммәд пәйгамбәребез исә, үз чиратында, боларны өммәтләргә сөйләде һәм язучыларына әйтеп яздырды. Шул рәвешле Коръәне-кәрим аяте-аяте, сүрәсе-сүрәсе белән егерме өч ел дәвамында тәмамына кадәр иңдерелде.

Пәйгамбәребезнең изге яраннарыннан булган хәзрәте Госман, Аллаһы тәгаләнең аңарга ризалыгы булсын, Коръәне-кәримне бүген кулыбызда тоткан рәвешкә китереп тәртип итте. Шуның белән Хак тәгалә вә сөекле рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәлам рухы каршында олуг эшне башкарды. Моңа кадәр китерелгән пәйгамбәрнең китаплары, Мусамы, Гайсәме, башканыкымы, аларны хәзрәте Госман шикелле камил рәвешендә тәртип итүчесе булмаганлыктан, һәртөрле ялгышлар белән тулган иде, аерым урыннарына илаһи сүздән гайре хәбәрләр кертелгән иде. Ә Коръәне-кәрим исә бу җәбердән Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән, Госман сәхабә тырышлыгында котылып вә коткарылып калынды. Рәхмәтебез чиксез булсын!

Коръәне-кәримдә нәрсәләр хакында язылган соң?

Анда Аллаһы тәгаләнең боерган һәм тыйган эш-гамәлләре хакында, пәйгамбәрләрнең хәлләре, дин, гыйбадәт, ул гыйбадәтләрнең дөрес һәм бозыклары, җәннәт вә җәһәннәм, савап вә газап, дөнья һәм Ахирәттә котылу яки һәлак булу юллары турында һәм дә шулай ук үткәндә күрелгән тарихлар һәм киләчәктә бәндәләр башына төшәчәк хәлләр барчасы да, Коръәннең Кыяматкәчә өстен булачагы һәммәсе дә бәян ителгән. Кешелек алга

барган һәм тәрәккыят юлы күтәрелгән саен Коръәннең дөреслеге һәм хөкемнәренең хаклыгы бәндәләр күзенә ачыграк күренә бара. Аерым бер хәбәрләре бүген ачыкланылса, башкалары иртәгәге көндә билгеле була бара. Шунлыктан, бүген «бу өлеше ялган» дип дәлил китерүчеләр иртәгә ялганчыга чыга, дәлиле көчен югалта. Коръән — изге Китап, аның хакында бәхәсләр вә сүз куертулар урынсыз булыр.

## НӘСЕЛ-НӘСӘП МӘСЬӘЛӘСЕ

*Җиденче асылташ:* Җир йөзендә яшәгән һәм яшәүче барча кешеләрнең ата вә анасы булыр, алар шуларның балалары торырлар. Шулай ук кошлар һәм хайваннар да яшәр. Бөҗәкләр, балыклар һ. б. шуның кебек җан ияләре белән Җир йөзе тулып торыр. Боларның барчасы да күзләребез белән күреп беленерләр, әмма дә җеннәр һәм башка күзгә күренмәүче затлар да бардыр.

Иманда соралыр:

— Син кем нәселеннән? — диеп, ягъни кемнең балаларыннан булырсың.

Бәндәләр өчен үзенең җиде буын бабасын белү хәерлерәк күренер һәм сөннәт саналыр. Үз нәселен һәм бабаларын белмәүчеләр исә мәгънәсезләрдән саналырлар, хөрмәтсез күрелерләр.

— Син кем нәселеннән? — дип сораган вакытта хак мөселман бәндәсе:

— Мин атабыз Адәм галәйһис-сәлам нәселеннән булырмын, — дип җавап бирер.

— Моңа дәлилең бармы? — диярләр.

— Бар, — дияр бәндә, — моңа дәлилем Аллаһы тәгалә сүзе булган Коръәндә язылган! Хак тәгаләгә сыенып әйтәмен ки:

وَاِذْ اَخَذَ رَبُّكَ مِنْ بَنِىٓ اٰدَمَ مِنْ ظُهُورِهِمْ ذُرِّيَّتَهُمْ

وَاَشْهَدَهُمْ عَلٰى اَنْفُسِهِمْ اَلَسْتُ بِرَبِّكُمْ قَالُوا بَلٰى ۞

*Вә из әхәзә раббүкә мин бәни Адәмә мин зуһуриһим зөрриййәтәһүм вә әшһәдәһүм галә әнфүсиһим әләстү би раббикүм калү бәлә*

Мәгънәсе: «Шул вакытта Аллаһы тәгалә Адәм галәйһис-сәламнең теләге аркасында балаларының аталары булу сәбәпле дөньяга туу тәртибен белдерде һәм иҗат итте, бер-берләренә шаһит итте, Адәм галәйһис-сәлам әйтте, әмма мин сезнең Раббыгыз түгел, диде, алар «әйе» диделәр!»

## КЫЙБЛА МӘСЬӘЛӘСЕ

*Сигезенче асылташ:* Һәрбер мөселман Кыйбланың кайсы тарафта икәнлеген белергә тиешле. Ул кайда гына булмасын, әйтик, Җирнең көнбатыш тарафына китәме, бәлки, көнчыгышынамы, көньягына яки төньягынамы, Кыйбла Согуд Гарәбстанындагы Мәккә шәһәрендә Кәгъбә булыр, моңа дәлил бар:

فَوَلِّ وَجْهَكَ شَطْرَ ٱلْمَسْجِدِ ٱلْحَرَامِ

*Фәвәлли вәҗһәкә шатрал-мәсҗидил-харам*

Мәгънәсе: «Кайчан намаз кылсаң, йөзеңне Харам мәсҗиде тарафына юнәлдер!»

## МӘЗҺӘБ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Тугызынчы асылташ:* Мөселманнар белергә тиешле мәзһәбләр бардыр. Бу дин юлының күрсәткечләре булып тора, мәзһәбләрне Ислам дине өчен тырышучы галимнәр тәртип иткәннәр һәм һәрбер бәндә өчен камил дәрәҗәдә аңлашылырлык итеп белдерелгәннәр. Мәзһәб үзе ике төрле була.

Беренчесе, Аллаһы тәгаләнең берлегенә, сыйфатларына, фигълиятенә, пәйгамбәрләренә, фәрештәләренә һ. б. шуның кебек иман китереп инануыбызны белдергән һәммәләрне аңлатып биргән юл — мәзһәбнең әүвәлгесе булыр, ягъни мөселманлыкка керү юлын күрсәтер.

Икенчесе, Аллаһы тәгаләгә ничек вә ни рәвешле гыйбадәт итәргә кирәк, дөньялыкта нинди гамәлләр кылуың яхшырак һәм нинди эшләрең яманрак вә дөрес түгел, шуларны сөйләүче мәзһәб.

Беренчесен «Дин вә игътикад мәзһәбе» дип, икенчесен «Гамәл вә гыйбадәт мәзһәбе» дип атап йөртерләр. Мөселманнар шушы юллар аша дингә килгәндә аяклары таюдан вә ялгышлардан сакланып калырлар һәм туры юл белән дингә ирешерләр.

Мәзһәбләрне мөҗтәһидләр, ягъни дин өчен тырышучы галимнәр күрсәтте, дидек. Алар үзләре ялгышмадылармы соң? Юк, ялгышмадылар, чөнки Коръән вә хәдисләрдән чыгып алар бу юлларны төзеделәр һәм хаклык өчен гыйлемнәрен вә тырышлыкларын кызганмадылар. Ул галимнәр Мөхәммәд пәйгамбәребезнең якын дуслары, теләктәшләре, ягъни сәхабәләре һәм дә имам Әгъзам, имам Малик, имам Шафигый, имам Әхмәт Ханбали, имам Мөхәммәт, имам Әбу-Йосыф, имам Әбу-Мансур, имам Әбул-Хәсән һәм башка шушындый олуг дәрәҗә иясе затлардыр. Аларның сүзләре Коръән вә хәдисләр белән үлчәнеп, Аллаһы тәгалә алдында хак булды, әмма белдергән хөкемнәрендә бәндәләрдән игътикад, ягъни күңел салу, таләп ителде.

Күрсәткән гыйлемнәре хак булды исә, нигә ул вакытта бәндәләрдән игътикад-күңел кую соралды соң? Моңа аңлатма бирү өчен шактый күп мәгълүмат таләп ителә. Бу урында кыскача гына аңлатып үтәрбез.

Мөҗтәһидләр арасында кайбер мәсьәләләргә кагылышлы аерымлыклар булса да, аларны үзара бәхәсле дип тикшермәделәр. Аларның бәяннәрендә вә хәбәрләрендә аермалыклар хөкемнәрне төрле яктан тикшереп карау аркасында гына булды. Шунлыктан, һәрбер мөселман кайсы галимнең сүзен дөрес дип табып, шул хөкемнәргә буйсынды, игътикад куйды исә, ул ялгышмас. Шуңа күрә дә игътикад мәзһәбең хакында сорасалар: «Әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбе минем игътикадым мәзһәбе!» — дип белдерсәң, дөрес булыр.

Асылда галимнәр дин юлында икегә бүленеп каралалар һәм аларның беренчесе — Әбу-Мансур Матриди хәзрәтләре тарафыннан төзелгән мәзһәб, икенчесе — Әбул-Хәсән Әл-Әшгари хәзрәтләренекедер. Калган мөҗтәһидләр аларның гыйлем нуры белән сугарылып, артларыннан килерләр. Хәнифиләр исә Әбу Мансур юлындадыр, Шафигый, Малики, Ханбали — болар Әбул-Хәсән укучыларыдыр. Әһлегә исә боларның арасындагы аермалыкларны бәхәс итмичә, мәзһәбләренә күңел баглап гамәл кылуны киңәш итәрбез, калганы — казыйлар вә мөфтиләр эше.

Болардан тыш, гамәл һәм гыйбадәттә тагын да дүрт төрле мәзһәб бар. Беренчесе имам Әгъзам мәзһәбе, икенчесе имам Малик мәзһәбе, өченчесе имам Шафигый мәзһәбе, дүртенчесе имам Әхмәт Ханбалиныкы. Аларның юлын тоту шулай ук әһле сөннәт эше һәм җәмәгать фигыле санала. Өйрәтмә итеп китерелгән иман, намаз, рузә (ураза), хаҗ, зәкәт бирү һәм башкалар барчасы да дөрес, боларга нигезләнеп эш йөртү хакыйкатькә туры килә вә хак бәндәләргә фарыз күрелә. Әмма дә ләкин гыйбадәтнең кайбер нечкә мәсьәләләрендә һәм күрсәтмәләрендә бераз аермалыклары бар. Бары тик бу аермаларны мөселманнар «ялгыш» дип уйлаудан саклансыннар иде, чөнки ул ихтилафлар һич тә хата түгел, бәлки Аллаһы тәгаләнең бәндәләргә тапшырган рәхмәте билгесе генә. Шушы нәзек мәсьәләне аңлауда күңел сабырлыгы һәм дә кальбнең сафлыгы таләп ителер. Ул аерымлыкларның Хак тәгаләдән рәхмәт булуы шунда ки, боларны Аллаһыбыз гафу итте һәм дин юлын күрсәтүдәге тырышлыклары өчен һәм дә мөселманнарның туры юлга шушы юнәлеш белән барып ирешүләре сәбәбендә бу галимнәрнең өйрәтмәләренә рәхмәтле булды. Шушы юлга кергән барчалар, аларның гыйлем юлын тотып барулары өчен шулай ук сөекле булдылар. Наданнар гына моның хаклыгын аңламаслар, күңелләре хакыйкать юлында тырышлык табучылар исә бу хәбәрләр белән сөенерләр һәм дөреслеккә ирешерләр. Шуңа күрә һәркем өчен, әгәр дә ул үзен хак мөселман саный икән, кайсы

гына мәзһәбтә булмасын, минем юлым дөрес дип белсен, башкаларның мәзһәбенә кырын күз белән карамасын һәм гамәл вә гыйбадәттә үзләренең имамнары күрсәткән юл белән барсын, итәгеннән кулын ычкындырмасын. Менә шул булыр игътикад, менә шул булыр дөрес эш вә Аллаһы тәгаләгә лаеклы күрелгән гамәл.

И мөэмин, мәгәр син имам Әгъзам мәзһәбен сайлагансың икән, имамыңның юлында биленне кысып бәйлә, бер эшендә бер имамның, ягъни бер мәзһәбнең өйрәтмәсен, икенчесендә икенче бер имамның, ягъни мәзһәбнең өйрәтмәсен тотма. Сайлагансың икән, бер юлдан гына бар. Берсеннән икенчесенә күчеп йөрү бер дә килешмәс һәм синең күңел сафлыгың юк икәнлекне күрсәтер. Сак бул! Кем дә кем имамының итәген ычкындырды икән, юл адашыр. Бу юл адашучылар исә тәмугка юнәлерләр, Аллаһы тәгаләгә сыенабыз, Аллаһы сакласын!

## ИМАНГА ИРЕШҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Унынчы асылташ:* Әбул-Хәсән Әл-Әшгари хәзрәтләре өйрәтмәләре буенча бәндәләргә иман китерү акылы җитлеккән һәм балигъльк яшенә җиткән кешеләр өчен генә фарыз санала, әмма имам Әбу-Мансур Матриди белдерүенчә, иман китерү өчен балигълыкка ирешү һәм акыл җитлегү дәрәҗәсенә килеп җиту тиешле саналмый, адәм баласы моңа кадәрле үк иман китерә ала. Шулай булса да, балигъ булуга иманын яңарту яхшыга юрала.

Адәм баласының акылы җитлекте дип әйткән вакытта аның файда белән зыянны аера башлавыннан карап билгелиләр. Әгәр дә бала әлегә ул дәрәҗәдә түгел икән, ул вакытта аның акылы яшь була, шунлыктан андыйларны гөнаһсыз сабый дип йөртәләр, ата-аналары яхшыдан яманны һәрдаим аеру юлларын аңлатып торалар. Кайбер балалар бик тә зиһенле булып, яхшыдан яманны тиз аера башларлар, ә кайберләре исә моңа акрынлык белән ирешер. Шунлыктан ашыктыру дөрес булмас, тәр-

бия чараларын камилләштерү яхшырактыр. Акыл дәрәҗәсе камил бала балигълыкка иреште исә, ягъни ир яки хатын була алырлык исә (ир бала икән, төшләнсә һәм ирлек җенесе үзен сиздерсә, кыз бала икән, күрем (хәйз) күрә башласа), ул вакытта ул иман китерер. Мәгәр акыл дәрәҗәсе камил балада бу сыйфатлар күренмәсә, ул унбиш яшеннән балигъ саналыр. Әмма күпчелектә, кыз балалар тугыздан кимдә балигъ булмас, ир балалар унике яшеннән кимдә балигъ саналмас. Һәрхәлдә алар үзләренең балигъ икәнлекләрен үзләре әйтерләр. Шунлыктан мөселманнар үз балаларының дөрес сөйләшүен һәм кальбләре пакь булуын теләсәләр, аларга ышансыннар вә ялганга юл калдырмасыннар.

И мөселман карендәшем, бел, иман белән Ислам дине икесе дә бердер, иманың юк икән, син Ислам динендә түгел, кяфер, иманың бар икән, син мөселман. Ә мөселман дип әйткән вакытта Ислам динендәге бәндә дигән төшенчә белдерелә. Инде дә мөселман дип берәүне атаганбыз һәм шулай дип белгәнбез икән, аңа мөэмин дип әйтү дә дөрес. Әмма иман мөфтигә дә, имамга да, муллага да китерелмәс, бәлки Аллаһы тәгалә һәм дә рәсүле Мөхәммәд галәйһис-сәламгәдер.

## ШӘРИГАТЬ ТАЛӘПЛӘРЕ БУЕНЧА ИМАННЫҢ ШАРТЛАРЫ

*Унберенче асылташ:* Бер адәм иман китерсә, аның шарты шул булыр, ул күңеле белән инанып, теле белән нәрсә әйткәнен ачык итеп аңлап әйтсен. Теле сөйләгәнен күңеле белмәсә яки шик-шөбһәсе булса, аның иманы дөрес булмас һәм дә ул иманлы саналмас. Шушы ике таләпнең беренчесе дип күрсәтелгән тел белән әйтүне Ислам динендә:

إِقْرَارٌ بِاللِّسَانِ ❁ *икърар бил-лисани*

һәм икенчесе дип белдерелгән күңел белән инануны шәригатьтә:

تَصْدِيقْ بِالْجَنَانِ *тасдыйк бил-җанани* —

дип атап йөртерләр.

*Шәригатьтә кабул ителгән буенча иманның кабул булуы өчен асылда иң төп саналган алты шарты бар.*

*Беренчесе:* Бәндә, әгәр дә ул иман китерде икән, иманын һәрдаим дәвамчылык белән тотарга һәм аңа таянырга бурычлы. Башта иман китереп, аннан соң кяферлек кылырга үзенә юл куйса яисә ниятләсә, аның иманына игътибар булмас һәм элеккечә мөселман саналмас, Аллаһы тәгаләнең ачуын алыр.

*Икенчесе:* Мөселман булган кеше иманның бер генә мәсьәләсендә дә шикләнергә тиешле түгел, шуның өчен дә ышанган хәлендә фикер итәргә, хөкем йөртергә һәм гамәл тотарга бурычлы. Әгәр дә алай түгел икән, иманы камил булмас һәм дөрескә саналмас.

*Өченчесе:* Галимнәр күрсәткән мәзһәбтә игътикад тоту иман китерүче өчен шарт булып тора. Әгәр дә бу юлларны бозса яки ташласа, әһле сөннәт игътикадына туры китермәсә, мәзһәбтән чыгар. Мәзһәбен ташлаган кеше кяферләр арасына керсә һәм мәзһәбсез йөрсә, кяфер саналыр.

*Дүртенчесе:* Иман китерү һәм аның хаклыгын раслау өчен адәм баласы һәрдаим Аллаһы тәгаләдән куркырга һәм аннан өметтә, ярлыкау таләбендә яшәү рәвешендә булырга тиешле. Әгәр дә шушы хәләтне хасил итмәсә, шарт бозылыр. Бер кеше шулай да иман китергән булып та, диннең тәрәге күрелгән намазны укымаса, башка таләп ителгән бурычларны үтәмичә, зур гөнаһлардан каралган зина һәм хәрәм эшләрне эшләп, бу ялгышларын аңлаган хәлендә тәүбә итеп Аллаһы тәгаләдән курыкмаса яисә тәүбә итеп тә яман юлга кабат баса калса, андыйның иманы камил булмас һәм ул мөселман саналмас, кяфердер.

*Бишенчесе:* Адәм баласы соңлап булса да иман китерә алыр. Әмма дә ләкин җан бугазга килгәнчегә кадәр иман китереп калу дөрес, җан бугаздан үткәч китерелгән иман дөрес саналмас.

*Алтынчысы:* Ахирәт хәбәре булып кояш баеган җиреннән чыгар. Иман китерү һәм тәүбә итү шушы көнгә кадәр алдан башкарылса гына дөрес.

## ИМАННЫҢ ТӨРЛӘРЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Уникенче асылташ:* Иманның төрләрен белмәгән кеше газапка лаеклы дип карала. Иманның төрләре икәү, беренчесе «тәхкыйкый иман» дип атала, икенчесен «истидлали иман» диләр. Тәхкыйкый булганда мәгънәсе — хак иман, бу исә фәрештәләргә һәм дә пәйгамбәрләргә хас. Алар барлык иман китерелә торган нәрсәләрне һәм дә затларны үз күзләре белән күреп, барлыгына ышаналар. Әгәр дә бер-бер мөселман күңелендә иманы камил хәлендә иман китерелгәннәрне күзе белән күрә икән, аның да иманы тәхкыйкый була. Шуңа күрә дә төшләрендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламне һәм башка иман китерелгән затларны вә әйберләрне күрүчеләр булса, алар бәхетлеләр һәм иманнары шиксез дөрес булуына дәлилле булырлар.

«Истидлали иман» өчен бәндәләр дә дәлил һәм исбатка көчләре җитеп, гыйлемнәрен файдаланырлар һәм иманны да дәлил белән китерерләр. Мондый иман көчле вә куәтле саналып, үзләре дә хак мөселман булырлар.

## ИМАННЫҢ ДӘЛИЛЛӘРЕ

*Унөченче асылташ:* Иманның дәлилләре ике төрле. Беренчесе — «дәлиле гакыли», ягъни акыл белән инанып дәлилләү, икенчесе — «дәлиле нәкъли», ягъни тел белән белдерергә тиешле дәлилләр. «Нәкъли дәлил» өчен Коръәннән һәм хәдисләрдән дәлилләр эзләү кирәк, әгәр дә аларга таянып иман

дәлилләнде икән, дөрес булыр. Акыл дәлиленә килгәндә исә, аның юллары болардан гыйбарәт:

Беренчедән, бәндәләр моны исләрендә тотарга тиешләр, Коръәннән:

﴿قُلْ انْظُرُوا مَاذَا فِي السَّمٰوَاتِ وَالْاَرْضِ﴾

*Кулинзуру мә-за фис-сәмәвәти вәл-ард*

Мәгънәсе: «И рәсүлем, бәндәләргә сөйлә: Карагыз күкләрдә вә җирләрдә булган әйберләргә,ул әйберләрне күреп һәм аларны бар кылучы Аллаһы тәгаләнең барлыгын белеп торыгыз». Икенчедән, барлык бар булган әйберләр һәрбер бәндә өчен ике төрле. Аларның берләре үзеңнән читтәге галәмәтләр, икенчеләре исә үзеңдә күрелгән галәмәтләрдер.

Үзеңнән читтәге галәмәтләр үзләре икегә бүленәләр: беренчесе — галәвият, икенчесе — сәфәлият.

## ГАЛӘВИЯТ

Күкләр һәм аларда күренгән галәмәтләр барчасы галәвият дип аталалар.

Бәндәләрнең акылы шуны төшенергә тиешлс, күкләр җиде кат булыр, бер-берсе өстендә торырлар, әмма берсенә икенчесе терәтелмәгән яки асылып куелмаган сурәттәдер. «Күн!», ягъни «Бул!» дигән әмер белән баштанаяк Хак тәгалә тарафыннан яратылганнар, искермәсләр, тишелмәсләр һәм төзәтүгә мохтаҗ булмаслар. Кояш, Ай, йолдызлар, яңгыр, җил, кар, болытлар һ. б. әйберләр барчасы да Аллаһы тәгалә әмере белән бар кылынып, аларга йөкләтелгән тәртип белән яшәрләр һәм олуг көчнең барлыгына дәлил булып торырлар.

## СӘФӘЛИЯТ

Җирнең җиде каты һәм аларда булган галәмәтләр барчасы сәфәлият дип аталыр.

Җир өстендә аккан сулар, үскән үсемлекләр, һәртөрле кош-кортлар, аларның яшәү рәвешләре,

туктаусыз агулары, күлләрнең ташуы, карларның эрүе, яз, аның артыннан җәй, көз, кыш килүе, таулар һ. б. барчасы да кодрәт иясенең барлыгын исбатлап торырлар, аларның барлыгы үзе дәлилдер.

## КЕШЕНЕҢ ҮЗЕНДӘ КҮРЕНГӘН ГАЛӘМӘТЛӘР

Адәм балаларының башлангычы туфрак булып, алар ата вә ана теләге белән һәм Хак тәгалә рәхмәте илә дөньяга килерләр, ризыкланып үсәрләр, колаклары ишетү өчен, күзләре күрү өчен, авызлары сөйләү өчен һәм башка җисемнәре һәртөрле хаҗәтләр өчен хезмәт итәр. Кеше олыгаеп, көннәрдән беркөнне камиллек дәрәҗәсенә ирешер, картаер, тешләре коелыр, чәчләре агарыр һәм дөньялыкта кылган гамәлләре өчен җавап тотарга гүр иясе булыр һ. б. Боларны аңлаган кешеләр Аллаһы тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә акыллары белән ышаныблар.

И мөэминнәр, иман диварларын төзүче унөч асылташны тикшереп һәм карап үттек. Сез дә бу рәвешле гыйлемнәрне күңелегезгә салып, акылыгыз белән аларны ныгытып, бәгырегез түрендә иман диварын күтәрсәгез, ул камил булыр һәм дин Исламның ныклыгын саклар, үзегезне мәңгегә бәхетле итәр. Алга таба иманның сыйфатлары белән танышкач, сез моның шулай икәнлеген тагын да ныграк төшенерсез.

## ИМАННЫҢ СЫЙФАТЛАРЫ

Иманның сыйфатлары *алты* төрле булып, аларны:

اٰمَنْتُ بِاللّٰهِ *әмәнтү билләһи*

وَمَلَائِكَتِهِ *вә мәләикәтиһи*

وَكُتُبِهِ *вә күтүбиһи*

وَرُسُلِهِ *вә рүсүлиһи*

وَالْيَوْمِ الْآخِرِ *вәл-йәүмил-ахири*

وَالْقَدَرِ خَيْرِهِ وَشَرِّهِ مِنَ اللّٰهِ تَعَالٰى وَالْبَعْثِ بَعْدَ الْمَوْتِ

*вәл-кадәри хәйриһи вә шәрриһи минәл-лаһи тәгалә вәл-бәгъси-бәгъдәл-мәүти* — диләр.

Бу алты төр иман дин телендә «иманның шартлары» яки «иман шарты» дип аталып йөртелә; аны шулай ук «зат иман», «асыл иман», «мөэминнәр иманы» дигән сүзләр белән дә белдерәләр. Димәк, иманның бу алты сыйфатларын санаганда без аларны иманның шартлары (иман шарты), яки зат иман, яисә асыл иман, йә булмаса мөэминнәр иманы рәвешендә аңларга һәм күңелебез белән инанган рәвештә телебез белән әйтә алырга тиешбез. Иман сүзләренең кодрәте вә башка диннәр каршында куәте зурдыр. Бәндәләр, ир булсыннар яки хатын-кыз затыннан торсыннар, алар шушы иман сүзләрен, ягъни «Мин Аллаһы тәгаләгә инанам, шулай ук фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, хәерле вә яман тәкъдиренә ышанам вә ышаныч белдерәм»,— дип үз ана телләрендә чын мәгънәсендә моның хаклыгын җантәннәре белән тоеп әйтә алалар икән, алар шуның белән мөэмин-мөэминә (мөслим-мөслимә) дәрәҗәсен алырлар һәм Аллаһы тәгалә каршында сөекле колларына әверелерләр, Кыямәт көненең авырлыкларыннан вә тәмуг газапларыннан, әгәрем ки үзләре начарлык вә бозык эшләре белән зыянлы шөгыльләр кылмасалар, һичшиксез котылырлар, җәзасыз калырлар һәм рәхмәт вә рәхәт табарлар. Иманлы бәндәләрне Аллаһы тәгалә үзенең ярдәменнән ташламас.

Кем дә кем иманга килде, ул шуның белән үз өстенә мөэминнәрдән таләп ителә торган бурычларны алды. Кем дә кем имансыз калды, ул кеше үзен бәхетсезлек вә җәбер-җәфага хөкем итте. Бәндәнең күргәне һәм күрәчәге Аллаһы тәгаләдәндер, чөнки бәндәләрнең үз-үзләрен тотышларына карап аларга җәзалар бирде; бәндәләрнең күргәне вә күрәчәге үзләренең кулындадыр, чөнки алар үз теләкләре белән теге яки бу гамәлне кылдылар, яманлык өчен яманлык, яхшылык белән яхшылыкны таптылар, Аллаһы тәгаләдән уза алмадылар, чөнки Хак тәгалә бар нәрсәләрне күреп вә белеп торучы буларак ахырдан үзе хөкем йөртер.

И мөэмин исемен алыр өчен җан аткан бәндә, син иманның шушы алты сыйфатын белдереп әйтүең белән мөселман булдың. Син аны күңелдән әйтәсеңме, укып барасыңмы яки кеше артыннан, мөгаллимең сүзләреннән соң кабатлап барасыңмы—болар барсы үз эшең. Әмма «укымадым-белмәдем» дип аклану бер дә тиешле эш түгел, иман китерү һәм шушы инануыңны гомереӊ буе саклау фарыз гамәлләрдән санала, фарыз эшең булып тора.

*_Әмәнтү билләһи_* ягъни «Аллаһы тәгаләгә инандым» дигән вакытта бу сүзләрнең үз эченә нәрсәләрне берләштерүен ачык итеп белергә кирәк. «Мин Аллаһы тәгаләгә инандым,—диген.—Ул бар һәм бердәнбер, затында һәм сыйфатында иптәше, охшашы юк, кимчелекле сыйфатлардан азат вә пакь, камил сыйфатлар белән сыйфатланган, барча җан ияләре-мәхлукатьләрне юктан бар иткән, гыйбадәт өчен бары Ул гына лаеклы һәм тиешле булуына ышаныч итәм»,—дип фикер белән тасвирлау һәм күңел белән төшенү тиешле. Әмма шундый бәндәләр бардыр, алар һәр сүзгә дәлил сорарлар. Аллаһы тәгаләнең барлыгына дәлил Коръән аятьләреннән билгеле булыр. Аять:

أَفِي اللَّهِ شَكٌّ فَاطِرِ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ ❀

*Ә-фил-лаһи шәккүн фатирис-сәмәвәти вәлард*

Аятьнең м ә г ъ н ә с е: «Аллаһы тәгаләнең барлыгына һичбер шик бармы, бәлки дәлилләрнең күплеге һәм ул дәлилләр барлыгына бик ачык дәлиллелек күренгәнлеге өчен шик ихтималы юк, ул Аллаһы тәгалә җирнең вә күкләрнең барлыкка китерүчеседер».

Аллаһы тәгаләнең берդәнбер икәнлегенә дәлил шулай ук Коръән аятендә китерелер:

قُلْ هُوَ اللّٰهُ أَحَدٌ ❀ اَللّٰهُ الصَّمَدُ ❀ لَمْ يَلِدْ ❀ وَلَمْ يُولَدْ ❀
وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ ❀

*Куль һуал-лаһү әхәд. Аллаһүс-самәд. Ләм йәлид вә ләм йүләд. Вә ләм йәкүл-ләһү күфүән әхәд*

Аятьнең м ә г ъ н ә с е: «(И Мөхәммәд,) Әйт, Аллаһы тәгалә бер генәдер. Ул камил хуҗадыр. Ул һичкемне тудырмады һәм үзе дә һичкемнән тумады, һичкем Аңа тиң түгел».

Моңа өстәп, тагын да бер аятьне искә төшереп үтәргә мөмкин. Аять:

لَوْ كَانَ فِيهِمَا اٰلِهَةٌ اِلاَّ اللّٰهُ لَفَسَدَتَا ❀

*Ләү-кәнә фи-һи-ма илаһәтүн иллал-лаһү ләфәсәдәтә*

Аятьнең м ә г ъ н ә с е: «Әгәр күкләрдә һәм җирләрдә Аллаһы тәгаләдән башка бер Аллаһ булса иде, болар үзара бозылыр һәм бер карарда тормас иделәр».

Моннан фәлсәфәи фикер казанышы өчен шулар күренер, Аллаһы тәгалә бер һәм ялгыз, әгәрем ки алар икәү булсалар, ул вакытта бу ике камил акыл үзара тартышыр, тегесе яки монсы өстен чыгарга тырышыр һәм галәмнең тәртибе бозылып, тынычлык югалыр иде. Халкыбызда бер мәкаль бар: «Ике тәкә башы бер казанга сыймый». Бу сүздән үзебез өчен күңелгә барып җитәрлек төшенчә чыгара алабыз. Тарихлардан шулай күренә ки, тәхет өстенә ике хан яки падишаһ менеп утыр-

са, алар бер-берсенә дошманлык кылып, илнең тынычлыгын бозарлар иде. Мәмләкәтләрнең таркалуы вә бетүе дә шуның аркасында. Читтән басып кергән дошманны куып чыгарырга була, әмма ил эчендәге бозыклыкны, туган белән туганның тарткалашуын җиңүе мөмкин түгел эшләрдән. Димәк, камиллеккә ирешүнең чиге юк дип белсәк тә, шуны төшеник: камиллекнең нигезе — ялгызлыкта, күплектә түгел. Бер урынына ике булуга ук камиллек җимерелә. Шуның өчен дә суфи вә дәрвишләр ялгызлыкны өстен күргәннәр, шәех яки ишаннарының итәкләренә генә тотынып йөрү аркасында дин юлыннан адашмаганнар, ягъни үзләре ялгызлык белән камиллеккә ирешү генә түгел, тагын да югарырак дәрәҗәгә омтылып, ялгыз бер шәех яки ишанга гына ияргәннәр, бер даирәдән икенчесенә күчеп йөрүләрне саташу итеп кабул күргәннәр. Гомумилек, берләшү — көч өчен кирәк, ялгыз берәүгә буйсыну, ягъни ялгызлыкка ирешү — камиллекне табу өчен шарт. Әгәр дә шәех яки рухи җитәкченең сүзе синең тарафтан хакыйкый һәм дөрес дип кабул кылынмый икән, башка фикергә тукталсаң, ул вакытта камиллегең югала, күңелең тынычсызлану таба.

«Әмәнтү билләһи...» сүзләренең мәгънәсе менә шушылар белән аңлатылыр, аның дәвамы булган **вә мәләикәтиһи** ягъни «һәм аның фәрештәләренә» дигән вакытыбызда, «мин Аллаһы тәгаләнең фәрештәләре булганлыгына инандым» дигән төшенчә хисап ителә. Коръән, хәдисләр гыйлемнәреннән аңлашылганча, фәрештәләр ашамаслар вә эчмәсләр, ризык җыюда һичбер мохтаҗлыклары күренмәс, аларда ирлек вә хатынлык сыйфатлары да юк, шунлыктан җенес теләге ярдәмендә ишәймәсләр. Алар күкләрдән җир йөзенә иңәрләр һәм җирдән күкләргә чыгарлар, моны бер дә авырлыксыз вә артык көч куймыйча башкарырлар, бер хәлдән җиңел генә икенчесенә керә алырлар, сурәт, төс, кыяфәтләрен алмаштырырлар, кабат асыл рәвешләренә кайтырлар. Алар кайбер пәйгамбәрләргә, әүлияларга, изге затларга яки кош, яки хайван, яисә бөҗәк, йә булмаса балык, яки болыт һ. б.

тереклек иясе яисә җансыз сурәттә килгәннәр, күренгәннәр вә мәңге Кыяматкәчә шушы хаслыкларын саклап калырлар вә күркәм дин иясе бәндәләрне шулай хозурларлар. Адәм балалары гөнаһ вә бозыклык кылалар, әмма фәрештәләр мондый гамәлләрдән тәмам азат вә ирекледер. Алар һәммәсе дә бер Аллаһы тәгаләнең генә әмерләренә буйсынучылар, шул рәвешле һәрдаим мактауга вә зурлауга лаеклылар. Боларның сәбәбе — аларда нәфес вә һәвәс кебек тойгыларның юклыгыннан. Әгәрем ки фәрештәләр адәм балалары төсле ризыкка, киемгә, торыр йортка, җенескә мохтаҗ булсалар, ул вакытта алар да безнең кебек бозыклык куркынычы астында яшәр иделәр. Кайчан Һарут белән Марут фәрештәләр җиргә төшерелеп, адәмиләргә хас сыйфатлар белән үзгәртелделәр, шунда ук күңелләрендә нәфес вә һәвәс уты пәйда булып, теләкләрен тыя алмадылар вә Ахирәт көненә кадәр җәзага тартылып, Аллаһы тәгаләдән миһербан үтенүдә котылу юлын таптылар. Бу хәбәрдән шул аңлашыладыр: бәндәләр һәрьяклап та мохтаҗ кылынып, нәфес вә һәвәс утыннан котылырга, һәрдаим Аллаһы тәгаләгә таянып, оҗмах өчен теләк тотып, рухи камиллеккә омтылырга тиешләр. Коръәндә әйтелгән:

﴿تَنَزَّلُ ٱلْمَلَٰٓئِكَةُ وَٱلرُّوحُ﴾

*Тәнәззәлүл-мәләикәтү вәр-рух*

Аның мәгънәсе: «Ул Кадер кичәсендә фәрештәләр һәм Рух иңәр». Моннан шул билгеле булыр: Рух дигәндә Җәбраил галәйһис-сәлам күздә тотылыр, чөнки тагын да аны икенче төрле «Рухыл-Әмин» дип атап йөртерләр. Ул фәрештәләр арасында иң мәртәбәлесе вә күркәме саналыр, аның янәшәсендә шулай ук олуглык белән Микаил, Исрафил, Газраил исеме белән аталган мәләкләр, ягъни фәрештәләр дан тотарлар.

«Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә күтүбиһи...» дигәнебездә **вә күтүбиһи* сүзе «мин Аллаһы тәгаләнең китапларына инандым» дигән тө-

шенчәне бирә. Бу китаплар Җәбраил фәрештәнең пәйгамбәрләргә килүендә Аллаһы тәгаләдән индерелгәннәр вә барчасы да изге булып торалар. Бу төшерелгән, ягъни пәйгамбәрләргә индерелгән китапларның баштагылары йөз сәхифә күләмендә, ун битлесе — Адәм галәйһис-сәламгә, илле сәхифәлесе — Шис пәйгамбәргә, утыз битлесе — Идрис галәйһис-сәламгә, ун сәхифәсе — Ибраһим пәйгамбәргә бирелеп, тагын да дүрт олуг китаплардан — Тәурат (Библия), Зәбур (Псалмы), Инҗил (Евангелие), Коръәннең — беренчесе — Муса пәйгамбәргә, икенчесе — Давыт галәйһис-сәламгә, өченчесе — Гайсә пәйгамбәргә, дүртенчесе — өммәтебезнең пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәламгә насыйп кылынды вә алардан бу китаплар дөньяга мәшһүр булдылар, бәндәләргә ирештеләр.

Бу адәм балалары өчен пәйгамбәрләренә бирелгән һәм алар тарафыннан аңлатылган китаплар арасында иң бөеге вә өстене — Коръәне-кәрим, аларның иң соңгысы да шушы китап. Болар — аның башка китаплар каршында дөреслеген белдерәләр. Аллаһы тәгалә аны моңа кадәр китерелгән китапларның ялгышлы булуыннан азат итеп хак бәндәләренә тапшырды. Ул китерелгәннән бирле Инҗил дә, Тәурат та, Зәбур да нәсех ителделәр. Гыйбадәт өчен Коръән дөрес һәм ышанычлы, гыйбадәттә бары тик аңа гына таянырга тиешлебез. Башка китапларга гыйбадәттә таяну ярамый. Әмма аларны Аллаһы тәгаләнең бәндәләргә биргән гыйлеме буларак өйрәнергә вә белергә тиешлебез. Коръәне-кәрим белән гамәл кылу дөрес. Аның хөкемнәре Кыяматкә кадәр хак, Кыяматкә кадәр торачак.

Без тагын да әйтербез: «...вә рүсүлиһи...» дип. Ягъни: «Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә күтүбиһи вә рүсүлиһи...» дип. ∗*Вә рүсулиһи*∗ дип әйткәнебездә «Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәрләренә инандым» дигән әманәтебезне бирәбез. Ягъни Аллаһы тәгаләнең әмерләрен колларына ирештерүчеләрнең пәйгамбәрләр булуын таныргa тиешлебез. Пәйгамбәрләр һәммәсе дә ялган сүздән һәм хыянәт итүдән азат, олы һәм кече гөнаһлардан

пакь. Иман китерәбез икән, моның шулай булуына инану тиешле. Адәм пәйгамбәрдән алып Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәламгә кадәр күпме генә пәйгамбәрләр килмәсеннәр, алар чыннан да Җир йөзендә булганнар, болар хакында гайре табигый вакыйга вә риваять-кыйссалар сөйләнүләргә дә карамастан (хәтерләребез кыскадыр, кай хәбәрләрне әкиятләргә дә әвереллдергәнбез), аларның тарихта булулары вә яшәүләре хак, монда ялган юк. Ул пәйгамбәрләр чыннан да Аллаһы тәгалә тарафыннан сайлап алынганнар. Адәм галәйһис-сәлам үзе Җир йөзенә җәннәттән чыгарылган, шуннан төшерелгән, башкалары исә анадан вә атадан туганнар, Адәм пәйгамбәрнең нәселеннән саналалар.

Пәйгамбәрне тану һәм белү тиешле. Ул кешеләр арасында яхшы гадәтләр белән сыйфатланган була: дөрес вә туры-хак сүзле, ышанычлы һәм Аллаһы тәгалә әмерен вә таләбен өммәтләренә ирештерүче, заманасына күрә иң акыллы, зирәклектә камил, һәртөрле начарлыклардан, көнчелектән-нәфрәттән азат, кешеләргә зыян ясаудан, башкаларны нәфрәтләндерүче кече вә олы гөнаһтан имин, бар төрле яхшылыклар иясе икәнлекләре хак. Әмма аларның пәйгамбәрлеккә кадәр ялгышулары һәм нәби булгач та дөрес юлдан тайпылып китүләре мөмкин. Мондый вакытта алар хакында «аягы таеп киткән» дип әйтү кирәкле. Чөнки тиз ара төзәтеп, дөрес юлларын төзекләндерерләр. Пәйгамбәрләр һәммә кешеләр төсле үк өсләренә кием киеп йөриләр, ашыйлар, эчәләр, әмма хәрәмгә кызыкмыйлар. Алар шулай ук хатын алалар, гаилә коралар, балалар үстерәләр, гашыйк булалар, ягъни адәм балаларына хас булган һәртөрле дөнья эшләре белән мәшгуль кылып, тормыш коралар, авырыйлар, савыгалар, гамь утын йоталар, хаҗәт күрәләр һ. б. Әмма бар эшләренең асылында гаделлек, дөреслек, акыл вә хөрмәт ятар, күңелләре дөрес булыр.

Пәйгамбәрләрнең барчасы да ир-ат җенесеннән сайланган, хатын-кызлардан пәйгамбәрләр юк. Сәбәбе — күңелләре йомшак булуда, шайтан коткысы алдында адашырга мөмкинлекләре аркасында вә акылларының ир-ат белән чагыштырганда күпне

күтәрә алмавы белән бәйле. Әмма хатын-кызлар арасыннан әүлиялар булыр. Мөхәммәд пәйгамбәр — ахыргы пәйгамбәр, аннан соң килгән затларда пәйгамбәрлек сыйфатлары күренсә дә, асылда пәйгамбәр булмаслар, бәлки әүлия аталырлар. Исламда тормаган, аны белмәгән акыл ияләре әүлиялык йөген тарта алмаслар, юллары хаталыдыр.

Иман китергәндә шулай ук Ахыр көнгә, Кыямәт көненә инану тиешле. Аны «...вәл-йәүмил-ахири...» дигән сүзләрне әйтү белән белдерербез. Ягъни: «Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә күтүбиһи вә рүсүлиһи вәл-йәүмил-ахири...» дип. ∗*Вәлйәүмил-ахири*∗ дигән вакытта «һәм Аллаһы тәгаләнең Ахирәт көненә китерәчәгенә инандым» дигән мәгънә икәнлеген онытмаска кирәк.

Моны ничек дип аңларга кирәк соң?

Шулай дип аңларга кирәк: һәр кеше үлгәннән соң яңадан терелтелеп, киредән элек яшәгән хәленә кайтарылачак, Мөнкир белән Нәкир фәрештәләр каберебезгә килеп, пәйгамбәребездән, динебездән, әлбәттә инде, иң элек Раббыбыздан, сорап, сөаль итәчәкләр. Кабер газабы да бар. Сират күпере, җәннәт, тәмугның булуы хак. Дөньяда яшәгән дәверендә һәр кешенең яхшы вә яман эшләрен теркәп торган гамәл дәфтәре дә бар. Бу дәфтәр укылып, Ахирәт көнендә бәндәләрнең хисап тотулары да хак. Җәһәннәм өстенә тартылган кылдан нечкә, кылычтан үткер күперне кичеп, җәннәткә керү дә дөрес. Кемнәр җәһәннәм әһеле булдылар, аларның газапка тартылулары да хак. Шунсы да бар, кем дә кем иман белән китә, иманлы була, ул бәндәсен Аллаһы тәгалә вә пәйгамбәре ташламый, Җир йөзендә кылган гөнаһларына бәрабәр газап вә җәзаларын алып, ул кеше ахыр чиктә, яманлыклары шулай юылып, җәннәткә кертелә. Әгәр дә менә шушыларның барсына да инанасың икән, димәк син Ахирәт көненең булачагына вә барлыгына чын күңелдән ышандың дигән сүз.

Һәм әйтербез: ∗*...вәл-кадәри хәйриһи вә шәрриһи минәл-лаһи тәгалә вәл-бәгъси-бәгъдәл-мәүти*∗ — дип, шуның белән иман кәлимәсен тәмам итәрбез. Бу сүзләрнең мәгънәсе болардан гыйбарәт: Адәм балаларына килгән хәер вә каза Аллаһы

тәгаләдән икәнен һәркем төшенергә тиеш. Әгәр дә бәндә үзенең көчен яхшылык теләүгә вә күркәм эшләргә сарыф итә икән, әлбәттә аңа хәер-яхшылык ирешер, мәгәрем ки яманлыкка тартылса вә начар эшләр кылса, ул вакытта казаланыр вә җәзасын алыр. Шуның өчен явызлыктан йөз чөерү, качу зарур, савапка тартылырга кирәк. Шуның өчен дә изгелек вә явызлык Аллаһы тәгаләнең тәкъдире һәм теләге белән була дигән сүзгә инандым дию тиешле. Димәк, бәндәләрнең язмышы Аллаһы тәгалә кулында, әмма кеше үз гомерендә, гамәлләрендә тәкъдире белән уйный, явызлыкны яки савапны эзли һәм Аллаһы тәгалә теләге белән таба. Моннан шул аңлашыла, бәндәләрнең тәкъдире Аллаһы тәгаләдән булса да, үзләренең дә теге яки бу казада гаепләре бар, һәм дә теге яки бу савапта гамәли өлешләре юк түгел.

Шулай итеп, без иманның асыл мәгънәсе нидән гыйбарәт булуын тикшереп аңлаштык.

اٰمَنْتُ بِاللّٰهِ وَ مَلٰۤئِكَتِهٖ وَ كُتُبِهٖ وَ رُسُلِهٖ وَ الْيَوْمِ الْاٰخِرِ
وَ الْقَدَرِ خَيْرِهٖ وَ شَرِّهٖ مِنَ اللّٰهِ تَعَالٰى وَ الْبَعْثِ بَعْدَ الْمَوْتِ*

*Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә күтүбиһи вә рүсүлиһи вәл-йәүмил-ахири вәл-кадәри хәйриһи вә шәрриһи минәл-лаһи тәгалә вәл-бәгъси-бәгъдәлмәүти* — дип иман китергән вакытта шушы мәгънәләрне эченә алган сүзләрне әйтүебезне төшендек. Әмма болар берсе дә Аллаһы тәгаләне танып-белүдән башка була алмый һәм дөрес түгел. Шунлыктан әһеле сөннәт һәм җәмәгать гадәтенчә Аллаһы тәгаләнең сыйфатларын белү зарур. Моңа алдагы бүлектә аерым тукталып китүне кирәк таптык.

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ СЫЙФАТЛАРЫНА ӘҺЕЛЕ СӨННӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ГАДӘТЕНЧӘ ИНАНУ ЮЛЫ

Аллаһы тәгаләне барлык камил сыйфатлар белән зиннәтләнгән Зат итеп беләбез, әмма андый

затны яшәешебездә күрү мөмкин түгел. Аның бары тик бар булуын танырга гына мөмкин. Шунлыктан һичкем вә һичнәрсә белән Аны чагыштыру ярый торган эшләрдән түгел. Акылыбызга килергә, фикеребезгә урнашырга мөмкин һәртөрле камил рәвешле вә сыйфатлы зат Аллаһы тәгаләнең үзенчәлекләре түгел. Ул алар белән генә чикләнми. Белергә мөмкин булган, яшәешебездә очраган һәртөрле яхшылык вә камиллекләр генә түгел, бәлки без күз алдыбызга да китерә алмаган өстенлекләр вә пакьлекләр дә Аңа хас. Бу өлкәдә һәммәбезнең хыялы вә танып белүе чикләнгән. Әмма безнең максат шуңа омтылырга, лаек булырга юнәлдерелгәндә генә яшәешебез бар, тормышыбыз бәхет вә сәгадәткә, үсеш вә тәрәккыятка таба бара ала. Әмма, тагын да әмма, нинди генә гүзәл вә камил хыялларыбыз булмасын, Хак тәгалә каршысында алар түбән. Димәк, тагын да күркәмрәк итеп уйларга вә өметләнергә тиешлебез.

Ничек кенә булмасын, Аллаһы тәгалә хакында безгә белергә мөмкин сыйфатларын голәма вә дин кешеләре бәян итеп калдырганнар. Иман юлыбызның ныклыгын төзегән борынгы галимнәрдән мәзһәбебезнең имамы Әбу-Мансур Матриди хәзрәтләренең өйрәтүләре буенча, Аллаһы тәгаләнең егерме ике сыйфатын белү бар. Аларның *берсе* — затына күрә сыйфаты, *бишесе* — сәлибия сыйфатлары, ягъни кире кагыла торган сыйфатлары, *сигезе* — сәбутия сыйфатлары, ягъни раслаучы һәм ачык дәлил белән белдерелүче сыйфатлары, *сигезе* — мәгънәвия сыйфатлары, ягъни мәгънәсенә төшенеп аңлау белән бәйле үзенчәлекләре. Болар барсы да Аллаһы тәгаләне танырга вә белергә ярдәм итәләр.

Затына күрә сыйфаты бар дигәндә төшенчәсе бик тирән. Аның мәгънәсе шуннан гыйбарәт: Аллаһы тәгалә бар! Аның барлыгы үзенә күрә, үзүзенә барлыгы белән аңлатыла. Аның барлыгы башкаларның булуы яки булмавы белән бәйле түгел, Ул һичбер заттан вә һичкемнең теләге белән бар булмады, Аның барлыгында һичкемнең катнашы юк, мөмкин дә түгел. Ул шулай ук һичнәр-

сәне вә һичкемне үзеннән тудырмады, ягъни балалары да, гаиләсе дә юк. Ул тудыру вә тудыртудан саф вә чиста. Юкка чыгуы мөмкин түгел. Аны бетереп, үтереп, түбәнәйтеп кую мөмкин эш түгел. *Иннәәна Аллаһу* аятендәгечә, ягъни «Дөреслектә мин — Аллаһ, мин — бар!»

Сәлибия сыйфатлары *биш* дидек. Алардан *беренчесе* — кыйдәм. Бу Аллаһының яшәве вә барлыгы белән бәйле сыйфаты. Аның бар булуының башы, әүвәлгесе, ягъни туган көне юк. Әгәр дә Аннан да алда берәр зат булган икән, ул вакытта ул Аның барлыкка китерүчесе, тудыручысы сыйфатында каралыр иде. Аллаһы тәгалә үзе яратучы, бар кылучы. Аның алдыннан, Аннан элек һичкем вә һичнәрсә юк иде. Барчаларны Ул үзе бар кылды, ягъни яратты.

*Икенчесе* — бәка. Бәка сыйфатының мәгънәсе, ягъни Аның барлыгының чиге юк, мөмкин дә түгел. Ул мәңге яши, мәңге бар! Коръәндә әйтелгән: *Һуал-әүвәлү вәл-ахиру вәз-заһиру вәл-батыйнү* — дип, ягъни: «Ул әүвәл һәм Ул ахыр һәм Ул күренүче һәм Ул яшерен», моның мәгънәсе: «Ул бар әүвәлгеләрдән дә әүвәлгерәк, Ул барча ахыргылардан да ахыргырак вә мәңгелек, Ул барча билгелеләрдән дә билгелерәк, Ул барча яшереннәрдән дә яшеренрәк вә серлерәк». Аның барлыгы безнең дәлилләребезнең никадәр күп булуына бәйле түгел, бәлки дәлилләребезнең күплеге белән акылыбыз вә йөрәгебез танып белә. Әмма аның ниндилегенә акылларыбыз һичкайчан ирешмәс вә төшенеп бетә алмас, без белмәгәннәрне вә күрмәгән-танымаганнарны да тану вә белүдән азат түгел. Аннан һичнәрсәне яшереп калдыру мөмкин түгел. Ул — мәңгелек!

*Өченчесе* — мөхалифәтүн лилхәвадиси сыйфаты, ягъни бар булганнар арасында һичнәрсә вә һичкем Аңа охшаш түгел, Аның сыйфатларын вә үзенчәлекләрен кабатлый алмый. Шулай ук Аллаһы тәгалә үзе дә һичкемгә вә һичнәрсәгә охшаш түгел. Коръәндә мондый аять бар: *Ләйсә кәмисилһи шәйүн* Мәгънәсе: «Аңа охшаш һичнәрсә юк!» Әгәр дә охшашы бар икән, димәк ул Аллаһы тәгаләгә тиңдәш булыр иде, Аңа тиң күрелер иде.

Сәлибия сыйфатларыннан *дүртенчесе* — кыйамүн бинәфсиһи, ягъни нәфестән өстен. Чөнки Аллаһы тәгалә барлыгында һичнәрсәгә мохтаҗ түгел, ризыкка да, яшәү урынына да, башкасына да. Аллаһы тәгалә уңда да, сулда да, җирдә дә, күктә дә түгел. Чөнки хәтта болар берсе дә юк чагында да Ул бар иде. Аларны бар итүдән соң үзенең барлыгын бетермәде. Әмма Ул аларга мохтаҗ түгел иде. Алар Аңа мохтаҗ. Аллаһы тәгаләнең барлыгына барсы мохтаҗ, хәтта галәм, дөнья, һәммә нәрсә дә. *Валлаһул-ганиййү вә әнтүмүлфукара-у* ягъни Аллаһы тәгалә сезнең Аны танымавыгыздан өстен һәм бөек, сез үзегез Аның савабына, ярлыкавына, рәхмәтенә мохтаҗ бит, әгәр дә Аны танысагыз, савабы үзегезгә, кире каксагыз, бәласе шулай ук үзегезгә. Моның белән Аллаһыга файда да, зыян да китерә алмыйсыз, барсы да үз башыгызга гына булачак.

*Бишенчесе* — вәхданиять сыйфаты, моның мәгънәсе шуннан гыйбарәт: Аллаһы тәгалә үзенең затына күрә һәм эшләрендә бердәнбер, асылда Аның охшашлары, иптәшләре һәм ярдәмчеләре юк. Ул боларга мохтаҗ түгел, Аңа арадашчылар кирәкми. Әгәр дә сайласа, Аның теләге. Бар нәрсәгә көче җитә. Аннан да бөек булу мөмкин түгел, бөеклек Аның хас үзенчәлеге. Әүвәлдән дә, ахырда да Ул шундый. *Куль һуал-лаһү әхәд* ягъни, әйт, Аллаһы тәгалә ул бер, бердәнбер!

Шулай ук сәбутия, ягънираслаучы, ачык дәлил белән белдерелгән сыйфатлары *сигез* төрле. Шуларның *беренчесе* — хәйан, ягъни һәрдаим терек булуы, *икенчесе* — гыйлем, ягъни һәрнәрсәне белеп торуы; *өченчесе* — сәмигъ, ягъни һәрнәрсәне ишетеп торуы, *дүртенчесе* — бәсар (бәсыйр), ягъни барсын да күрүе, *бишенче сыйфаты* — ирадә, ягъни теләүдән барсын да хасил кылуы, *алтынчысы* — кодрәт, ягъни һәрнәрсәгә көче-кодрәте җитүе, *җиденчесе* — кәлям, ягъни сүздә булуы, сөйләве; *сигезенчесе* — тәквин, ягъни һәрнәрсәне бар кылуы, хасил итүе, яратуы. Бу сыйфатларның һәммәсенә тиешле төшенчә һәм мәгънәләр бар, аларны мәгънәвия сыйфатлары дип аерып йөртәләр, шулай булгач, алары

да *сигез*. Сәбутия сыйфатында беренчесе хәйат булгач, мәгънәвия сыйфатында ул — хәй, ягъни яшәүче, икенчесе сәбутия сыйфаты — гыйлем, мәгънәвиядә — галим, белеп торучы; сәмигъ, бәсыйр, кадир, мәрам, мөтәкәллим, мөкүн. Боларны аерым-аерым карап үтик.

*Хәй*. Аллаһы тәгалә терек, әмма тереклеге безнең кебек кан һәм җан белән түгел, бәлки үзенә күрә терек вә тере, Аның тереклегенең әүвәле-башы һәм ахыры да юк. *Аллаһү лә иләһә иллә һүвәл-хәййүл-каййүм* ягъни: «Бердәнбер хаклык белән коллык ителә торган илаһи зат Аллаһы тәгаләдән башка юк, Ул бер, Ул терек, үз тереклегенчә яшәүче (Аллаһы тәгаләдән башка илаһи зат юк, Ул һәрвакыт терек)».

*Галим*. Аллаһы тәгалә барча олы-кече, зур-вак әйберләрне, һәммәне белеп торыр. Әмма Аның белүе безнең кебек акыл ярдәмендә түгел, өйрәнүдән дә килми. Үз гыйлеме буларак белүче, гыйлем сыйфаты рәвешендә белүче. Аның белемнәреннән әүвәлгесе дә, ахыргысы да юк. Гыйлемендә чиксез вә төпсез, ягъни никадәр икәнлеге дә билгесез. Ул борынгыны да, бүгенгене дә, киләчәкне дә белеп тора, эшләгәнне дә, уйлаганны да, яшерен һәм ачыкны да — һәммәне-һәммәне белеп тора. *Галимүл-гайби вәш-шәһадәти* ягъни: «Яшерен һәм билгеле-күренгәнне белүче галим ул Аллаһы тәгалә». Аның гыйлеменнән читтә бер генә нәрсә дә юк.

*Сәмигъ*. Аллаһы тәгалә барча тавышларны вә сүзләрне, уйларны вә фикерләрне, теләкләрне вә хисләрне ишетеп торучы зат. Әмма Ул безнең кебек колак белән түгел, бәлки үзенә күрә ишетү рәвеше белән барсын да ишетә. Аңа моның өчен арадашчы да, юлдаш та, фикердәшче дә кирәк түгел. Ул моны үзенең сыйфатлары белән башкара. Шушында мөэминнәрнең иманы башка динне тотучылардан аерылып тора. Тагын бер кат искәртик: Аллаһы тәгалә арадашчыларга мохтаҗ түгел. Ул болай да барсын да ишетеп тора: каты итеп кычкыручыны да, кырмысканың аяк атлавын да, җил тибрәнүен дә. *Вә һуас-самиигул-галиим* ягъни: «Ул Аллаһы тәгалә ишетүче-белүче». Шу-

шы аятьне хәтергә сеңдерү яхшы булыр, бәхәсләрдә яхшы дәлилегез итеп файдаланырсыз.

*Бәсыйр*. Аллаһы тәгалә барчаларны күреп торучы. Әмма Ул безнең кебек күз белән түгел, бәлки үзенә хас күрү рәвеше белән күрә. Борынгы дини китапларда аның күрү дәрәҗәсен караңгы төндә кара ташка басып үткән кара кырмысканың аяк атлавын күрә алу дәрәҗәсендә дип белдерәләр. Ул ачыкны һәм яшертенне дә күрә ала. Качып эшләү Аллаһы тәгаләнең күреп торуыннан азат итүгә ия түгел. Димәк, Аның карашыннан читтә калу мөмкин түгел. Шулай ук, мине күрсен әле, нинди яхшылыклар эшлим бит дип кат-кат белдерү-күрсәтүгә дә мохтаҗлыгы юк. Ул күрә һәм күрмичә калмый. *Вә һуас-самиигул-бәсыйр* ягъни: «Ул Аллаһы тәгалә һәрнәрсәне ишетүче-күрүче». Бу аять Аллаһы тәгаләнең күрүче икәнлегенә ачык дәлил.

*Кадир,* ягъни ирадә сыйфаты. Аллаһы тәгалә бар нәрсәне барлыкка китерүче. Аның моңа көчкодрәте җитә. Ул кодрәт иясе. Әмма безнең кебек түгел, үзенә хас рәвештә хасил кыла. Аллаһы тәгалә өчен биек тауны барлыкка китерүгә яки кырмысканы хасил кылырга бернинди авырлык вә кыенлык юк, барсы да бер. Теләге белән барчаларны мизгел эчендә юк итә ала, мизгел арасында кабат барлыкка китерергә сәләтле. «Бул!»—дисә, барсы булыр, «Бет!»—дисә, барсы бетәр. Һәркайсы үз теләгенә буйсынырлар. Чөнки галәмнең вә җирләрнең Ул бердәнбер хуҗасы, Аннан башка бернинди хуҗа вә әмер итүче була алмый. Аллаһы тәгаләнең кодрәтенә вә теләгенә бер генә нәрсә дә авыр вә кыенга килә алмый. Ул теге яки бу эшкә, затка, сыйфатка һәм башкасына көче җитмәүдән азат, гаҗиз була алмый. *Иннәл-лаһа галә күлли шәйин кадиир* ягъни: «Хакыйкатьтә Аллаһы тәгалә һәрнәрсәгә көче җитүче зат!» Шушы аять Аллаһы тәгаләнең кадир икәнлеген дәлилләп тора.

*Мәрам*. Аллаһы тәгалә—теләүче. Адәм балаларының күңелендә теләкләре булган кебек, Аның да теләкләре бар, әмма безнеңчә түгел, бәлки теләк рәвеше башкача. Безнең кебек теләмәгән эшләрен

башкармый, бәлки теләге аша хасил кыла. Аңа һичбер нәрсә үз ихтыяҗларын хасил кылу өчен кирәк була алмый, чөнки аның мохтаҗлыгы юк. Аның һәр нәрсәдә һәм эштә хикмәтләре бар. Ул хикмәтләрен төшенеп бетерергә мөмкинлек юк. Ул нәфестән азат, ни теләсә, шуны кыла. *Фәггаалүн лима йуриидү* я г ъ н и: «Аллаһы тәгалә теләгәнен кылучы». Коръәндәге шушы сүз теләүчелек үзенчәлеген тулысынча ачыклый.

Әгәр Аллаһы тәгалә теләмәсә, хәтта бер чебен дә канатларын тибрәтмәс. Барсы да Аның теләгеннән тора. Аның теләге һәрнәрсәгә вә һәркемгә җитә. Үтенсәң: «Йа Ходаем, бу дошманымның кылыч күтәргән кулы хәрәкәтсез калсын?!» — дисәң, бу теләгеңне Хак тәгалә кабул кылса, дошманыңның кулы таш кебек катып, ихтыярсыз калыр.

Шул ук вакытта бәндәләр өчен кече теләк бар. Моны нәрсә дип аңларга? Хикмәт шунда ки, Аллаһы тәгалә тырышлык куймыйча бәндәләргә теләгән эшләрен башкарырга мөмкинлек калдырмый, теге яки бу нәрсәне хасил итәр өчен һичшиксез бәндәгә көч сарыф итү кирәк. Теләгенә ул шул вакытта ирешә. Әгәр дә теләгәне яхшылык белән ирешелә икән, яманлыктан азат икән, ул вакытта аңа гамәле савап булып кайта. Мәгәрем ки теләгенә яманлык белән, усал эшләр ярдәмендә, начар гамәл белән ирешә икән, ул вакытта аңа Аллаһы тәгалә газап бирә. Белеп торырга кирәктер, Җир йөзендә һәркемнең үз теләге вә үз нияте бар. Алар һәркайсы моңа ирешү өчен көч түгәләр, кайвакыт теләк-омтылышлары кисешә яки туры килә. Берсе икенчесеннән уздыру нияте пәйда була. Әгәр дә шунда кайсы да берсе яманлык вә явызлык белән теләген хасил итәргә тырыша икән, белеп торсын, җавап төшерелер, көннәр үз чиратлары белән үтеп, газап табар. Яхшылык вә дөреслек белән теләгенә ирешкәннәр исә ахыр чиктә саваплы булырлар. *Иннәл-лаһа йәфгалү маә йәшаа-у* я г ъ н и: «Хакыйкатьтә Аллаһы тәгалә үзенең теләгәнен хасил итәр, кылыр». Бу аятьтән чыгып эш йөрткәндә, бәндәләр сабырлык белән коралланырлар, гамәлләренең ахыры савап буласын белеп торырлар.

*Кәлям.* Аллаһы тәгалә сөйләүче, әмма Ул адәм балалары төсле сөйләшмәс, бәлки Аның сөйләве үзгәдер. Аның сөйләвен ике төрлегә бүлеп карыйлар. Беренчесе, Ул теләгәнен күңелләребезгә төрле уй вә фикер аркылы җиткерә. Әмма һәркем максатын үзенчә билгели, шуның белән саваплы яки җәза табарлык эш башкара. Кайберәүләр үзләренең нәфесләренә вә көнчелек хисләренә ияреләр, Аллаһы тәгаләнең аларга ирештергән теләген кабул итмиләр, Аңа буйсынмыйлар. Бу рәвешле нәфес-шайтанга иярүләре әлбәттә гөнаһ, бер көнлек максатларына ирешеп, гомерлек җәзага калалар. Шунлыктан Аллаһы тәгаләдән китерелгән теләк белән нәфеснең саташтыруын һичшиксез аера белергә кирәк. Казага калуың бик мөмкин. Нәфесшайтаннан илаһи хәбәрне аерырга теләгән кешеләр борынгылар тапкан акыл вә хикмәтләргә күбрәк игътибар күзен салсыннар иде. Аллаһы тәгаләнең сөйләүче булуының икенче сыйфаты шунда ки, Ул пәйгамбәрләргә үзенең гыйлемен җиткерде, аларга китаплар бирде. Муса пәйгамбәр Аллаһы тәгаләнең гыйлемен Тур тавында алды, Мөхәммәд пәйгамбәребез Аллаһы тәгалә белән мигъраҗ вакытында сөйләште. Давыт пәйгамбәргә Зәбур иреште. Мөхәммәд пәйгамбәребез Коръәннең аятьләрен (мигъраҗда Аллаһының үзеннән алганнарыннан калганнарын) Җәбраил фәрештә аша ишетте. Болар барсы да Аллаһы тәгаләнең сөйләүче икәнлеген дәлилләп торалар.

*Тәквин.* Аллаһы тәгалә бар итүче, терелтүче, ризык бирүче, үтерүче, ягъни бәндәләргә вә башка затларга үлем тынычлыгы бирүче зат. Бу эшләр барсы да Аллаһы тәгаләнең теләге белән башкарыла, шунлыктан безнең язмышлар Аның кулында. Бер бәндәнең икенчесен үтерүе кебек гөнаһ эш исә Аллаһы тәгаләгә каршы кул күтәрү, Аның белән ярышырга теләү билгесе буларак аңлатыла һәм шундый хәрәм гамәлләр рәтенә керә дә. Аллаһы тәгалә бар кыла, әмма адәм балалары кебек түгел, бәлки үзенә хас рәвештә. Аллаһы тәгалә ризык бирә, әмма кешеләр яки башка затлар кебек пешереп, яки өзеп алып, яисә башкача иттереп түгел,

бәлки туфракта, суда, башка урында ризыкларны хасил кылырга, алардан тукланырга мөмкинлек тудыра. Әгәр дә Аллаһы тәгалә ризык бирмәсә, бәндәләр туклык тапмас, ачлык заманнары ирешер иде. Моны белеп торырга кирәк. Аллаһы тәгалә бәндәләрне йөртүче дә, хәрәкәтләндерүче дә. Әгәр дә Ул булмаса, без дә булмас идек. Аның барлыгына без үзебез дәлил. *Иннәл-лаһа һуар-раззаку* я г ъ н и: «Хакыйкатьтә Аллаһы тәгалә ризык бирүче». Кешенең, ризыгы бетмичә торып, әҗәле дә килми. Берәү икенчесенең ризыгын ашый алмас, гыйбадәт белән ризык күбәймәс яки мескенлек белән артып калмас, гөнаһ эшләүдән азаймас. Барчаларның ризыгы һәм гомере алдан ук билгеләнеп куелган булыр. Әмма монда бер сер бар: әгәр дә кылган гамәлләрең изге икән, ул вакытта ризыгыңның да бәрәкәте күп булыр, мәгәрем ки эшләгән эшләрең яманлык икән, ул вакытта ризыгыңның да бәрәкәте юктыр. Шул сәбәпле, әгәр дә ризыгыгызның бәрәкәтен табасыгыз килсә, яшәгән гомерегез заяга үтмәсен дисәгез, ул вакытта гамәлләрегез дә изгелектә булсын. Кешегә кылган җәберзолымыгыз көннәрнең берендә үзегезгә үк авырлык китерер, башкаларга күрсәткән яхшылыкларыгыз исә савап вә рәхмәт рәвешен табар, гомерегез бәхетле көннәр эчендә үтәр. Болар түгелме Аллаһы тәгаләнең берлеген вә барлыгын дәлилләүче сүзләр? Иманыгыз камил вә ныклы булсын! Мәгәрем ки шулай икән, сезнең һәрвакыт терәгегез — Аллаһы тәгалә!

## ШӘРИГАТЬ ДӘЛИЛЛӘРЕ

Без күп тапкырлар ишеткән һәм сөйләгән шәригатебез нигезләре нәрсәләр соң? Алар ничәү. Шәригатьнең дәлилләре *дүртәү,* алар: китап, сөннәт, әҗмәгу өммәт, кыйасе фөкаһа. *Китап* дип әйткән вакытта Коръәне-шәриф күз алдында тотыла, ягъни мөселманнар үзләренең йола-гамәлләрендә Аллаһы тәгалә сүзе-Коръән өйрәтмәләренә таянып эш йөртергә тиешләр. *Сөннәт* дигән вакытта тагын

да өч нәрсә игътибарда тотыла: пәйгамбәребезнең әйткән сүзләре, кылган фигыль-гамәлләре, тәкрарлары. Пәйгамбәр әйткән сүзләр исә аерым рәвештә хәдисләр дип йөртелә. Фигыль-гамәлләре исә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең белеп эшләгәннәре, ягъни ул теге яки бу гамәлне шиксез башкарган икән, димәк мөселманнар өчен шушы эшләре үрнәк санала, һәммә кешеләргә дә шулай эшләү гөнаһ түгел. Тәкрарлар исә, Мөхәммәд пәйгамбәр теге-бу бәндәнең эшләвен күреп торып та, аны туктатып, нигә алай эшлисең, дип кисәтмәве, яки ачык тел белән хуплавы, яки кире кагуы.

*Әҗмәгу өммәт* дигән вакытта Ислам галимнәренең, мөселманнарның һәммәсе дә бер фикергә килеп, теге яки бу гамәлнең асылда хәрәм түгеллеген дәлилләр белән ачыклап, җыен корып кабул итүләрен әйтәләр. Алар әгәр дә уртак фикергә киләләр икән, димәк бу канун да шәригатькә кертелә вә дөрес дип табыла. Кабул ителгән ул канунны бозмау өммәттән таләп ителә. Бу канунга нигезләнеп алга таба җәмгыятьтә хөкем тоту, хөкем йөртү шулай ук дөрес эшләрдән санала.

*Кыйасе фөкаһа* дигән вакытта, мөҗтәһидләрнең, ягъни дин галимнәренең моңа кадәр булмаган эшнең ни-нәрсә икәнлеген ачыклап, башка кануннарга туры китереп, аларның тәңгәллеген ачыклаганнан соң, бу эш дөресме-түгелме икәнлеген төшенеп, аны канунлаштырулары атала. Мисал өчен, хаҗга самолетка-очкычка утырып бару дөресме-түгелме, дигәндә, пәйгамбәребезнең гамәлләреннән булган эше исәпкә алына, ул исә дөягә утырып барган. Димәк, самолетта бару да хәрәм түгел.

## БАЛИГЪЛЫК ЯШЕНӘ ҖИТКӘН БӘНДӘЛӘРНЕҢ ГАМӘЛЛӘРЕ

Адәм балалары бер-берсеннән бары тик балигълык яшенә җитү-җитмәүләре белән генә аерылалар. Кемнәр әлегә балигъ түгел, алардан зур вә җитди эшләрне артыгы белән таләп итү бер дә дөрес эш түгел. Аларны икенче төрле сабыйлар,

үсмерләр дип йөртәләр. Акыл ягыннан нинди генә камиллеккә ирешмәсеннәр, алар һаман да шул исем белән йөртелерләр. Үзләреннән мәҗбүри рәвештә иман китерүне таләп итү, бишвакыт намазны укыту, хаҗ, зәкәт, уразаны үтәтү — болар теләкләре белән генә башкарылалар, сабыйны шунлыктан динсез яки имансыз дип атау бер дә урынлы түгел. Чөнки Аллаһы тәгалә каршында да, өммәт каршында да, олуглар вә түрәләр алдында да сабый баланың гөнаһы юк, әгәр дә ул кешелексезлек күрсәтмәсә, ягъни башка берәүне үтермәсә, көчләмәсә, кимсетмәсә. Балигъ булмаган кеше белән балигълык дәрәҗәсенә ирешкән, балигълык яшеннән үткән бәндәләр арасында, алар каршына куелган таләпләр ягыннан чыгып караганда, аермалар шактый күп. Алар шәригать каршында да бар, өммәт алдында да. Сабый бала эшен аңламыйча кылырга мөмкин, шулай эшли дә. Аның күңел күзе әлегә «йоклаган» санала. Балигълык яшенә ирешмичә торып, ул баладан дингә керү таләп ителсә, бу эштә зур гөнаһ бар. Шулай итеп, балигълык яшенә ирешмәгән баладан дин таләп итү дөрес эшләрдән түгел. Әмма бу әле алар дини йола вә тәртипләргә өйрәнә тормасыннар дигән сүз түгел. Дини йола-гадәтләргә өйрәтү эше аларның тәрбиячеләренә, ата-ана, әби-бабаларына йөкләнелә, аң булсыннар!

Балигълык яшенә ирешкән ир балага шәригатьтә «мөкәлләф» дип әйтәләр. Мәгәрем ки хатын-кыз икән, «мөкәлләфә» дияләр. Шушы рәвештә аталулары өчен, балигълык яшенә ирешүләреннән тыш тагын бер сәбәп бар, ул да булса, моның өчен аның акыллы булуы, ягъни акылга камиллеге таләп ителә. Әгәр дә ул кеше дивана яки мәҗнүн икән, ул вакытта алар шулай ук балигълык яшенә ирешмәгән, камиллек тапмаган, мөкәлләф булмаган кеше хисапланалар. Алар урталыкта дип тә бүленмиләр. Балигъ затлардан соралган гамәлләр дә болардан таләп ителми.

Балигълык яшенә ирешкән бәндәләрнең эшли торган эшләре, ягъни гамәлләре, шәригать өйрәтмәләре буенча *сигез* төрлегә аерылып йөртелә. Бо-

лар: 1. Фарыз; 2. Важиб; 3. Сөннәт; 4. Мөстәхәб; 5. Мөбах; 6. Хәрәм; 7. Мәкруһ; 8. Мөстәкрәһ.

Әгәр дә бер бәндә балигълык яшенә ирешеп, акылы камил, ягъни дивана түгел икән, ир-ат яки хатын-кыз булуына карамастан, ул менә шушы сигез нәрсәне яхшы итеп белергә тиешле һәм аларга таянып гамәл йөртергә бурычлы, әгәр дә үзен мөселман дип исәпләсә.

Диваналыкта шикле бәндәләрне мулла итеп танымаслар, эш вә гамәлдә аларга иярмәсләр, аларны, нинди яшькә җитүләренә карамастан, һаман да сабыйлар рәтендә күрерләр, әмма мохтаҗлыгына ярдәм итү, аңа киң күңеллелек күрсәтү дөрес булыр.

## 1. ФАРЫЗ

Фарыз гамәл дип Аллаһы тәгалә тарафыннан бәндәләргә әмер ителгән, шиксез рәвештә эшләнергә тиешле дәлилле гамәлләргә әйтәләр. Фарыз гамәлләр үз чиратларында тагын да *өч* төрлегә бүленәләр. *Беренчесе* — Фарыз даим. Мондый гамәлләр һичкайчан ташланмыйлар вә үзгәртелмиләр, һәрдаим вә һәр җирдә алар үз тәртипләре белән кылыналар. Һәрвакыт фарыз булган нәрсә — иман, ягъни бәндәләр һәрдаим инанып, шул инанырга тиешле булган нәрсәләрдән баш тартмаска, иманда камил калырга, шиккә төшмәскә тиешләр. Ул гына да түгел, әгәр дә инанасың икән, ул инанылган нәрсәләргә һәрдаим таянырга да тиешле.

Моның өчен «Әмәнтү билләһи...»не ахырына кадәр укып, шуңа таянып эш йөртү сорала. Бәндәләргә ачык билгеле булырга тиешле, ирләргә һәм хатыннарга йөкләнгән иң ачык билгеле, шиксез гамәл, төп фарыз менә шушы, ягъни иман. Әгәр дә иманы юк икән, бәндә аңа таянмыйча эшкә керештеме, иманын оныттымы, ул кеше мөселман дип атала алмый. Иманның һәрдаим күңел түрендә булуы тиешле. Аны икенче төрле «Фарыз гайн» дип тә йөртәләр. «Фарыз гайн» ул шундый нәрсә ки, бер кеше эшләп, икенче кешедән бу бу-

рыч төшми. Аны һәркем белергә һәм башкарырга тиешле. Мин бу тиешле эшне үти алмыйм, минем өчен син башкар, дию белән ул бәндәгә иман керми, аның белән ул мөселман саналмый. Бу фарыз бер кешедән икенчесенә йөкләнми вә күчми, бәлки һәркемнең үзе белән вә үзендә булырга тиешле. Иманның олуглыгы да шунда.

*Икенче* фарыз гамәлләрне төркемләп «Фарыз мүвәккать» дип йөртәләр. Мондый фарыз гамәлләр билгеле бер вакыт җитү белән эшләнеләләр, шул вакыт үтү белән (әгәр дә вакытында кылынсалар!) өстән төшереләләр. Бу фарыз мүвәккать дигәне шулай ук фарыз гайн тәртибендә карала, ягъни бу фарызны үзең өчен башкалардан таләп итү белән, үзең үтәми торып, өстеңнән төшерелми. Болар: бишвакыт намаз уку, ураза (рузә) тоту, байлыгың бар икән, зәкәт тапшыру һәм дә, көчең җиткәндә, хаҗ кылу.

*Өченче* төр фарыз гамәлләр — фарыз кифая (кифайә) дип төркемләнәләр. Фарыз кифайә булган вакытта, бер кеше тарафыннан ул төр фарызлар үтәлә икән, башкаларның өстеннән ул төр фарызлар төшә. Болар, мәсәлән: җеназа намазы уку (берәү укый, башкалар тыңлап торалар, шул рәвешле өсләреннән төшә), сәлам алу. Сәлам алган вакытта, мәсәлән, дүрт-биш кеше җыелышып утырганнар икән, алар янына килеп, берәү сәлам бирсә, алар барсы да кайтарып сәлам тапшырырга тиешлеләр, бу эш — фарыз. Әмма алар арасыннан берәү кабул итеп алса, ул вакытта бу фарыз башкаларның өстеннән дә төшәр. Инде берсе дә сәлам кайтармаса, фарыз гамәл өсләреннән төшмәс.

Фарыз гамәлләрнең хикмәте шунда ки, әгәр дә аны ташласаң, сиңа бик каты газап ирешә, әгәр дә шик белдерсәң, фарыз түгел дип исбатларга тырышсаң, диннән чыккан дип саналасың, ә инде үтәп барасың икән, ул вакытта бу гамәлләрең үзеңә үк савап буларак кайтарылалар.

Һәр фарыз гамәл эчендә *биш* фарыз бар. Алар: аның фарыз гамәл икәнлеген белергә тиешлек, белү белән бергә — эшләнүе-кылынуы фарыз, микъдары фарыз, инануы фарыз, ихлас күңел бирүе фарыз.

Әгәр дә аңсыз рәвештә башкарыла икән, мәсәлән, курку-куркыту белән, ул вакытта фарыз эчендәге биш фарызның төгәл түгеллеге беленә, шуның белән ихласлыгына шик төшә, гамәле дөрес булып бетми.

Димәк, фарыз гамәл икән, аны кылырга тиешлегенә һичбер шигеңне калдырмыйча ихлас күңел биреп, инану белән башкару мәслихәт.

## 2. ВАҖИБ

Ваҗиб гамәлләр дип шуларга әйтәләр — Аллаһы тәгалә һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәлам эшләргә кушып та, әмерендә шул нәрсәне кушканы шикле икәнлеге, шөбһәле булганы тәгаен дип уйланган гамәлләргә әйтәләр. Мәсәлән: бәйрәм намазы уку, корбан чалу, садака бирү һ. б. Болар бәндәләргә йөкләтелгән эшләр саналсалар да, аларны Аллаһы тәгалә һәм пәйгамбәре кушканлыкта шик, дәлилләрдә камиллек җитмәү аркасында шушы төркем гамәлләргә керәләр.

Ваҗиб гамәлләрне башкарган бәндәләргә, ваҗибнең хөкеме буенча, савап ирешер, әгәр дә үтәмисең икән, савапсыз калырсың, шик белдереп, бәхәс кыласың икән, ул вакытта диннән чыкмассың, мөселманлыгың саклаunion.

Һәр ваҗиб эчендә тагын да *өч* төрле ваҗиб бар. Алар: белү сорала, эшләү сорала, инануы сорала. Өч ваҗиб өстенә тагын да һәр ваҗибтә бер фарыз бар — ихлас булу. Әгәр дә соралганлыгы өчен генә башкарылып та, ул гамәлләр ихлас күңелдән үтәлмиләр икән, ул вакытта бу кылган нәрсәләре икейөзлелек була. Бу исә — хәрәм. Гамәлдә һичкайчан икейөзлеләнергә ярамый, чөнки эшең савап булып кайтмый, газапка әверелә. Шунлыктан чын күңелдән инанып башкарганда гына камиллеккә ирешергә мөмкин.

## 3. СӨННӘТ

Сөннәт гамәлләре дип шундый эшләргә әйтәләр, кайсыларын Мөхәммәд пәйгамбәр үз гомерен-

дә күп мәртәбәләр кылып, бер-ике тапкыр гына яки аннан да бераз артыграк калдырып торган, әмма аларны башкаруны гадәте иткән. Мисал өчен: тешне мәсвәк-чистарткыч белән чистарту, азан, камәт, җәмәгать белән намаз уку һ. б.

Сөннәтнең хөкеме шунда ки, әгәр дә аны кылсаң, рәхмәткә ирешәсең, савап табасың, әгәр дә калдырсаң, ул вакытта моның өчен җәза вә газап ирешми, шулай да шелтә бирелә, Аллаһы тәгаләнең рәхим-шәфкатеннән коры калырга мөмкинлек өчен сәбәп барлыкка килә.

Сөннәт гамәлләре *өч* төрлегә бүленәләр. Аларның беренчесен — сөннәт мөвәкдә дип, икенчесен — сөннәт гайре мөвәкдә, өченчесен — сөннәт гали-әл-кифайә, диләр.

*Сөннәт мөвәкдә* дип шундый гамәлләргә әйтәләр, кайсыларын Мөхәммәд пәйгамбәр үз гомерендә бер яки ике тапкыр гына үтәмичә калдырган, әмма моның өчен аерым олуг сәбәпләре булган нәрсәләр. Мәсәлән: иртә һәм ахшам намазының сөннәтләре, йәсигъ намазының соңгы ике рәкәгате, өйлә һәм җомга намазларының әүвәлге һәм соңгы сөннәтләре.

*Сөннәт гайре мөвәкдә* булган вакытта шундый гамәлләр күздә тотыла, кайсыларын Мөхәммәд пәйгамбәр бер вакыт эшләп, икенчесендә ташлаган булса, аннан тагын башкарса. Әйтик, икенде һәм йәсигъ намазларын укыганда әүвәлге сөннәтләрен калдыру шушындый гамәлләрдән санала.

*Сөннәт гали-әл-кифайә* дип шундый гамәлләргә әйтәләр, әгәр дә аларны арадан бер кеше башкарса, башкаларның өстеннән дә бурыч төшәр. Әйтик, җыелышып, өмә белән, бергәләшеп эшли торган теге яки бу эшкә тотынганда халык арасыннан берәү бисмилласын әйтеп керешә икән, ул вакытта моны һәммәсе дә тәкрарлаган кебек килеп чыга, барсына да кагыла, гамәлләре дөрес була.

## 4. МӨСТӘХӘБ

Мөстәхәб дип шундый гамәлләргә әйтерләр, кайсы эшләрне Мөхәммәд пәйгамбәр гомерендә

бары тик берничә мәртәбә генә эшләгән яки башкаларга моны эшләү кирәклекне белдергән, савабы барлыгын әйткән булса. Мисалга: нәфел намазы, нәфел садакасы бирү һ. б.

Мөстәхәб гамәлләрне үтәгән кешеләргә савап ирешер, ташлаганнарга исә шелтә дә белдерелмәс, газап та ирешмәс, шул ук вакытта андыйлар Аллаһы тәгаләнең шәфкатеннән дә коры калмаслар. Әмма дә ләкин үз гомереңдә берничә тапкыр бу гамәлләрне башкару яхшы булыр, моны истән чыгарырга ярамас.

## 5.МӨБАХ

Башкарсаң-башкармасаң да, кылсаң-кылмасаң да гөнаһ һәм савап бирми торган эшләр мөбах гамәлләр дип аталалар. Ягъни боларны кылу тыелмый һәм шулай ук шәригать каршында макталмыйлар. Утыру, тору, йөрү, йоклау, ашау һ. б. гамәлләр шундыйлардан саналалар. Алар бәндәләрнең тормыш ихтыяҗларыннан мәҗбүри рәвештә килеп туалар. Алардан арыну таләп ителми.

## 6. ХӘРӘМ

Хәрәм дип шундый гамәлләргә әйтәләр, кайсыларны Аллаһы тәгалә шиксез дәлилләр белән тыя, эшләмәскә, сакланырга куша.

Хәрәм үзе *ике* төрлегә бүленә. Аның берсенә — хәрәм ләгыйнә, икенчесенә — хәрәм ләгыйрә дип әйтәләр.

*Хәрәм ләгыйнә* булган вакытта, ләгънәтләнә торган эш һәм нәрсәләргә әйтәләр. Ул эшләрнең үзләрендә үк хәрәмлекләре күренеп тора. Болар: кеше үтерү, зина кылу-уйнаш, риба һәм ятимнәрнең малын ашау, ялган сүз, гайбәт, көнчелек белән сүз сөйләшү һәм башка шуның кебек эшләр, нәрсәләр. Әгәр дә берәү боларны кыла икән, ул зур гөнаһ эшләүче була. Шунлыктан тәүбә итүе тиешле. Әгәр дә тәүбәсез дөньядан үтә икән, андыйларның имансыз үлүләре ачык билгеле була. Тәү-

бәсезләрнең иманы дөрес булмый. Әгәр дә инде бу хәрәм эшләрне башкарган вакытында бисмилла белән керешсә яки болар хәрәм түгел, хәләл, дип белдерсә, ул вакытта ул кеше диненнән чыгар, иманы һәм никахы дөрес булмас. Мондый ирнең хатыны аңа хәрәм булыр, бергә йокласалар, эшләре зина саналыр. Шулай ук мондый хатын белән торган ирнең гамәлләре дә хәрәм булып, бергә йоклаулары гөнаһсыз ирне гөнаһлы итәр, зиналы исәпләнер. Шунлыктан, хәрәм эш эшләгән икән, үкенеп, тәүбә сорасын һәм иманын яңартып, яңадан никах укытсын.

*Хәрәм ләгыйрә* дип шундый гамәлләргә һәм нәрсәләргә әйтәләр, теге яки бу эш һәм нәрсә үзе асылда хәрәм булмыйча, башкаруы гөнаһ саналса. Мәсәлән: икмәк үзе хәрәм әйбер түгел, әмма аны урлау, кеше өлешен тартып алу кебек эш исә — хәрәм, ягъни караклык, кеше хакына кул сузу һ. б.

## 7. МӘКРУҺ

Хәрәмгә яки хәләлгә якын булган эш һәм нәрсәләр мәкруһ гамәлләр дип аталалар. Мәкруһ үзе *ике* төрле була. Берсе — хәрәмгә якын гамәлләр һәм нәрсәләр, икенчесе — хәләлгә якын гамәлләр һәм нәрсәләр. *Беренчесе* важибне калдыру, үтәмәү аркасында барлыкка килә. Мәсәлән, Ислам динен калдыру, башка дингә күчү. Моның өчен бәндә шәфкатьтән коры кала һәм казага юлыга. *Икенчесе,* сөннәтне калдыру белән бәйле. Мәсәлән, сакал йөртү — сөннәт санала, әмма сакалсыз булу үзе хәләл исәпләнелә. Моның өчен бәндәләр шелтәгә тартылмыйлар, казага да юлыкмыйлар.

## 8. МӨСТӘКРӘҺ

Һәртөрле изге гамәлләрне бетерә торган эшләрне һәм нәрсәләрне мөстәкрәһ дип йөртәләр. Мисалга: намазда дөнья хәлләрен сөйләшү, аятьнең мәгънәсен боза торган рәвештә ялгышып уку, тәһарәт алган вакытта бер-бер җирдән кан агу, ураза вакытында ашау-эчү һ. б.

# *Бишвакыт намазның тәртипләре*

*Бишвакыт намаз* дип әйткән вакытта бер тәүлек эчендә укыла торган биш намаз күздә тотыла. Бу намазларның һәрберсенең үз вакыты һәм дә тәртипләре бар. Аларны бутарга ярамый. Беренчесе иртәнге намаз дип атала, икенчесе өйлә намазы (җомга көннәрдә аның урынына җомга намазы укыла), аннан соң икенде намазы, ахшам намазы, йәсигъ (ястү) намазы.

## ИРТӘНГЕ НАМАЗ

*Укыла торган вакыты*— таң беленә башлаганнан алып кояш чыкканчыга кадәр укылып тәмам ителергә тиешле.

*Тәртибе*— иртәнге намаз дүрт рәкәгать башкарыла, ягъни дүрт тапкыр кабатлана. Аның әүвәлге ике рәкәгате— сөннәт мөвәкдә, калган икесе— фарыз.

*Кагыйдәләре:*

1. Әгәр дә бер кеше иртәнге намазына мәсҗидкә килгәндә җәмәгатьтән соңга калып җитешсә, инде ул вакытта алар фарызны үтәүгә керешкәннәр икән, бу очракта: а) соңарган бәндә: «Әгәр дә сөннәтне укысам, җәмәгать артыннан әттәхияткә җитешермен!»— дип фикерләп намазга керешә икән, акылы белән хөкем кылса, сөннәтне калдырмас, укыр һәм дә җитешергә тырышыр. Бу юлы аңа ашыгу дөрес саналыр, гөнаһка кермәс. б) соңарган бәндә: «Әгәр дә сөннәтне дә укысам, әттәхияткә җитешә алмам!»— дип борчыла икән, ул вакытта сөннәтне калдырып, имамга оеса, яхшырак. Чөнки җәмәгатьнең савабы, алар белән бергә намаз уку, сөннәтнең савабыннан артыграк. Сәбәп: соңыннан

сөннәт өчен каза тиешле түгел, ягъни сөннәтнең казасы кайтарылмас.

2. Әгәр дә бер бәндә иртәнге намазын укырга соңарса, йоклап калса, инде кояш чыгарга өлгерсә, ул очракта каза итеп, төшкелеккә кадәр (өйлә намазы алдыннан) иртәнге намазын сөннәте белән бергә үтәр, әгәр дә төштән соңга (өйлә намазыннан ахырга) калдырса, ул очракта фарызын гына каза итәр, сөннәтне каза буларак үтәмәс, калдырыр.

3. Әгәр дә мөселман бәндәсе иртәнге намазга килгәндә җәмәгать мәсҗидтә фарызга кергәннәр икән, ул вакытта бу соңаручы сафка басып яки артка чыгып сөннәтне укуы мәкруһ була, шунлыктан ул сөннәтне мәсҗиднең сөннәт бүлмәсендә башкарыр, әгәр дә андый бүлмәсе юк икән, ул очракта мәсҗиднең почмагында укысын. Әгәр дә өендә сөннәтне укып килгән булса, ул вакытта кабатлавы кирәк түгел, фарызга кушылыр, сафка керер яки арттан урын алыр.

## ӨЙЛӘ НАМАЗЫ

*Укыла торган вакыты* — кояш баш түбәсенә җитеп, бераз авышканнан соң гына башкарыла.

*Тәртибе* — өйлә намазы ун рәкәгатьтә булыр. Элек дүрт рәкәгать сөннәт укыла, аннан соң дүрт рәкәгать фарыз башкарыла, ахырдан тагын да ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә укыла. Әмма дә өйлә намазының соңгы ике рәкәгате сөннәт мөстәхәб саналып, аны арттырып дүрт рәкәгать кылуның савабы бик күп. Һәр ике рәкәгате бер намаз исәпләнелә. Шунлыктан, әүвәлге утырышка керүе фарыз. Салават һәм догаларны башкарып, аягына торганнан соң «Сөбханәкә»не укуы кирәк. «Бисмилләһ» белән башлап китәр. Теләгән тәкъдирендә икешәр рәкәгать итеп укыр, ягъни ике рәкәгать укыганнан соң аягына басар алдыннан сәлам бирер, торыр, яңадан ике рәкәгатьне ниятләп, өстән аны башкарыр. Шунсы да бар, көндезге намазларда дүрт рәкәгатькә бер тапкыр, кичкеләрдә исә ике рәкәгатькә бер сәлам бирү мактаулы исәпләнелә.

*Кайбер кагыйдәләре:*

Әгәр дә бер мөэмин өйлә намазына соңарып килсә, ул вакытта җәмәгать фарызга кергән булса, ул вакытта бу бәндә дә имамга оеп, фарызны башкарыр. Әүвәлге дүрт рәкәгать сөннәтне фарыздан соң каза итеп үтәве дөрес булыр, аннан соң гына ике рәкәгать ахыргы сөннәтне укыр.

## ИКЕНДЕ НАМАЗЫ

*Укыла торган вакыты* — аяк өсте басып торганда күләгәң үзеңнән ике тапкыр озынрак икән, намазга керешергә мөмкин. Кояш батканчыга кадәр уку тиешле.

*Тәртибе* — икенде намазы сигез рәкәгать була, иң элек дүрт рәкәгать сөннәт мөстәхәб башкарыла, аннан соң дүрт рәкәгать фарыз үтәлә.

*Кайбер кагыйдәләре:*

1. Әгәр дә бер кеше мәсҗидкә килгән вакытта мөэминнәр фарызга кереп, камәт итсәләр, ул вакытта соңаручының фарызга тотынып, сөннәтен калдыруы, имамга оюы дөрес күрелер.

2. Әгәр дә соңарган кеше сөннәткә керешүгә мөэминнәр камәт итсәләр, ул вакытта аның өчен ике рәкәгать укып, сәлам биреп, имамга оер, бу дөрес гамәл күрелер. Әгәр дә инде өченче рәкәгатькә торса, аны тәмам кылып, шуннан соң гына фарызга күчәр.

## АХШАМ НАМАЗЫ

*Укыла торган вакыты* — кояш тәмам батканнан соң, шәфәкъ кызыллыгы беткәнгә кадәр укыла.

*Тәртибе* — иң элек өч рәкәгать фарыз, аннан соң ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә, барсы бергә биш рәкәгать укыла.

## ЙӘСИГЪ (ЯСТҮ) НАМАЗЫ

*Вакыты* — кояш тәмам баеганнан соң, шәфәкъ кызыллыгы югалып, иртәнге таңга кадәр вакыт аралыгы эчендә ниятләнеп укыла.

*Тәртибе* — йәсигъ намазы барлыгы унөч рәкәгатьтән гыйбарәт: иң элек дүрт рәкәгать сөннәт укыла, аннан соң дүрт рәкәгать фарыз, тагын да ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә һәм өч рәкәгать витр намазы укыла.

*Кайбер кагыйдәләре:*

Йәсигъ намазының икенче өлешендәге ике рәкәгать сөннәтне дүрт рәкәгать уку саваплырак санала. Әмма бу вакытта әүвәлге ике рәкәгате сөннәт мөстәхәб кылынып, аннан соңгы ике рәкәгатен «Сөбханәкә...» һәм «Әгузү...» «Бисмилләһ...» белән укырга кирәк. Шул рәвешле алар икешәр-икешәр рәкәгать булырлар. Шулай ук сөннәт һәм нәфел намазлары фарыз намазлары рәвешендә укылырга тиешле. Фарызны бозганнар исә сөннәт һәм нәфелне бозалар. Әгәр дә башка намазларда дүрт рәкәгать бер намаз хисабында йөрсә, йәсигъ һәм икендедә ике рәкәгать бер намаз исәпләнелер. Шунлыктан, теләсә, сөннәттә ике рәкәгатькә бер сәлам бирер, теләсә — дүрткә бер сәлам. Әгәр дә дүрткә бер сәлам бирә икән, ул вакытта, әүвәлге утыруында әттәхияттән соң салават һәм догаларын укыр, аягына торган вакытында «Сөбханәкә...» «Әгузү...» «Бисмилләһ...»ләрне башлап әйтеп үтәр:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ وَ تَبَارَكَ اسْمُكَ وَ
تَعَالٰى جَدُّكَ وَلَا اِلٰهَ غَيْرُكَ ۞

*Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкәс-мүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә иләһә гайрүк*

«Сөбханәкә»нең татарчасы моннан гыйбарәт: «И Аллаһы тәгалә, Сине бар яманлыктан саф дип беләмен һәм Сиңа мактау әйтәмен, Синең исемең бәрәкәтле булды, Синең олылыгың өстен булды, Синнән башка илаһи зат юк!»

۞ اَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ۞

*Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-ражим*

Татарчасы: «Рәхмәтеңнән сөрелгән шайтанның явызлыгыннан Аллаһы тәгалә үзеңә сыенам!»

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим*

Татарчасы: «Дөньялыкта һәм Ахирәттә рәхмәтле Аллаһы тәгаләнең исеме белән башлыйм!»

## НАМАЗНЫҢ ШАРТЛАРЫ

Намазның *унике* шарты бар. Аларның алтысы намазга кергәнче үтәлергә тиешле, аларын — «шарт» дип атыйлар, калган алтысы — намазга кергәч үтәлә, боларын — «рөкен» дип йөртәләр.

*Намазга керер алдыннан кирәкле шартлар:*

1. Тәһарәт алу, тиешле булса, госел коену.

2. Нәҗестән сафлану, тәндә, киемдә, намаз укый торган урында нәҗесләр бар икән, аларны чистарту фарыз.

3. Гаурәт урыннарны кием белән каплау, аларны ачылып китмәслек итеп ябу шарт.

4. Кыйблага йөз белән басу, ягъни Кәгъбәи-шәриф тарафына йөз белән юнәлеп тору.

5. Намаз — вакытында укылганда гына дөрес, ягъни бишвакыт намазларның кайсы вакыттан кайсы вакытка кадәр укылырга тиешлеген дөрес белеп һәм шул чакта гына уку.

6. Ниятләнү, ягъни кайсы вакыт намазыңны укыйсың икән, шул вакытның намазын ният итеп башкару, ниятеңне белдерү.

*Намазның эчендә булган шартлар:*

1. Ифтитах тәкбир, ягъни намазгаябышканда колак каккан вакытта «Аллаһү әкбәр» дип әйтү.

2. Кыям, ягъни намаз укый торган кеше аяк өсте басып башкару.

3. Кыйраәт, ягъни намазда аяк өсте булганда Коръән уку.

4. Рөкүгъ, ягъни баш белән билне тигез итеп иелү, бөгелү.

5. Сәҗдә, ягъни тезләрне, аякларны, кулларны һәм йөзне җиргә кую, терәү.

6. Кагъдә ахирәт, ягъни намазның ахырында «әттәхият» уку өчен кирәк булган вакыт аралыгы дәвамында утырып тору.

Боларның берсен дә намаз уку алдыннан һәм укыганда онытып калдырырга ярамый, әгәр дә хәтердән чыксалар, дөрес намаз хисапланмый.

Хәзер бу унике шартның ничек үтәлүен аерым-аерым карап, тәртипләрен күреп үтик.

## НАМАЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ ШАРТЫ — ТӘҺАРӘТ АЛУ

*Тәһарәт алу* ике төрле була, аның *беренчесе* — олуг тәһарәт, ягъни тәһарәт кәбирә. Олы тәһарәт — коенырга кирәкле саналганда, коенып сафлануны таләп итә. *Икенчесе* — кече тәһарәт, ягъни тәһарәт сагыйрь. Монсы госелне таләп итми, юынудан гыйбарәт.

## ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ

Коръәндә шундый аять бар: *Вә ин күнтүм җүнүбән фаттаһһару* ягъни: «Әгәр да сез чиста түгелсез икән, ул вакытта камил рәвештә тазарыгыз», ягъни госел коенагыз.

Госелнең *өч* төрле фарызы бар:

1. Мәзмәзә, ягъни авыз чайкау. Авыз куышлыгына су алып, анда бер генә урынны да калдырмыйча бер кат чайкаудан гыйбарәт.

2. Истиншакъ, ягъни борын эчен чайкау. Моның өчен борын эченә су тартыла һәм аның нечкә тишегенә кадәрге барлык урыннары су белән чылатыла, чистартыла.

3. Коену. Моның өчен тән-гәүдәнең барлык җирләрен су белән сафландыру таләп ителә. Әгәр дә бер генә урынында да, ягъни чәч арасы, култык асты кебек һәм башка бер төшендә энә очы кадәр генә булса да җиргә су тими калган икән, ул вакытта госелең дөрес түгел. Тәнеңә балык тәңкәсе

ише әйбер ябышып, астына су үтмәсә, шулай ук госел дөрес түгел. Тәнеңнең һәммә ноктасына, йөзек ише әйберләрнең асларына да су тидереп юу шарт.

Авыз-кулны юмыйча ашарга утыру һәркемгә мәкруһ санала!

Әгәр дә госел коенучы хатынның чәчләре толымнарга үрелеп куелган икән, ул вакытта толымнарын сүтеп тору шарт түгел. Шулай да ул хатын чәчләренең төпләрендә коры җир калдырмыйча чылатыр, толымнарын сүтмичә генә суын сыгар, шулай дөрес булыр.

Әгәр дә хатынның чәчләре толымнан сүтелгән икән, ул вакытта, госел алганда, бөтенләй тулысынча чәчен юу сорала.

Әгәр дә ир кешенең чәче үрелгән икән, ул вакытта ул аны сүтәргә һәм тулысынча юарга тиешле.

Әгәр дә чәче таратылган икән, ягъни үрелмәгән булса, ул вакытта ир кеше шулай ук чәчләрен бөтен тулысы белән бергә юарга тиеш.

Әгәр дә госел коенучы хатынның тырнак астында коры камыр калса, ул вакытта госеле дөрес түгел, кабатлап башкарылуы сорала. Чөнки камыр бер ара каты булып та, бераздан аңа су үтеп йомшарыр һәм юылыр. Шул ук вакытта камыр кебек башка төрле әйберләр белән дә эш итүчеләргә бу таләпләр карый. Әгәр дә тырнак астында балчык калган икән, ул вакытта госеле дөрес була, чөнки балчыктан тәнгә су госел коенган вакытта ук үтә. Бу очракны дөрес аңлау өчен бер хакыйкатьне игътибардан чыгармаска, шуның ярдәмендә төшенергә киңәш итеЛә: әгәр дә тырнак астыңа чыра ише нәрсә кадалып, үзе белән бергә балчык та керткән булса, чыра алынып та, тырнак асты каралып, балчыгы калса, госел коенганда тырнак астын каезлап-җимереп су кертеп маташу һич тә кирәкле һәм дөрес эш түгел, чөнки госелең дөрес икәнлеген онытмаска гына кирәк.

## ГОСЕЛНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ

Әгәр дә олы-кече йомышларыңны башкарсаң, алар артыннан ул урыннарны юарга кирәк һәм

аны ният итеп эшләргә тиешле. Аннан соң намаз тәһарәте кебек юыну сорала. Тәһарәт алганда авыз, борын, кул һәм башка урынны өчәр мәртәбә юу һәм уу — сөннәт.

Коенган вакытта иң элек уң җилкәсеннән башлап, сулына күчү, аннан баш очыннан коену дөрес.

Госел коенган вакытта аяклары әгәр дә су эчендә калсалар, соңыннан ул аякларын аерым юып алу тиешле.

## ГОСЕЛНЕҢ МӘКРУҺЛАРЫ

1. Госел коена торган җиргә олы-кече йомышларны башкару.
2. Кыйблага таба карап яки арка белән басу.
3. Гаурәтләрне капламыйча коену.
4. Дөнья сүзен сөйләшү.
5. Суны җиткән кадәрледән артык исраф итү. Әгәр дә сабын белән юынасың икән, ул вакытта суны артыгы белән исраф итүдә мәкруһлык юк, кирәгенчә кулланырга кирәк.

Әгәр дә госел коенган кешенең суы икенче берәүгә тамса, дин галимнәренең берләре бу суны пакь дип белдерә, икенчеләре сидек белән тиңли. Шунлыктан госел коенган кешенең суы таммаслык итеп үзеңне саф калдыру тиешле. Әгәр дә суы тама икән, ул вакытта яңадан коену кирәк. Комганының капкачы юк икән, ул вакытта да бик сакланырга кирәк. Госел коенган кешенең суы комган эчендәге суга төшсә, ул су бозылыр, аның белән госел коену дөрес түгел. Госел пакьлекне таләп итә. Тәһарәт алганда да, әгәр дә берәүнең суы сиңа тама икән, тәһарәтең бозыла.

## ТӘҺАРӘТ ФАРЫЗЛАРЫ

Тәһарәтнең юынуда *дүрт* төрле фарызы бар:

1. Йөзне юу. Чәч үсә торган урыннардан алып ияк астына кадәр һәм бер колак йомшаклыгыннан икенчесенә тикле барсын пөхтәләү. Әгәр дә сакалы бик тә куе икән, астына су үткәреп бетерү мөмкин

түгеллек сәбәпле, сакалга мәсех кенә кылыныр, әгәрем ки сакалы сирәк икән, ул вакытта төбенә кадәр чылату сорала.

2. Ике кулларын да терсәкләренә кадәр юу. Әгәр дә бармакларында йөзеге булса, тыгызланып, астына су кермәсә, ул вакытта йөзекне йөрткәләп, астына су үткәрелер.

3. Башның дүрттән бер өлешенә мәсех итү, ягъни чылатып алу, су белән сыпыру. Бармакларны учка кадәр чылатып, чәчтән бүтән һичнәрсәгә кулларны тидермичә мәсех алыныр. Әгәр дә бармаклар нәрсәгә булса да тиеп китә икән, ул вакытта мәсех дөрес түгел. Бармакларны мөмкинчә башка нәрсәләргә тидермәскә тырышырга кирәк. Бармаклар учка кадәр чылатылгач та чәчләрнең дүрттән бер өлешенә мәсех тартылыр, бармаклары белән чәчне кузгаткалап куелыр. Хатын-кызлар да шушы рәвешле итәрләр.

4. Ике аякны да тубыкларына кадәр юу.

## ТӘҺАРӘТНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ

1. Тәһарәткә керешкән вакытта моны укырлар:

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلْعَلِيِّ ٱلْعَظِيمِ وَٱلْحَمْدُ لِلَّهِ عَلَىٰ دِينِ الإسْلام
وَعَلَىٰ تَوْفِيقِ ٱلإِيمَانِ وَعَلَىٰ هِدَايَةِ ٱلرَّحْمَٰنِ۞

*Бисмилләһил-галиил-газыйм вәл-хәмдү лилләһи галә динил-ислам вә галә тәүфыйкыл-иман вә галә һидайәтир-рахман*

Мәгънәсе: «Олуг булган Аллаһы тәгаләнең исеме белән башлыйм тәһарәт алырга. Ул Аллаһы тәгаләгә бик күп рәхмәтләремне әйтәмен — Ислам динендә кылганлыгын иман биргәне өчен һәм дә хак юлга күндергәненә!»

Кулларны юганда бармакларны аралаштыру — сөннәт.

2. Юыла торган барча әгъзаларны өчәр кат юу.

3. Авызга су алган вакытта теш чистарткыч ярдәмендә тешләрне чистарту һәм борынга су алып, суны кире төшерү, ягъни сеңгерү.

4. Йөзне юарга керешкән вакытта: «Ният иттем йөземне юарга, тәһарәт алырга»,— дип белдерү.

5. Муенны һәм колакларны мәсех итү һәм һәр юыла торган әгъзаларны сафландыруны уң яктан башлау.

6. Һәр юыла торган әгъзаларны кабул ителгән тәртибе буенча чиратландырып башкару: әйтик, башта — йөзне сафландырасың, аякларга мәсехне иң соңыннан үтисең. Әмма бу тәртипне бозып, башта аякларга мәсех, аннан соң йөзгә пакьләндерү ясарга да мөмкин, бу очракта тәһарәт һич тә бозылмый, бары тик сөннәткә хилафлык кына килә.

## ТӘҺАРӘТНЕҢ МӘКРУҺЛАРЫ

Тәһарәтнең мәкруһларыннан *унысын* гына карап үтәрбез, алары төп, башка галимнәр тарафыннан да бәхәссез рәвештә кабул ителгәннәр:

1. Тәһарәт алган вакытта суны йөзгә бик каты ору, чәчрәтеп юыну киңәш ителми.

2. Тәһарәттә йөзеңнән тыш бүтән әгъзаларны өчтән ким тапкыр юып төшерергә киңәш ителми.

3. Тәһарәттән төшкән суның өстенә төкерү һәм сеңгерү киңәш ителми.

4. Тәһарәт алган вакытта кыйблага арка белән тору киңәш ителми.

5. Уң кул белән сеңгерү киңәш ителми.

6. Сул кул белән авызга һәм борынга (тәһарәт алган вакытта) су күтәрү мәкруһ санала.

7. Кояшта җылынган су белән тәһарәт алу киңәш ителми.

8. Тәһарәт алынучы әгъзаларны сул тарафтан башлап юарга ярамый.

9. Тәһарәт алган вакытта дөнья сүзен сөйләшмиләр.

10. Йөзне юган вакытта авыз-күзләрне бик нык ачу яки каты йому киңәш ителми.

## ЧИТЕККӘ МӘСЕХ ИТҮ

Читекләргә мәсех итү хәдисләр һәм сөннәт белән дәлилләнә. Әмма читекләргә мәсех итү тәһа-

рәт өчен генә дөрес, госел коенганда исә дөрес түгел. Әгәр дә читекләргә мәсехне тәһарәттә калдырса, ул вакытта тәһарәте бозылган саналыр, дөрес булмас.

Су үткәрми торган аяк киемнәренә генә мәсех дөрес: күн итек, кәвеш, киез итек кебекләргә.

Читекләргә мәсех йорт эчендә яшәүченең бер көн һәм бер кичә буе читекләрен салмаганда, мөсафир-юлаучыга өч көн һәм өч кичә дәвамында аяк киемнәрен салмый йөргәндә генә дөрес, әгәр дә салса, яңадан юарга тиеш.

Әгәр дә берәүнең аяк киемнәренә су керсә яки юеш җирдә йөрсә, тубыктан түбән бер аягын гына чылатса да, икесен дә, читекләрен салып, тәһарәттә юарга кирәк. Алай эшләмәсә, тәһарәте дөрес түгел.

Мәсех микъдары өч бармак буе исәпләнелә. Ягъни аерым-аерым ике кулны да мәсех тарту өчен чылатасың һәм аерым-аерым өчәр бармак белән читекнең оч башыннан куныччына өч бармак эзе тартасың. Менә шушы рәвеш читеккә өч бармак буе дигән микъдарны белдерә.

Кулларга аерым-аерым су алына. Әгәр дә читеккә бармакларны тидермичә генә су тамызып барсаң, тәһарәтең дөрес саналмый, мәсех үтәлмәгән булып чыга.

Әгәр дә табаны яки үкчәсе тишелгән читектән аяк чыкса, күренсә, мәсех дөрес түгел. Аяк киемнәрен салып, аякларны юарга тиешле.

Әгәр дә бер читегендә өч бармак сыярлык тишек яки сүтелгән җир бар икән, мәсех дөрес түгел. Бу тишек аерым булса да, берничәсе бергә өч бармак сыярлык исә дә, дөрес түгел. Ике бармак сыярлык кына тишек икән, ул вакытта мәсех дөрес санала.

Әгәр дә бер читегендә бер бармак, икенчесендә ике бармак сыярлык тишек бар икән, мәсех дөрес була. Ягъни, әгәр дә читекләрнең икесендә бергә өч бармак сыярлык тишекләр икән, мәсех дөрес санала.

Тишекләр тубыктан югары, куныччта икән, ул вакытта мәсех дөрес.

Әгәр дә бер читегенең үкчәсе кубып, күтәрелеп-күтәреп, табанын күрсәтсә, әмма шул вакытта аяк табаны җиргә тимичә, купкан табаны кире йомылса, мәсех дөрес. Әгәр дә шунда аягы җиргә табаннан чыгып, тиеп китсә, мәсех дөрес түгел.

Читекләренә мәсехенең дөрес булу вакыты тәмамланса, ул кеше тәһарәт алганда аякларын юар, шуның белән тәһарәте тәмам булыр.

Әгәр дә берәү яралы булып, ярасына су тидерү зыянлы исә, ул вакытта мәсех кенә тартыр, шулай дөрес булыр, каны күренсә дә тәһарәте бозылмас.

Әгәр дә ярасы төзәлеп, кутыры коелса, тәһарәт тиешле, чөнки бу вакытта тәһарәте бозылыр.

Әгәр дә ярага су тиюдән зарар юк икән, ул вакытта ярасын юу дөрес, юмаса, тәһарәте бозылыр.

Кемнәрнең тәнендә ярасы төзәлмичә, кан килеп торыр яки борынынннан кан агар һәм башка шуның ишеләр күренер исә, аларны гозер иясе, ягъни игътибарга лаеклы сәбәп иясе санарлар. Әгәр дә болар өч көннән ким яки ун көннән артыкка китсәләр дә сәбәпле булудан туктамаслар.

## ХӘЙЗ МӘСЬӘЛӘСЕ

Хәйз дип хатын-кызларда балигълык яшенә җиткәннән соң аналыктан килә торган кан атала.

Бу кан чир аркасында түгел, илле яшьләренәчә дәвам итә. Хәйзнең азы — өч көн, күбе ун көн дәвамында була. Әгәр дә өч көннән ким яки ун кичәдән артыкка сузылса, ул хәйз аталмый. Мондый вакытта намаз һәм уразадан туктау дөрес түгел. Ул истихазә, күрем дип атала.

Хәйзнең чикләре шәригать хөкемендә ачыкланылган хәл. Аның, ягъни бер хәйз белән икенчесенең арасында иң азы унбиш көн дәвам итә, иң күбенең чикләре юк, күпме булса да ярый.

Әгәр дә бер хатын гадәте буенча биш көн, яки артык, яки ким, дәвамында хәйз кичерә икән, биш көн гадәте булган хатын өчен хәйзнең чикләре

шушы биш көн белән тәмамлана. Бишесе — хәйз, калганы күрем санала. Хәйз вакытында намаз вә уразасын куеп торса, күрем вакытында намаз һәм уразасын калдырмас. Димәк, гадәтеннән арткан кан килү көннәре хәйз дип атала алмый, күрем дип йөртелә. Кан килүе унике көн дәвам итсә дә, ун кичәдән соңгылары күрем көннәре дип хисапланыла, намаз ул калган ике көнендә калдырылмый.

Әгәр дә бер хатын гадәте буенча хәйзне биш көн күреп тә, өч көннән туктаса, бу бәндә әле кан килә дип уйлап намазын калдырса, укылмаган ул көнге намазлары казага калыр, әмма госел таләп ителмәс.

Әгәр дә бер хатын-кыз су төсендәге хәйз күрсә, бу аның өчен хәйз саналмас. Хәйз булу өчен аналыктан килгән канның кызыл, яки кара, яки сары, яки болганчык төстә килүе шарт.

Әгәр дә бер хатын ун көннән ким вакыт эчендә яки гадәтеннән аз кичә үтеп, хәйзем бетте булса кирәк, дип уйласа һәм уразасын дәвам итсә, госел коенса, әмма кан килүе кабаттан беленсә, аның уразасы казага калыр, тоткан уразасы бу көн өчен дөрес булмас.

Әгәр дә бер хатын гадәте буенча җиде көн кан күреп тә, өч көннән тукталса, бу хатын, госел коенып, намаз укыр, әмма тыелып тору көннәре үтмичә, җиде кичәсе кичмичә, ире белән якынлыкка ләззәтләнмәс, гадәт көнен көтәр.

Бала тапканнан соң килгән кан — азына чик юк, күбе — кырык көннән соң. Кырык көн эчендә килмәсә, кырык беренче көндәгесе күрем аталып, намазы дөрес булыр. Әгәр дә кырык көн эчендә, әйтик, җиденче кичәдән кан күреп, аннан тукталса, бу хатын госел коенып, ураза тотса, әмма шушы кырык көн эчендә кан кабат кабатланса, әйтик, унынчы кичәдән, ул вакытта уразасы дөрес булмас, казага калыр.

## ХӘЙЗ ХӨКЕМЕ

Хәйз күргән хатынга намаз уку һәм ураза тоту дөрес түгел. Әмма уразасын соңыннан казага кал-

дырып үтәр, ә намазы казага калмас. Хәйз күрүче хатынга мәсҗидкә керү ярамас, ире белән йоклар, әмма якынлык кылышу тыелыр. Кан күрүче хатын кулына Коръән тотарга тиеш түгел. Шулай ук ул хатын Коръән укымас. Хәйзе тукталганнан соң госел коенуы вәҗиб саналыр.

Бала тапканнан соң шулай ук кырык көн бу алда сөйләнгән әдәпләргә буйсынуы шарт.

## ТӘҺАРӘТНЕҢ БОЗЫЛУ ОЧРАКЛАРЫ

Кешенең алдыннан һәм артыннан чыккан һәртөрле нәрсә, ташмы, кортмы, йомшакмы-сыекмы — һәммәсе тәһарәтне бозалар. Әгәр дә ир кешенең җиле чыкса, тәһарәте бозылмас, әгәр дә хатын-кыздан чыкса, иссез икән, шулай ук тәһарәте бозылмас, исле икән, кабат тәһарәт алуы кирәкле эш. Бу мәсьәлә галимнәребездә сәерсенү уятты. Шунлыктан, күңелләрен тынычландыру өчен бер хәбәрне китереп узыйк: Хуҗа Әхмәд Яссәвинең шәкертләре-мөридләре көннәрнең берендә, үзләрен зур галимгә санап, шәехлек дәгъвасын кыла башлыйлар. Гыйлемебез зур, фатихагызны бирегез, диләр. Әүлия дәрәҗәсенә ирешкән Әхмәд Яссәви, бер эчәккә һава өреп, икенчесенә су тутырып, аларны биленә бәйли. Намаз вакыты ирешә. Сәҗдәгә киткәч, Әхмәд Яссәви шул эчәкләрнең берсенә без төртә. Аннан һавасы чыга. Мөридләре: «Хәзрәтебезнең тәһарәте бозылды»,— дип, тәһарәт яңартырга китәләр. Бары тик Сөләйман Бакыргани һәм тагын берәү генә намазларын хәзрәткә ойган хәлдә дәвам иттерәләр. Икенче сәҗдәдә Әхмәд Яссәви су тутырылган эчәкне дә тишә. Суы агып китә. Алар Сөләйман Бакыргани белән икесе намазны дәвам итәләр. Шуннан Әхмәд Яссәви үзенең мөридләренә әле шәригатьнең серләрен белеп бетермәүләрен аңлатып бирә, димәк, шәехлек дәгъвасын кылырга боларга иртәрәк икән. Ә Сөләйман Бакыргани шәехлек дәрәҗәсенә ирешә. Бу хәбәр — югарыдагы мәсьәләгә бер дәлилләрдәндер.

Авыз тутырып косык чыкса, күңеле укшыса, бу вакытта авызында тыеп калырлык түгел икән, шулай ук тәһарәте бозылыр.

Какырык, әгәр дә корсактан килсә, бер дин галимнәре тәкрарлавына күрә, тәһарәтне бозар, әмма имам Әгъзам белдерүенчә, һичнинди какырык та тәһарәтне бозмас. Шунлыктан какырык тәһарәтне бозмаганлыгы беленер.

Әгәр дә күкрәктән кызыл яки төкерек төсле кан косса, тәһарәте бозылыр, каты укмашкан кан булып, аз икән, бозылмас, авызы тулы кан косса, каты укмашканлыгына карамастан, тәһарәтне бозар.

Әгәр дә тәнендә кан күренеп, үз тирәсендәге урыннарны да кызартса, акса, тәһарәт бозылыр.

Әгәр дә кутырлаган җирнең кутыры кубып, кан яки су кебек сыекчасы яра тирәсенә җәелсә, тәһарәт бозылыр.

Әгәр яра астындагы су тулып торып, читкә агып чыкмаса, таралмаса, ул вакытта тәһарәт бозылмас.

Әгәр дә берәү ярасында күренгән су яки канны читкә агызмыйча өстенә көл яки туфрак сипсә, шул сәбәпле җәелдермәсә, тәһарәт бозылмый. Әгәр дә җәелсә, тәһарәт бозыла, хәтта җәелерлек дәрәҗәдә акса да бозыла.

Әгәр дә авыздан төкерек белән бергә кан төшсә, кан төкеректән аз булса, тәһарәт бозылмас, кан күбрәк исә, бозылыр. Икесе дә тигез исә, ул вакытта тәһарәтне яңарту яхшырак, әмма таләп ителми. Әгәр дә теш арасыннан кан чыкса, кайдан килгәнлеге мәгълүм булса, тәһарәт бозыла, билгесез икән, ул вакытта күплегенә һәм кимлегенә бәйле рәвештә, төкеректән аз булса, тәһарәт бозылмый, күп исә, бозыла, тигез дәрәҗәдә икән, үзеңә карыйсың. Юынып алуың зыянга түгел.

Әгәр дә берәүнең күзеннән һәрдаим яшь акса яки кан акса, сары һәм башкалар, шулай ук колагыннан акса, күкрәгеннән, кендегеннән, борыныннан, ул вакытта һәр намаз алдыннан тәһарәт алу таләп ителә. Бер алынган тәһарәт берничә намазны үтәү өчен җитмәс.

Хәйз күрүче хатын, җаен табып, канны тышка чыгудан туктатса, ул һаман да хәйз күрүче дип хисапланыр. Әгәр дә бер яралы кеше дару һәм башка чара белән кан агуын туктатса, ул кеше намазлы саналыр һәм намаз укуы шарт булыр.

Әгәр дә берәүнең тәнендә чәчәк яки бетчә булып, аны сытса, яңадан тәһарәт алыр, тагын да башкасын сытса, яңадан сафланып юыныр, чөнки алар аның тәнен аерым-аерым пычратырлар.

Әгәр дә берәүнең ярасыннан яки башка җиреннән кан яисә бүтән сыекча һаман да ага икән, ул вакытта бу кеше тәһарәт алып, намаз укыр. Әмма намаз ахырында кан яки сыекча агудан туктаса да, намазы дөрес булыр.

Әгәр дә берәү сәбәпле булып та, тәһарәт алганнан соң тәнендә сыекча вә кан таралмыйча, сафчиста хәлендә намаз укыганда кан яки сыекча күренсә, тәһарәте бозылып та, намазы кайтарылмас, дөрес саналыр. Сәбәпле булуы аркасында шулай.

Әгәр дә берәүнең борынынннан кан агып тамса, тәһарәте бозылыр, ә инде оеган кан төшсә, бозылмас. Чөнки кан оегач, аның кан сыйфаты, чисталыкны бетерүе югалган була. Тәһарәтне сыек кан гына боза.

Әгәр берәү намаз укыганда аяк өсте, яки рөкүгъта, яисә сәҗдәдә, йә әттәхияттә йокласа, тәһарәте бозылмый. Әмма сәҗдәдә сөннәтчә түгел икән, бозылыр. Ягъни корсагын ботына терәмичә, беләк һәм кулларын ачык куеп, ян-ягына тидермичә йокласа, тәһарәте бозылмас, әгәр шушылай итмичә, ишелеп йокласа, бозылыр. Шулай ук намаздан соң йокласа, тәһарәте бозылыр.

Әгәр дә бер кеше намаздан соң тезләнеп, яки аяк бөкләп утырып, яисә янбашларын куеп, тезләрен кадап, башын ике тезе арасына яки өстенә куеп йокласа, тәһарәте бозылмас.

Әгәр дә бер кеше әлеге сөйләнгән рәвештә йокласа һәм кинәт җиргә авып егылса, тәһарәте бозылыр, җиргә төшеп җиткәнче уянып китсә, бозылмас. Шуның өчен дә намазсыз вакытында саклануы шарт, әгәр дә мөмкин түгел икән, тәһарәтен яңартуы шарт, мөстәхиб.

Әгәр дә берәү иярсез генә ат яки хайван өстендә барганда таудан түбән төшкәндә йокласа, тәһарәте бозылыр, үр-тауга менгәндә яисә тигез җирдә икән исә, бозылмас.

Әгәр дә иярле хайван өстендә булса, тәһарәте һичбер сурәттә дә бозылмас.

Әгәр дә берәүнең һушы китсә, диваналык галәмәте күренеп алса яки исерсә, тәһарәте бозылыр. Исерү төрлечә булып, ис тиюдән дә килергә мөмкин. Шунлыктан исереклекнең чиген йөрәкнең әрлебирле килүе белән ачыкларлар.

Әгәр дә бер кеше рөкүгъ халәтендә, яки сәҗдәдә, яки намаз вакытында көлсә, көлгәне икенче берәүгә ишетелсә, намазы һәм тәһарәте бозылыр. Әгәр дә үзе генә ишетсә, белеп калса, ул вакытта тәһарәте бозылмас, намазы бозылыр. Җеназа намазында һәм сәҗдәи тилавәттә кеше янында ишетелерлек итеп көлсә дә тәһарәте бозылмас.

Әгәр дә бер кеше тәһарәтле кеше буларак чәчен алдырса яки тырнагын киссә, чәченең алынган җиренә мәсех һәм киселгән тырнак астын юу таләп ителми, тәһарәте бозылмый.

Әгәр дә бер кеше үзенең тәһарәте бозылганлыкка шик белдерсә һәм тәһарәтем бозылдымыюкмы дип аптырауда калса, ул бәндәнең тәһарәтен шиксез яңартуы таләп ителмәс. Әмма бу очракта бу кешенең алдан чыннан да чистарынганлыгын белеп торуы шарт.

Әгәр дә бер кеше үзенең тәһарәт алганлыгын хәтерләмәсә, әмма: «Тәһарәтем бозылдымы-юкмы икән?» — дип аптыраса, тәһарәт яңартуы сорала.

Әгәр дә бер кеше тәһарәт алган вакытында югалып калса, кайсы җирен юганлыгын яки юмаганлыгын онытса, ул бәндә сул аягын юарга тиеш, шуннан тәһарәтле исәпләнер.

Әгәр дә берәү үзенең кайсы җирен юганлыгын төгәл белеп тә, чистарганлыгына шикләнсә, ул шушы әгъзасын яңадан юарга тиеш дип таләп ителми. Тәһарәтнең үз тәртибе белән тәмам булуы шул әгъзасын юганлыгын да исбатлар.

Тәһарәте юк кешегә Коръән һәм аять язылган китап-кәгазьләрне тоту һәм тоттыру, мәсҗидкә керү һәм кертү дөрес түгел.

Хатын-кыз белән якынлык кылганнан соң коенмаган кешегә, хәйз һәм күрем күргән хатын-кызга Коръән һәм аять язылган язу-китаплар тоту хәрәм санала, тыела.

## ТӘҺАРӘТ ТӘРТИПЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАРЫ

Тәһарәт алган вакытта догалар уку үзләренә күрә әдәп кагыйдәләреннән санала. Һәр әгъзаны юган вакытта догалар белән җан вә күңелләрне хушландыру бик тә саваплы. Әгәр дә тәһарәт догаларын гарәпчә әйтә алмыйсың икән, ул вакытта үз телеңчә-татарча кылсаң, һичбер хилафлык юк.

1. Тәһарәттә иң әүвәл кулларны юганда укыла торган дога:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى جَعَلَ الْمَاءَ طَهُورًا وَجَعَلَ الْاِسْلَامَ نُورًا بِسْمِ اللّٰهِ الْعَلِىِّ الْعَظِيمِ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ عَلٰى دِينِ الْاِسْلَامِ وَعَلٰى تَوْفِيقِ الْاِيمَانِ وَعَلٰى هِدَايَةِ الرَّحْمٰنِ ۞

*Әл-хәмдү лиллаһил-ләзи җәгаләл-маә таһүран вә җәгаләә исламә нуран, бисмилләһил-галлиил-газыйм вәл-хәмдү лиллаһи галә динил-ислам вә галә тәүфыйкыл-иман вә галә һидайәтир-рахман*

Мәгънәсе: «Аллаһыга шөкер һәм рәхмәтләрдер. Ул Аллаһы тәгалә суны пакьләндерүче итеп кылды, Исламны нур кылды. Олуг булган Аллаһы тәгаләнең исеме белән башлыйм тәһарәт алырга. Ул Аллаһы тәгаләгә бик күп рәхмәтләремне әйтәмен — Ислам динендә кылганлыгына, иман биргәне өчен һәм дә хак юлга күндергәненә!». Димәк, бу догада иң элек Аллаһы тәгаләгә рәхмәт вә мактауларыңны җиткерәсең, суның саф-чиста булуына сөенеп, аннан соң «Бисмилләһ...» әйтәсең, тәһарәт ала башлауны ниятлисең һәм Ислам динендә булганлыгыңа, иманлы кылынуыңа, хак юл-

ны табуыңа сөенеч һәм рәхмәтләреңне белдерәсең. Боларны көнкүреш телендәге сүзләрең белән үзеңчәләп әйтсәң дә, чын йөрәктән чыкса, Аллаһы тәгалә каршында кабул булыр.

2. Ике кулны юганнан соң авызга су алыныр һәм шунда ошбу дога укылыр:

اَللّٰهُمَّ اَسْقِنِى مِنْ حَوْضِ نَبِيِّكَ كَأْسًا لَا اَظْمَأُ بَعْدَهُ اَبَدًا ❀

*Аллаһүммә әскыйни мин хәузый нәбиййикә кә-әсән лә азма-у бәгъдәһү әбәдә*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, мине пәйгамбәребез коесыннан эчерсәң иде, аннан эчкәннән соң мәңге сусамамын!»

3. Моннан соң борынга су тартылыр һәм шушы дога укылыр:

اَللّٰهُمَّ اَرِحْنِى مِنْ رَائِحَةِ الْجَنَّةِ وَ اَرْزُقْنِى مِنْ نَعِيمِهَا وَلَا تُرِحْنِى مِنْ رَائِحَةِ النِّيرَانِ ❀

*Аллаһүммә арихни мин раихәтил-җәннәти вә арзукъни мин нәгыймиһа вә лә турихни мин раихәтин-нииран*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, мине оҗмах исләре белән хушландыр, оҗмах нигъмәтләреннән ризыкландыр, тәмуг исләрен иснәттермә!»

4. Шуннан соң йөзне юарбыз һәм шушы доганы укырбыз:

اَللّٰهُمَّ بَيِّضْ وَجْهِى بِنُورِكَ يَوْمَ تَبْيَضُّ وُجُوهُ اَوْلِيَائِكَ وَلَا تُسَوِّدْ وَجْهِى يَوْمَ تَسْوَدُّ وُجُوهُ اَعْدَائِكَ ❀

*Аллаһүммә бәййиз вәҗһи бинурикә йәүмә тәбйәззу вөҗүһү әүлийәикә вә лә түсәувид вәҗһи йәүмә тәсвәдду вөҗүһү әгъдаикә*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, йөземне ак кыл — үзеңнең нурың белән өртелгән әүлияларыңның йөзләре ак булган көндә, минем йөземне кара кылма — дошманнарыңның йөзе кара булган көндә!»

5. Шушыннан соң, тәһарәт алыну буларак, уң кул юылыр һәм бу вакытта ошбу дога укылыр:

اَللّٰهُمَّ اَعْطِنِى كِتَابِى بِيَمِينِى وَحَاسِبْنِى حِسَابًا يَسِيرًا ۞

*Аллаһүммә әгътини китаби бийәмини вә хасибни хисабан йәсира*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, минем гамәл дәфтәремне уң кулыма бир, мине җиңел хисап белән хисап кыл!»

6. Уң кулдан соң сул кулга тәһарәт алыныр һәм шушы доганы укыганда әдәп булыр:

اَللّٰهُمَّ لَا تُعْطِنِى كِتَابِى بِشِمَالِى وَمِن وراء ظهرى
وَلَا تُحَاسِبْنِى حِسَابًا شَدِيدًا ۞

*Аллаһүммә лә түгътыйни китаби бишимали вә лә мин вәра-и заһри вә лә түхасибни хисабан шәдийдә*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, минем гамәл дәфтәремне караңгы йөзең белән (усал карап) бирмә, бәлки йөзеңне ачык-якты тотып бирсәңче һәм дә хисабымны каты-авыр итмәсәңче!»

7. Моннан соң башыңа мәсех кыласың һәм бу доганы укыйсың:

اَللّٰهُمَّ حَرِّمْ شَعْرِى وَبَشْرِى عَلَى ٱلنَّارِ وَاَظِلَّنِى
تَحْتَ ظِلِّ عَرْشِكَ يَوْمَ لَا ظِلَّ اِلَّا ظِلُّكَ ۞

*Аллаһүммә харрим шагъри галән-нари вә азыйлләни тәхтә зыйллли гаршикә йәүмә лә зыйллли иллә зыйллүкә*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, минем тәнемне һәм чәчләремне тәмуг утына хәрәм кыл һәм дә мине күләгәләндер — гаршенең күләгәсе астында, шул көндә бүтән һич күләгә юк, бары тик Синең гарше күләгәң генә».

8. Моннан соң колакларыбызны мәсех кылып, шушы доганы укырбыз:

اَللّٰهُمَّ اجْعَلْنِى مِنَ الَّذِينَ يَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَيَتَّبِعُونَ أَحْسَنَهُ

*Аллаһүммә-әҗгални минәл-ләзинә йәстәмигунәл-каулә фәйәттәбигунә әхсәнәһ*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, мине шундый адәмнәрдән кыл, алар кушылган сүзләрне-әмерләрне ишетерләр, ул эшләрнең кайсы әҗердә артык, шуңа ияререләр, шуны кылырлар».

9. Муенга мәсех кылыныр һәм бу дога укылыр:

اَللّٰهُمَّ اَعْتِقْ رَقَبَتِى مِنَ النَّارِ وَاحْفَظْنِى مِنَ السَّلَاسِلِ وَ الْاَغْلَالِ

*Аллаһүммә әгътикъ рәкабәти минән-нари вә әхфазни минәс-сәласили вәл-әгълал*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, минем муенымны уттан азат кыл һәм мине сакла зынҗырлардан һәм богаулардан».

10. Уң аякны юган вакытта бу дога укылыр:

اَللّٰهُمَّ ثَبِّتْ قَدَمَىَّ عَلَى الصِّرَاطِ يَوْمَ تَزِلُّ فِيهِ الْاَقْدَامُ

*Аллаһүммә саббит кадәмәййә галәс-сирати йәүмә тәзиллү фиһил-акъдам*

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, минем аякларымны Сират күперендә, аяклар тайган көндә, ягъни Кыямәт көнендә ныклы теркле кыл».

11. Моннан соң сул аяк юылыр, ә догасы — шушы:

اَللّٰهُمَّ اَجْعَلْ سَعْيِى مَشْكُورًا وَ زَنْبِى مَغْفُورًا وَ عَمَلِى مَقْبُولًا وَ تِجَارَتِى لَنْ تَبُوْرًا ۞

*Аллаһүммә-әҗгал сагйи мәшкүрән вә зәнби мәгъфуран вә гамәли мәкъбулән вә тиҗарәти лән тәбурә*

Татарчасы: «Йа Аллаһы тәгалә, минем эшемне шөкер итәрлек кыл, гөнаһларымны ярлыкалмыш кыл, гамәлемне кабул кылынмыш кыл, минем теләкләремне һәлакәткә чыгарма».

Тәһарәт тәмам ителеп, шушы дога укылыр: «Аллаһүммә-әҗгални минәт-тәүвабинә вә-әҗгални минәл-мөтәтаһһиринә вә-әҗгални минәл-ләзинә лә әүфүн галәйһим вә лә һум йәхзәнүнә».

Мәгънәсе: «Йа Аллаһы тәгалә, мине тәүбә кылучылардан ит, мине пакьләнүчеләрдән кыл һәм дә изге колларыңнан һәм дә шундый кешеләрдән, кемнәргә куркыныч һәм кыенлык юк».

Болардан соң ахырда «Кәүсәр» сүрәсе:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۞

اِنَّا اَعْطَيْنٰكَ الْكَوْثَرَ ۞ فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ۞ اِنَّ شَانِئَكَ هُوَ الْاَبْتَرُ ۞

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Иннә әгътайнәкәл-кәүсәр. Фәсалли лираббикә вәнхар. Иннә шаниәкә һүвәл-әбтәр*

Мәгънәсе: «Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы тәгалә исеме белән! Чыннан да, без сиңа кәүсәр бирдек. Син дә Раббыңа намаз кыл һәм корбан чал. Чыннан да, имансызлар синнән көнчелек итеп нәфрәтләнә бирсеннәр»,— дип укылып, битләрне һәм башка юылган әгъзаларын сөлге белән корытыр, кәлимәи шәһадәтне әйтер:

اَشْهَدُ اَنْ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

*Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ* — дип. Шулар белән тәһарәт тәмам ителер.

Әгәр дә берәүнең юылган әгъзаларында чак кына коры җир калса да, шул әгъзаның сулырак җирендәге суы белән ул коры җирен юешләр яки тәһарәтен яңартыр. Йөзендәге коры җирне аягындагы яки башка әгъзасында чыланып калган су белән юешләргә ярамас. Шулай ук юылган җирдән су тамызу һәм чәчрәтү дә әдәпсезлек, сак булырга кирәк. Бүтән кешенең тәһарәтен бозуың бар.

Тәһарәт алу ул үзеңне генә түгел, башкаларны да сафлыкка өндәү һәм аларны да сафландыру икәнлеген онытмаска кирәк. Хәтта мунча кергәндә дә ләгәндәге яки чиләктәге суга үз тәнеңнән тир яисә суны тамызудан сакланырга кирәк, чөнки, шәригать кануннары буенча, синең тәнеңнән тамган бер тамчы чиләктәге суны сидек хәленә кертә.

## ТӘЙӘММҮМ МӘСЬӘЛӘСЕ

Әгәр дә бер-бер кешегә госел яки тәһарәт алу тиешле күрелеп тә суы булмаса яки авыруы бар икән, ул вакытта аңа туфрак яисә туфрак җенесеннән саналган тузан белән пакьләнү тиешле күреләһәм моны тәйәммүм//тәяммем дип атыйлар.

*Дәлиле:* *Фәләм тәҗидү мә-ан фәтәйәммәмү сагыйдән таййибән* аяте.

Мәгънәсе: «Әгәр дә сез су тапмасагыз, чиста булган туфрак җенесенә тәйәммүм кылыгыз».

Тәйәммүмнең *ике* фарызы бар. Аның *берсе* — шарт, ягъни ниятеңне белдерү. «Ният иттем пакьләнмәккә», — дип әйтү. Фарызның *икенчесе* — «рөкен» дип атала. Монсы шуннан гыйбарәт: ике кулыңны да ике тапкыр чиста туфракка яки тузанга сугып, беренче тапкырында — йөзне, икенчесендә терсәкләрең белән кулларыңны чистарту, мәсех

итү. Тәйәммүм тирләп суы аккан тәнгә дөрес булмас, тирнең кипкән булуы яхшы.

*Тәйәммүм түгыз очракта дөрес була:*

1. Тәһарәт яки госелгә фарыз кадәрле су булмаган очракта.

2. Су бөтенләй булмаса.

3. Су дүрт чакрым ераклыкта булса.

4. Су булып та, су белән юынырга көче җитмәсә, зәгыйфьлек һәм сырхаулык очрагында.

5. Су булып та, әгәр дә суны файдаланганда сырхавы арту яки үлем булуы куркынычы янаса, ягъни су белән юынудан сихәтенә зыян килсә.

6. Су булып та, суны тотса, эчәренә һәм хайванына су калмаслык исә, тәйәммүм итәр.

7. Су юлы өзелсә яки су белән бу кеше арасында юлбасарлар булса.

8. Су булып та, суны алырга көче һәм чарасы юк исә, ягъни коедан күтәрү өчен чиләге яки бавы булмаса.

9. Суның барлыгын оныту аркасында.

Тәйәммүм итүнең сурәте болардан гыйбарәт: иң әүвәл ният итеп, ике кулларын да пакь-коры туфракка яки туфрак җенесеннән булган нәрсәгә бер тапкыр орып, кулларны күтәрәсең дә баш бармакларны бер-берсенә терәп селкисең һәм ике кул белән йөзне мәсех итәсең.

Моннан соң тагын да ике кулыңны да туфракка яки туфрак җенесендәге нәрсәгә орасың да селкисең, аннан соң, баш бармагыңны тидермичә, дүрт бармагыңның очларыннан алып терсәк турына кадәр сыпырып үтәсең, шул вакытта уң кулыңның уч ягын ачып, сул кулыңның баш бармагының яртысыннан түбән өлеше белән уң кулыңның эчке ягын мәсех итәсең, очына таба үтеп, сул кул баш бармагыңның калган ярты өлеше белән уң кул баш бармагыңның өске ягын мәсех итәсең. Шуннан соң инде сул кулыңны мәсех итүгә күчәсең һәм шулай ук эшлисең. Уң кулыңның дүрт бармагы белән сул кулыңның дүрт бармагын очаларыннан алып терсәк астына кадәр мәсех итеп күтәрәсең дә уң кулыңның баш бармагының аскы өлеше, икенче яртысы белән иң элек сул кулыңның баш бармагы

уч ягын мәсех кыласың, калган өлеше белән арка ягын сафландырасың. Шулай итеп туфрак сиңа чисталык бирә. Бер генә урыныңны да, тәйәммүм кыла торган әгъзалардан, һич тә мәсех кылмыйча калдырмыйсың. Әгәр дә йөзегең бар яки беләзек кигәнсең икән, аларны салып, тәйәммүм итү тиешле күрелә.

Әгәр дә бер кеше тәйәммүм кылып, намазга тотынган вакытта берәр балигъ зат яки камил акыллы кеше: «Су бар!» — дип хәбәр бирсә, ул вакытта намазга тезләнүче, туктап, намазын бозар һәм камил рәвештә тәһарәт яңартып, намазга бөгеләр. Бу вакытта суның тәһарәткә җитәрлек булуы шарт. Хәбәр бирүчеләр дә дивана түгел, камил һәм гадел акыллы затлардан саналырга тиешләр.

Әгәр дә: «Су бар!» — дип хәбәр бирүче кеше сабый яки акылга таман һәм гаделсез икән, ул вакытта намазын укып бетерергә тиеш. Тәйәммүм белән укылган намаз бу очракта дөрес була. Әгәр дә инде шушы хәбәрне намазы укылып беткәннән соң ишетсә, ул очракта шулай ук укылган намазы дөрес була. Әгәр дә яралы кешенең яраларына тәйәммүм итүдән зыян килерлек булса, ул вакытта сафландыра торган тәһарәт урыннарының өстенә әйбер каплап тәһарәт алыныр.

Әгәр дә тәһарәт алына торган әгъзаларының бер өлеше таза, калган җирләре яралы булса, ул кеше ярасыз урыннарын юар, яралы җирләрен мәсех итәр.

Әгәр дә берәүнең гәүдәсенең яртыдан күп өлеше яралы булса, ул вакытта аның өчен су булу-булмауга карамастан тәйәммүм дөрес санала. Әгәр дә тәненең ярты өлеше яралы, яртысы ярасыз икән, ул вакытта ул кемсәнә яралы җирләрен мәсех кылыр, калган ярты өлеш тәнен юар. Госел вә тәһарәте шулай дөрес булыр.

Әгәр дә бер кеше: «Иптәшемдә су бар, әмма тәһарәт өчен бирмәс шул!» — дип фикерләп тәйәммүм кылса, намаз укыса, намазы дөрес була. Әмма шунда, намазы укылып беткәч, иптәше: «Миндә су бар иде бит, нигә сорамадың? Бирә идем!» — дисә, әмма намаз вакыты инде чыккан булса, намазы дөрес була. Әгәр намаз вакыты үтмәсә, суын алып,

камил тәһарәт үтәп, намазын уку тиешле. Әгәр дә: «Иптәшемнең суы бар. Сорасам, бирер!» — дип уйлап та, тәйәммүм итеп, намазын укыса, дөрес булмас. Әгәр дә инде иптәше шунда сорап та, мөселманнар өчен бу гайре табигый хәл, су ала алмаса, юлдашы мәхрүм итсә, ул вакытта тәйәммүм кылып намаз укуы дөрес һәм кабул санала.

Әгәр дә бер бәндә үзен тәһарәтсез белеп, мәсҗидтән тышкы якта су таба алмаса, ул кеше тәйәммүм итеп, мәсҗидкә керер һәм су алып чыгып, госел коеныр, тәһарәт алыр. Билгеле булганча, сафланмаган-пакьләнмәгән килеш мәсҗидкә керү тиеш эш түгел.

Әгәр дә бер кеше су юк җирдә Коръән уку өчен, җеназа һәм нәфел намазлары өчен тәйәммүм итә икән, аның өчен фарыз намазларына да шушы тәйәммүме дөрес була.

Су булган җирдә бер кеше тәһарәт алырга өлгермәслеген белеп җеназа өчен тәйәммүм итсә, аның пакьләнүе дөрес була, әмма бу тәйәммүм белән фарыз намазларын укуы дөрес түгел, ярамас. Шунлыктан фарыз намазлары өчен тәһарәт яңартуы кирәк саналыр.

Коръән уку өчен яки Коръән тоту, өйрәтү, мәсҗидкә керү кебек теләкләрен үтәү өчен бер кеше ниятләнеп тәйәммүм итсә, бу тәйәммүме шушы эшләрен үтәүгә дөрес, әмма намаз уку өчен ярамый. Бу очракта намаз өчен аерым ниятләнелгән тәйәммүм таләп ителер.

Әгәр дә бер кеше зинданга салынса, әмма тәһарәт өчен су бирелмәсә, тәйәммүм кылып намазын үтәсә — яхшы. Аның бу намазлары дөрес булыр, соңыннан, зинданнан азат кылынгач, ул намазларын кайтарса, бик яхшы, әмма кайтармаса да ярый.

## НАМАЗНЫҢ ИКЕНЧЕ ШАРТЫ — НӘҖАСӘТТӘН ТӘҺАРӘТ

Намазның *икенче* шарты — нәҗасәттән тәһарәт, ягъни шакшылыктан азат булу, пөхтәлек.

Әгәр дә намаз укый торган кешенең тәнендә, яки киемендә, яисә намаз укый торган җирендә, аерым-аерым яки бергә тимер акча зурлыгында гына булса да нәҗес бар икән, аның намазы дөрес саналмый. Бу нәҗес тимер акчадан кимрәк икән, аны юсаң, важиб, тагын да аз исә, чистарту — сөннәт вә әдәп санала. Шунлыктан нәҗесне бетерү, чистарту вә чистарыну шарт булып тора.

Нәҗасәт *ике* төрле була. Аның беренчесе — каты нәҗес, икенчесе — йомшак яки сыек нәҗес дип атала.

Нәҗасәтнең бер ишләрен нәҗасәт гализ дип, икенчеләрен нәҗасәт хәфиф дип йөртәләр.

*Нәҗасәт гализ* булган вакытта бу нәҗесләр үзләре шулай ук ике төрлегә бүленәләр. Аларның беренчесе — сыек нәҗес, икенчесе — куе нәҗес дип йөртелә.

Куе нәҗес булган вакытта алар болардан гыйбарәт: адәм һәм дә ите ашалмый торган хайваннарның тизәкләре, дуңгыз һәм этнең, тавык, үрдәк, казныкы, аеры тырнаклы ерткыч җәнлекләрнең нәҗесләре.

Шушы тизәкләр тимер акчадан авыррак дәрәҗәдә киеменә, тәненә, намаз җиренә буялса, юарга кирәк, ким исә, юу важиб, тагын да кимрәк буялса, юу — сөннәт санала. Гомумән дә, тизәккә буялганда, юып алу бик мәслихәт күрелә.

Сыек нәҗасәт гализ булганда алар шуннан гыйбарәт: адәм һәм ите ашалмый торган хайваннарның алдыннан чыккан сыекчасы, сидеге, этнең, дуңгызның тире, каны, сыекчасы, аракы кебек исерткеч эчемлек сулары.

Әгәр дә бу сыек нәҗасәт уч төбе кадәрдән артыграк җиргә, киеменә, тәненә, намаз укый торган урынына тигән булса, аларны юарга кирәк. Кимрәк, ягъни уч төбе кадәрле генә тигән икән, юу — важиб санала. Тагын азрак тигән икән, юу — сөннәт вә әдәп күрелә.

*Нәҗасәт хәфиф* шулай ук ике төрле, сыек һәм куе була.

Куе булган нәҗасәт хәфиф дөянең, сарыкның, куйның, кәҗәнең, атның һәм ите ашалмый торган кошларның тизәге.

Сыек булган нәҗасәт хәфиф—ите ашала торган хайваннарның сидеге.

Күгәрчен, чыпчык һәм шулар кебек тизәкләре сасы исле булмаган кошларныкы—чиста, нәҗес саналмый.

Әгәр шушы нәҗасәт хәфиф кешенең киеменең яки намаз укый торган урынының дүрттән бер өлешенә тисә, ул киемнең зурмы-кечкенәме икәнлегенә карамастан, аларны юарга кирәк, юкса нәҗес санала һәм тәһарәт вә сафлану таләп ителә. Әгәр дә болардан да азрак өлеше пычранса, юу важиб һәм сөннәт хисабында йөри.

Киемнәрне һәм намаз урынын нәҗасәттән пакьләгәндә шушы шакшылыкларның исе һәм төсе тәмам беткәнчегә кадәр юарга кирәк. Әгәр дә ис яки төсе калса, пакьләнмәгән исәпләнелә.

Әгәр дә күренми торган нәҗасәттән сидек һәм аракы кебек нәрсәләр кием яки намазлыкка тамган һәм шакшыландырган булса, аларны өч тапкыр юарга кирәк. Һәр юганнан соң тамчысы да калмаслык итеп сыгу таләп ителә. Тәмам сыгылып бетмәсә, юылганлыгы шик астында кала.

Кием-салым юучылар шуны белергә тиешләр, нәҗасәтле өс-баш белән бергә нәҗасәтсез киемнәрне бергә салып җибәтергә һәм бер тагаракта бергә юарга ярамый. Чөнки нәҗасәтле кием җибәгән су нәҗасәтсезне дә пычратыр, шунлыктан барсын да өчәр кат юу таләп ителер. Әгәр дә бер генә тамчы суы да сыгылмыйча калса, ул кием белән намаз уку дөрес булмас. Гомумән, күлмәк-чапан белән бер суда һәм тагаракта ыштан кебек әйберләр бергә юылырга тиеш түгел. Чөнки ыштанга сидек тамган булуы мөмкин һәм шулай ук, ис сеңгән киемне ис сеңмәгәне белән бергә бер тагаракта һәм бер үк су белән юарга ярамый. Шулай да чиста өс-башны юган суда шакшысын юу дөрес исәпләнелә. Керләнгән киемне нәҗесләнгән дип уйлау дөрес түгел, нәҗесләнгән киемсалым ул тизәк һәм сидектән шакшыланган өсбаш. Аларны юганда да үзара бутарга киңәш ителми. Керләнгән киемне юып сыкканда соңгы тамчысына кадәр сыгу соралмый.

## НАМАЗНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ШАРТЫ—ГАУРӘТ ҖИРЛӘРНЕ ЯШЕРҮ

Намазның *өченче* шарты—гаурәт җирләреңне намаз укыган вакытта яшерү-каплау.

Гаурәт җирләрне каплау—намаз вакытында ирләргә кендек астыннан алып тез астына кадәр булган бар урыннарын каплау-яшерү, ягъни кием астында калдыру ул.

Азат-ирекле хатыннарның йөзе, куллары һәм аякларыннан кала барлык җирләре дә гаурәт санала. Хәтта чәче дә гаурәт, аны каплау, бөселеп китмәслек итеп яулык белән җыеп куярга тиешле. Кайбер китаплар хатын-кызларның хәтта кул аркаларын да гаурәт дип күрсәтәләр, шунлыктан кулларының аркаларын да яшергәндә начар булмас, шулай ук аяклары да гаурәт дип бәхәс кылучылар бар. Шуның өчен дә аларга яланаяктан намаз уку килешеп бетмәс. Тагын да шул билгеле булсын, хатын-кызларга муеннарын да яшерү тиешле эш, фарыз гамәлләрдән санала. Ачык муен, яланаяк, ачык кул аркасы белән намаз уку, әдәп вә сөннәтне саклау йөзеннән, аларга киңәш ителми. Шулай да ачык йөз, аяк, кул капланмау мәсьәләсе бәхәсле булып, капласаң-капламасаң да ярый. Әмма гөнаһ шомлыгы булу аркасында ул урыннарыңны да кием астына яшерү яхшыдыр.

Гаурәт җирләрне кием астына яшерү, караңгыда-яктыда укуыңа карамастан, һәртөрле очракта фарыз һәм төп шартларның берсе икәнлеген һичкайчан онытырга ярамый.

Әгәр бер кеше, хатын яки ир булуына карамастан, намаз укыган вакытында гаурәт җирләренең дүрттән бер өлеше ачылып, өч тапкыр: «Сөбханаллаһ»—дигән кәлимәне әйтер кадәр вакыт ябылмыйча торса, ул чакта укыган намазы бозык саналыр. Әйтик, чәчләрнең дүрттән бер өлеше ачылса да, тезләренә таба дүрттән бер өлеш киеме күтәрелсә яки беләкләренең дүрттән бер өлеше ачылса да, өч тәсбих әйтерлек вакыт шулай калса, намазы бозыла. Әгәр бер кулы белән тиз ара ябарга өлгерсә, намазы төзек кала, бозылмый.

## НАМАЗНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ ШАРТЫ—КЫЙБЛА

Намаз укыган кешенең йөзе һәм күкрәге *кыйбла* тарафына, ягъни Кәгъбәи-шәрифкә төбәлергә, каршы торырга тиешле. Әгәр дә беленми торган урында укый икән, белгән кешедән соравы тиешле.

Әгәр дә бер кеше намаз укыганда кыйбланы белмәсә, сорарга һичкемне тапмаса, ул вакытта һәртөрле галәмәтләрдән тикшереп, кояш вә табигатьтәге башка төрле җисем вә күренеш, үсемлекләрдән карап төшенер һәм: «Кыйбла шушында булырга тиеш!»—дип ниятләп укыр, намазы дөрес саналыр.

Әгәр дә намаз укыган вакытында кыйбла ягы беленсә, ул чакта билгеле тарафка борылып басар һәм намазын дәвам итәр, намазы бозылмас, кабаттан башлап уку таләп ителмәс.

Әгәр дә берничә мөселман бергә намаз уку өчен ниятләнеп тә кыйбла мәсьәләсендә бәхәскә керсәләр, ул вакытта һәркайсы үзләре дөрес санаган якка йөз вә күкрәк куеп намаз укырлар һәм һәркайсыныкы дөрескә саналыр. Соңыннан: «Син дөрес якка карап укымадың, намазың кабул түгел!»—дип бер-берсеннән көлү яки шаярту килешмәс, иң яхшысы, әгәр дә барсы бергә бер тарафны килешеп ниятләп, җәмәгать ясап намазларын укысалар, яхшы булыр.

Әгәр дә бер мөселманның кыйбла тарафына борылырлык көч-куәте вә сихәтлеге җитмәсә, яки ярдәм итәрлек кешесе янында булмаса, яки үзенә зыян килерлек дошман тарафы артында калырлык исә, яки ерткыч хайваннан хәвеф күрелсә, кыйбла тарафына борылмыйча, көче җиткән якка яки уңае килгән тарафка карап намаз укыса, кыйбласы андый кешеләр өчен дөрес була, намазы кабул кылына, шарт үтәлгән исәпләнелә.

Әгәр дә бер кеше һичбер сәбәпсез онытылып яки башбаштакланып, белгән өстенә кыйбладан үзгә тарафка борылса, андый вакытта намазы бозылыр.

Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытында кыйбла тарафыннан башын борып читкә карапа,

аның намазы бозылмас, әмма бу гамәле бик каты мәкруһ исәпләнелер.

Әгәр дә бер кеше ялгыш тарафны ниятләп һәм кыйбла тотып, намазын укып бетергәч кенә кыйбланың дөрес тарафын төшенеп һәм белеп алса, аның намазын кабатлавы таләп ителмәс, намазы бозылган дип исәпләнелмәс.

Әгәр дә бер мөселман сорарга кешесе булып та белешмичә намаз укыса һәм кыйбла тарафы туры килсә, намазы тәмам була. Әмма дә шул сорарга мөмкин булган кешедән сорамыйча һәм үзе дә ялгыш тарафны кыйбла тотып укыса һәм ялгышы билгеле булса, аның намазы дөрес исәпләнелми, яңадан намаз укуы таләп ителә. Шунлыктан, сорар кеше барында кыйбла тарафын белешү кирәк эш.

Әгәр бер кеше намазын укып бетергәч кыйбла тарафы дөреслегенә шикләнсә һәм хатасы ачык дәлил белән мәгълүм булса, намазын киредән кайтарып укыр, ягъни яңадан кабатлар һәм кыйбла тарафын дөреслек буенча тотар. Әгәр дә инде ачык дәлил күренмәсә, намазы дөрес саналыр һәм кайтарылмас.

Кыйбланы эзләү фарыз гамәлләрдән исәпләнелә. Әгәр дә бер кеше кыйбла тарафының дөреслеген эзләмәсә, галәмәтләрне тикшермәсә, кешедән сорашмаса вә белешмәсә, ачыкламаса, мөмкин булган тәкъдирдә, әлбәттә, ул бәндәнең укыган намазы дөрес саналмас. Тикшерү һәм эзләнеп ачыклау фарыз. Хәтта аның укыган намазы очраклы рәвештә генә дә кыйбла тарафына туры килсә дә, намазы дөрескә чыкмас. Яңа урынга килдең исә, кыйбланы сорап белешү фарыз гамәлләрдән исәпләнелә, әгәр дә һичкем белмәсә, галәмәтләрдән ачыклау мөмкин күрелмәсә генә намазы дөрес була.

Әгәр дә намаз укыла торган урын каршысыннан кешеләр йөрерлек булса, бер аршин биеклегендә, бармак юанлыгы таякны алдына кадап кую тиешле. Җәмәгать белән укыганда исә шушындый таяк имам каршысына кадап куела.

## НАМАЗНЫҢ БИШЕНЧЕ ШАРТЫ — ВАКЫТЛАР

Намазның *бишенче* шарты буларак аларның башланган һәм тәмамланган ахыргы вакытларын дөрес итеп белү фарыз. Һәр намазның үзенә аерым вакытлары бар. Намаз вакытыннан алда һәм вакыты үтеп киткәннән соң укылмый, әгәр дә бер-бер сәбәп белән вакытында укылмый калынса, ул намазы казага кала.

*Иртәнге намазның вакыты* — таң атканнан алып кояш чыкканчыга кадәрле. Таң ату үзе ике төрле була. Аның беренчесенә ялганчы таң дип, икенчесенә рас вә дөрес таң дип әйтәләр. Ялганчы таң атканда күкнең уртасына таба яктылык күтәрелеп, аның артыннан җир йөзенә караңгылык иңәр. Ялганчы таң вакытында ризыклану, ягъни ураза тотканда ашау һәм йәсигъ намазын уку дөрес була. Әмма бу вакытта иртәнге намазны уку ярамый. Рас һәм хакыйкый таңны көтәргә кирәк. Дөрес таң шул вакытта була, әгәр дә яктылык күк читеннән таралып җәелә барса. Бу инде иртәнге намазның вакыты җиткәнлеген хәбәр итә һәм ураза тотучыларга ризыкланудан читләшүне таләп итә.

*Өйлә намазының вакыты* — төшлек күләгәсе беленеп икенде намазы күләгәсенә кадәр дәвам итәр. Төшлек күләгәсе дигән вакытта, кояш чыгып, кыйблага таба барган чактан, һәр нәрсәнең күләгәсе кыскарып, кыйблага җиткәч, кыскарудан туктап, озынаерга керешкән мизгелдә була. Өйлә намазының ахыргы вакыты, имам Әгъзам белдерүенчә, һәр нәрсәнең күләгәсе үзе кадәр ике булган чакка кадәр. Имам Әбу-Йосыф һәм имам Мөхәммәт каршында, үзе чаклы бер булган вакытка кадәр. Димәк, өйлә намазын күләгәң үзең кадәр ике буй булганчыга кадәр тәмамлап өлгерү тиешле.

*Икенде намазының башланыр вакыты* өйлә намазының ахыргы вакыты, ягъни күләгәң үз буеңның икесе кадәрдән булгач. Икенде намазының ахыргы вакыты кояш баеганчыга кадәр. Әмма икенде намазын кояш кызарганчыга кадәр кичектерү мәкруһлык хисабында йөри.

*Ахшам намазын башлау вакыты* — кояш баткан-нан соң, ахыры исә кояш бату тарафында кызыл-лык һәм аклык беткәнчегә кадәр. Әмма ахшам намазын йолдызлар калка башлаганчыга кадәр калдыру мәкруһ дип белдерелә.

*Йәсигъ (ясту) намазының вакыты* кояш баткан тарафта кызыллык һәм аклык тәмам югалып бет-кән мизгелдән алып рас һәм хакыйкый таң аткан-чыга кадәр булырга тиешле.

## НАМАЗ УКУНЫҢ МӘКРУҺ БУЛГАН ВАКЫТЛАРЫ

Намаз укуның мәкруһ булган вакытлары бер тәүлек эчендә биш вакыт. Шушы биш вакытта фарыз, нәфел һәм каза намазларын уку мәкруһ дип исәпләнелә.

*Намаз укырга ярамаган өч вакыт болардан гый-барәт:*

1. Кояш чыккан вакыт.
2. Төш вакыты, ягъни күләгәнең тәмам кыска-рып калган чагы.
3. Кояш баеган вакыт.

Әмма кояш баткан вакытта шул көннең икенде намазы дөрес, нәфел һәм каза намазларын уку мәкруһ исәпләнелер.

Шулай да шушы өч вакытта җеназа намазын укып кеше күмү дөрес исәпләнелә, әгәр дә артык кичектерү мөмкин күрелмәсә. Әмма мәкруһ бул-маган вакыт эчендә әзер булган җеназа намазын һәм сәҗдәи тилавәтне бу мәкруһ күрелгән өч ва-кыт эчендә үтәү дөрес түгел, бу мәкруһ вакытлар-ның тәмам чыкканын көтеп сабыр итү тиешле.

Әгәр дә шушы вакытта, ягъни мәкруһ күрелгән вакыт аралыгында бер кеше каза һәм фарыз намаз-ларын һәм витр намазын укыса, намазы дөрес түгел, яңадан укуы соралыр.

## СӘҖДӘИ ТИЛАВӘТ

Коръәндә ундүрт урында сәҗдә аяте бар. Ул аятьләр: «Әгъраф», «Рәгыд», «Нәхел», «Мәрйәм»,

«Исраи», «Хаж», «Фуркан», «Нәмел», «Сәждә», «Сад», «Фуссыйләт», «Нәҗем», «Иншикак», «Галәкъ» сүрәләрендә. Шушы сәждәи тилавәт аятьләренең берсен укыган кешегә дә, тыңлаган бәндәгә дә сәждәи тилавәт кылу важиб санала. Шуның өчен дә сәждәи тилавәт дигән сүз Коръән укыганда сәждә итү дигән төшенчәне белдерә. Коръән чыгучылар боларны яхшы белергә тиешле.

Сәждәи тилавәт кылу рәвеше шуннан гыйбарәт, ул бәндәнең тәһарәте булырга тиешле һәм кыйбла тарафына йөз вә күкрәкне юнәлтеп: «Ният кылдым сәждәи тилавәт кылмага!» — дип ният итәргә һәм тәкбир әйтеп сәждәгә китәргә кирәк. Аннан соң өч тапкыр сәждә тәсбихы әйтеп торып утырыр, аннары бу сүзләрне яттан укып дога кылыр:

سَجَدْتُ لِلرَّحْمٰنِ وَاٰمَنْتُ بِالرَّحْمٰنِ فَاغْفِرْلِي ذُنُوبِي
يَا رَحْمٰنُ سَمِعْنَا وَاَطَعْنَا غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَاِلَيْكَ الْمَصِيرُ*

*Сәҗәдтү лир-рахмәни вә әмәнтү бир-рахмәни фагъфирли зунүби йа рахмәнү сәмигъна вә әтагъна гуфранәкә раббәнә вә иләйкәл-масыйр*

Татарчасы: «Сәҗдә кылдым Аллаһы тәгаләгә һәм иман китердем ул Аллаһы тәгаләгә, минем гөнаһларымны ярлыкагыл, и рәхмәт итүче Аллаһ, и Раббыбыз, без Синең гафуыңны ишеттек һәм Сиңа итагать кылдык, без ахырда Синең хөкемгә кайтачакбыз!»

Сәждәи тилавәтне укуның шартлары намаз уку шартлары төсле үк: тәһарәте булу, тәне һәм киеме, намаз укый торган урыны чиста булу, гаурәте ябылу, кыйблага йөз белән юнәлү.

Сәждәи тилавәтнең махсус вакыты юк. Намаз уку мәкруһ икәнлеге билгеле өч вакыттан тыш кайчан укыса да ярый. Намаздан аермалы буларак, монда тәкбир әйтүдә кулларны колак янына кадәр күтәрү, кыям вә рөкүгъ кылу юк. Сәждәсе дә бер генә мәртәбә була.

## НАМАЗ КЫЛУ МӘКРУҺ САНАЛГАН БИШ ВАКЫТНЫҢ КАЛГАН ИКЕСЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

Намаз укырга мәкруһ санала:

1. Таң аткач, кояш чыкканчыга кадәр.

2. Икенде намазын тәмамлагач, ахшам намазын укыганчыга кадәр.

Әмма таң атканнан соң кояш чыкканчы вакытта иртәнге намазның сөннәтен калдырып нәфел уку мәкруһ һәм шулай ук икенде намазын үтәгәннән соң ахшамга кадәр вакытта нәфел намазын уку мәкруһ, ләкин фарыз, каза, җеназа намазлары һәм дә сәҗдәи тилавәт — болары мәкруһ исәпләнми. Алар бары тик кояш чыкканда, төш вакытында, кояш баеганда мәкруһ.

Әгәр дә бер кеше мәкруһ исәпләнгән чакта нәфел намазын укый башласа, аны өзеп, мәкруһ исәпләнмәгән вакытта укыса һәм каза буларак башкарса — яхшырак. Әгәр дә шушы вакытында намазын туктатмаса, гөнаһлы була.

Әгәр дә намазын кисмичә, мәкруһ вакытта укып бетерсә, аның шушы намазын каза буларак кайтарып укуы таләп ителмәс.

## НАМАЗНЫҢ АЛТЫНЧЫ ШАРТЫ — НИЯТ

Намазны ният итү, намазның *алтынчы* шарты буларак, алдан тел белән тәкрарлап, кайсы вакыт намазын укуын белдерү ул. Ният ул бер-бер эшне үз теләгең белән башкару һәм шуңа тотынуны үзалдыңа белдерү дигән сүз. Намазга ният итүдә Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен һәм аның шулай булуын күңелең белән теләү шарт булып тора.

Намазларга бу рәвешле ният ителә: (Мәсәлән) «Ният иттем бүгенге иртә намазының фарызын кылуга, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен!», яки: «...бу көннең өйлә намазын кылмага, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен», яки: «... бүгенге икенде намазының фарызын укырга, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен», яисә: «... бүгенге ахшам намазының фарызын кылырга, Аллаһы тәгаләнең ризалы-

гы өчен», яки: «... бүгенге кичәнең йәсигъ намазының фарызын кылырга, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен», яки: «...бу кичәнең витр намазын укырга, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен»,—дип ният итәргә кирәк. Әлбәттә, гарәп телендә ниятләү әдәпле вә күркәм эшләрдән санала, әмма үз ана теле белән ниятләү дә мактала.

Намазында ничә рәкәгать икәнлеген ният кылу белән белдерү һәм дә кыйбла тәмам ачык билгеле булган урында, әйтик мәсҗидтә, «Юнәлдем кыйбла тарафына!»—дип әйтү тиешле эшләрдән түгел. Шулай да әйтсә, ялгыш түгел, дөрес, зыянга саналмый, әмма артык сүз. Әмма дә ләкин кыйбла тарафы дөресме-юкмы дигән шөбһәсе күңелендә бар икән, ул вакытта, ягъни кыйбланы дөрес билгеләвендә шөбһәле исә: «Юнәлдем кыйбла тарафына!»—дип әйтү кирәк, өстен.

Сөннәт һәм нәфел намазларын укыганда: «Ният иттем намаз кылырга!»—дип ниятләү дә җитә, әмма сөннәтне укыганда: «Ният иттем сөннәтне кылуны!»—дип белдерү яхшырак.

Тәравих, витр, җомга, гайд, каза, җеназа намазларын укыганда ниятләү тиешле, кайсы намазыңны укуны әйтү сорала. «Намаз укуны ниятләдем!»—дип кенә әйтү дөрес түгел.

Имам булган кеше: «Имам булуны ният иттем!»—димәсә дә ярый. Хәтта бер кеше фарызын укый башлап, икенчесе аңа килеп оеса, бу вакытта аның шулай кушылып китүе дә дөрес.

Әгәр дә җәмәгать арасында берәр мөслимә хатын булса, ул вакытта имам: «Ният иттем имам булуны!»—дип әйтү шарт, таләп ителә. Бу очракта тагын да камилрәк рәвештә ниятләү яхшырак, ягъни шушы рәвешле итеп имам белдерер: «Ният кылдым иртә намазының фарызын укырга, миңа оеганнарга имамлыкка, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен!»—дип. Әгәр дә имам шушы рәвешле ният итмәсә, хатын-кызларның намазлары дөрес булмый.

Имамга оеган җәмәгать исә: «Оедым ошбу имамга!»—дип ният итәрләр. Алар ике ниятkә мохтаҗлар: берсе—кайсы вакыт намазын укыса, шун-

сын ният итүгә, икенчесе — имамга оюда. Мәсәлән, өйлә намазы, ди. Җәмәгать әйтер: «Бүгенге өйлә намазының фарызын кылу өчен оедым ошбу хазир имамга, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен!» — дип.

Әгәр дә бер кеше кайсы вакыт намазын укыганлыгын белдермичә генә: «Оедым имамга!» — дип, яки «Ният иттем имам белән намаз кылырга!» — диярәк, яисә: «Имамның намазы кебек намаз кылырга!» — дип ният итсә, аның намазы дөрес булмый. Шулай да имамга оюны шарт ителгәне өчен, кайберәүләр имам колак кагып тәкбир әйткәнне көтеп торырлар, соңыннан тәкбир әйтерләр һәм дә имамның тәкбир әйтүен көтүне ният урынына тора дип, шуннан соң имамга оюны дөрес дип белдерерләр.

Әгәр дә арада кайберәүләр имамның нинди намазны укыганлыгын белмәүләре сәбәпле: «Ният иттем имамның намазына, оедым шушы имамга!» — дисә, намазы дөрес. Чөнки ул кеше имамның өйлә намазын укуын уйлап, өйлә намазын ниятләсә һәм имамга оеса, ә имам икенде намазын укыса, ул кешенең намазы дөрес булмый.

Бер кеше җомга намазын укыганда җомга намазын ният итеп тә имамга ният итмәсә, аның намазы дөрес була. Чөнки җомга намазы имамсыз укылганда дөрес түгел. Ул бары тик имам белән укыла һәм берәүнең имамга ою-оемавын әйтеп белдермәвеннән башка да аның имам белән укыганлыгын дәлилләп тора.

Бер кеше имамның намазга керешүен уйлап, тәкбир әйтүдән соң тиз генә намазга керешсә, әмма имам намазга керешмәгән булса, бу кешенең намазы дөрес түгел.

Әгәр дә бер кеше күңеле белән намазны ният итеп, теле белән әйтмәсә, аның намазы дөрес, әмма тавыш белән ниятләп әйтү өстенрәк санала, саваплы күрелә.

Әгәр дә бер кеше теге яки бу намазын җәмәгать белән мәсҗидтә укуны ниятләп өеннән чыкса, әмма намазга керешкәндә ниятен онытып, ягъни кайсы намазын укуын ниятләмичә генә «Аллаһү әкбәр» — дип намазга керешсә, әгәр дә аннан кайсы

намазын укыганлыгын сорагач җавап бирә алса, өеннән чыгып мәсҗидкә килгән арада чит бер гамәл кылмаса, аның намазы дөрес була. Чөнки ул бәндә өеннән чыкканда ук ниятләгәне өчен.

Бу шартларның намаздан тышкы шушы алтысын куйсалар, мөэминнәрнең намазы дөрес саналмас, бозылыр. Әмма авыру кешеләр һәм башкалар, ягъни югарыда күрсәтелгән кайбер чыгармаларга караган бәндәләр икән, ул вакытта алар арадан үзләренә туры килгән шартны калдырырлар, әмма намазны укымыйча ярамас. Әмма бу намаздан тышкы алты шартның берәрсен сау-сәламәт мөэмин онытып яки махсус калдырса, намазы дөрес булмас.

## НАМАЗ ЭЧЕНДӘ БУЛГАН АЛТЫ ФАРЫЗ

### БЕРЕНЧЕ ФАРЫЗ

Намаз эчендәге беренче фарыз, ягъни беренче шарт ул — фарыз намазы, сөннәт, яки нәфел, яисә җеназа, һәрнинди намаз булуына карамастан, иң элек, кул күтәреп, колак кагып: «Аллаһү әкбәр» — дип әйтү тиешле. Һәртөрле намазларга шушы рәвешле керелер. Моңа «Тәкбир тәхрим» яки «Ифтитах тәкбир» дип әйтәләр. Намазга керешкәндә «Аллаһү әкбәр» дигән сүздән башка төрле гыйбарәләр белән Аллаһы тәгаләне олылап кергәндә дә дөрес була: әйтик «Аллаһү әгъзам», «Рахман әкбәр» кебек сүзләр белән. Әмма дә ләкин «Аллаһү әкбәр» дип керешү өстенрәк һәм мактаулы санала, важиб булып тора.

Имам «Аллаһү әкбәр» дип әйткәннән соң аңа ияреп әйтү мактаулырак санала, шулай да шәригать китапларында имам Әгъзам өйрәтмәләре буенча, имам белән бергә әйтергә тиешле дип күрсәтелә, Имам Мөхәммәт белән имам Әбу-Йосыф өйрәтмәләрендә исә имам әйтеп бетергәннән соң мөэминнәр имамга оеп, «Аллаһү әкбәр» — дип аваз бирерләр, ияреләр дип күрсәтелә.

Әгәр дә бер кеше имамнан алда «Аллаһү әкбәр» — дип әйтсә яки имамнан алда әйтеп бетерсә,

ул вакытта аның намазы дөрес булмас. Чөнки имамга оеган кеше имамны тыңлар, аңа иярер.

«Аллаһү әкбәр»нең беренче сүзен аяк өсте, икенчесен рөкүгъта әйтү ярамас. Имамга җитешәм дип бу очракта ашыгу килешмәс.

Әгәр дә бер кеше имамга оегач, «Аллаһү әкбәр»не имамнан алда әйттемме, әллә соңмы, дип шикләнсә, шиге көчле булса, күңеле хаталанганлыкны тойса, тәкбир тәхримне яңадан әйтер, юкса намазы дөрес булмас. Әгәр шиге юк исә яки кечкенә исә, имамга оюы дөрес. Шулай да, шиге бар икән, кабат әйтүе яхшырак һәм дөрес гамәл санала.

## НАМАЗ ЭЧЕНДӘГЕ ИКЕНЧЕ ФАРЫЗ

Намаз укуның икенче фарызы — көче җиткән кешенең мөмкин кадәр намазны аяк өсте кылуы, ягъни кыям санала. Көче җитеп тә намазын утырып укыса, намазы дөрес булмас. Шулай да сөннәт һәм нәфел намазларын, авырмаганда, ягъни сәбәпсез дә утырып укырга мөмкин, әмма дә ләкин савабы аз була. Бигрәк тә иртәнге һәм өйлә намазларындагы сөннәтне утырып укымыйча, аяк өсте кылу яхшырак.

Әгәр дә бер авыруның аяк өсте уку өчен көче җитмәсә, утырып укыр. Инде дә утырырлык та түгел икән, ишарәт итеп намазындагы рөкүгъ вә сәҗдәне белдерер. Әмма дә ләкин сәҗдәнең ишарәте рөкүгъның ишарәтеннән түбәнгәрәк иелү белән аерылыр, тик шунсы бар, алдына ястык яки эскәмия куеп сәҗдә ярамас. Әгәр дә аяк өсте укып, савабын күбрәк табарга теләсә, авыру хәлендә дә, баса алмас җиреннән дә ифтитах-башлау тәкбирен аяк өсте әйтергә тырышыр, аннан соң утырып укыса да ярар. Утыра алган кешегә ятып уку, баса алган бәндәгә утырып уку мактала торган гамәлләрдән түгел. Киресенчә, ятып кына торыр хәлдәге кешенең утырып укуы, утырып кына укый алырлык кешенең басып, аяк өсте намаз кылуы мактаулы. Шуңа омтылганда савабы да зуррак булыр.

Әгәр бер кеше утырып укырлык хәлдә түгел икән, ул вакытта аякларын кыйбла тарафына

юнәлттереп, аркасына яткырылыр һәм ул шулай сәждә вә рөкүгъта башы белән ишарәт кылыр, әмма күз һәм каш белән ишарәт ярамас. Әгәр дә баш белән ишарәт кылырлык түгел икән, өстеннән намазы төшәр. Бу рәвешле казалануы егерме дүрт сәгатьтән артса, намазы каза саналмас. Һушы китү аркасында гына икән, каза тиешле. Вакыт-вакыт һушы китү аркасында исә, шулай ук каза тиешле. Әгәр тәүлек буе йокласа һәм һушы китеп торса да намазы казага калыр, кайтарып уку тиешле.

## НАМАЗДАГЫ ӨЧЕНЧЕ ФАРЫЗ—КОРЪӘН УКУ

Намазның өченче шарты шуннан гыйбарәт, намаз укучы кеше Коръәннән аятьләр укыр, аның тавышы үзе ишетер кадәрле булып, ачык һәм үзе мәгънәсен яхшы аңларлык дәрәҗәдә үтәлсен. Шул вакытта гына намазы дөрес булыр.

Намаз дөрес кадәрле итеп Коръән укуның күләме имам Әгъзам каршында—бер аять, ул, яки озын, яисә кыска булсын, үтәлгән исәпләнелә. Имам Мөхәммәт һәм имам Әбу-Йосыф күрсәтмәләре буенча, намаз дөрес булсын өчен өч кыска аять яки өч кыска аять озынлыгында бер озын аять укылыр.

Намазда Коръән аяк өсте басып укылыр.

Өч кыска аятьнең микъдары—ике тынып арасы бер аять. Мисалы:

ثُمَّ نَظَرَ ❁ ثُمَّ عَبَسَ وَبَسَرَ ❁ ثُمَّ أَدْبَرَ وَاسْتَكْبَرَ ❁

*Сумма назар. Сумма габәс вә бәсәр. Сумма әдбәр вә истәкбәр*

Менә шушы күләмдә бер озын аять яки шундый өч кысканы уку яхшы. Әгәр дә тагын да күбрәк укый икән, савабы була. Иртә намазында озын аятьләр уку сөннәт санала.

Имамга оеган мөэминнәр, имам кычкырып яки үзе ишетелерлек кенә тавыш белән аятьләр укуына карамастан, «Аллаһү әкбәр»—дип колак кагып, кул баглап, «Сөбханәкә»не укып туктарлар, имам-

ның укыганын тыңларлар. Бу вакытта җәмәгатькә «Фатиха» яки берәр сүрә кушу таләп ителми. Имамга оеганда имамның укыганын тыңлау фарыз.

Өч-дүрт рәкәгать фарызларда намазда сүрә кушу була. Мәсәлән, өйлә, икенде, ахшам, йәсигъ фарызларының икешәр рәкәгатьләрендә «Әлхәм...»нән соң сүрә кушып уку важиб. Боларның кайсы рәкәгатендә кушса да дөрес. Әмма имам Әгъзам каршында — әүвәлге ике рәкәгатендә кушу важиб, ике рәкәгатьле фарызларда һәр ике рәкәгатенә дә кушылыр.

Сөннәт, нәфел, витр намазларының һәр рәкәгатьләрендә дә «Фатиха»дан соң берәр сүрә кушу важиб санала.

Өйлә, икенде һәм йәсигъ намазларының соңгы икешәр рәкәгатьләренең, ахшам намазының соңгы берәр рәкәгатендә «Фатиха» укып, шуннан соң рөкүгъ кылыныр. Әгәр дә укымыйча гына өч тәсбих микъдары тик торса, намазы дөрес була. Әмма имам Әгъзам каршында «Фатиха» сүрәсен уку важиб дип белдерелә.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ❀ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعٰلَمِينَ ❀
الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ❀ مٰلِكِ يَوْمِ الدِّينِ ❀ اِيَّاكَ نَعْبُدُ وَاِيَّاكَ
نَسْتَعِينُ ❀ اِهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ❀ صِرَاطَ الَّذِينَ
اَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ ❀ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّآلِّينَ ❀

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әл-хәмдү лилләһи раббил-галәмин. Әр-рахмәнир-рахим. Мәлики йәүмид-дин. Иййәкә нәгъбүдү вә иййәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыраталь мөстәкыйм. Сыраталь-ләзинә әнгамтә галәйһим. Гайриль-мәгъдүби галәйһим вәләд-дальлин. Амин*

М ә г ъ н ә с е: «Һәр мактаулылык барча галәмне тәрбия кылучы, дөньяда да, Ахирәттә дә рәхмәт кылучы вә Кыямәт көненең хуҗасы булучы Ал-

laһы тəгалəгə тиешле. Әй Раббыбыз, без Сиңа гына гыйбадəт кылабыз вə Синнəн генə ярдəм эзлибез. Безлəрне тугры юлга күндер — шул кемсəлəрнең юлына ки, Син аларга изге нигъмəтлəр бирəсең. Ачуланылган һəм азган кешелəрнең юлыннан башка юлга, ягъни яхшы юлга күндер. Амин».

«Аятел-көрси» кебек аятьлəрнең яртысын бер рəкəгатьтə, икенче яртысын аннан соңгы рəкəгатьтə уку киңəш ителми. Тулысы белəн бер рəкəгать эчендə укылып бетүе хуш күрелə.

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۞
اَللهُ لَآ اِلٰهَ اِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ ۞ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ ۞
لَهُ مَا فِي السَّمٰوٰتِ وَمَا فِي الْاَرْضِ ۞ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ
اِلَّا بِاِذْنِهِ ۞ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ اَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ ۞ وَلَا يُحِيطُونَ
بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ اِلَّا بِمَا شَآءَ ۞ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ ۞ السَّمٰوٰتِ
وَالْاَرْضَ ۞ وَلَا يَؤُدُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ ۞

*Бисмиллəһир-рахмəнир-рахим. Аллаһү лə илəһə иллə һүвəл-хəййүл-каййүм. Лə тəхузүһү синəтүвə лə нəүм. Лəһү мə фис-сəмəвəти вə мə фил-ард. Мəн зəл-лəзи йəшфəгу гыйндəһү иллə би изниһ. Йагълəмү мə бəйнə əйдиһим вə мə хальфəһүм. Вə лə йухитунə би-шəйим-мин гыйльмиһи иллə бимə шəъ(ə). Вəсига күрсиййүһүс-сəмəвəти вəл-ард. Вə лə йə үдүһү хифзуһүмə. Вə һүвəл-галиййүл-газыйм*

Мəгънəсе: «Аллаһы — терек булучы, галəмнең һəрбер эшен телəгəнчə кылучы Ул. Бер Аллаһы тəгалəдəн башка һич тəңре юктыр. Ул Аллаһы тəгалəдə йокымсырау һəм йокы булмас. Җирдə вə күклəрдə булган нəрсəлəр һəркайсы

анықыдыр. Кемдер Аның каршында шәфкать кылгучымы? Һичкем шәфкать кылмас, мәгәр Аның рөхсәте белән генә. Ул Аллаһы тәгалә җирдә вә күкләрдә булган кемсәләрнең үзләреннән әүвәл булган нәрсәләрне дә, алардан соң киләчәк нәрсәләрне дә беләдер. Ул кемсәләр Аллаһы тәгалә белгән нәрсәләрнең һичкайсын белә алмаслар. Мәгәр Аллаһы тәгалә теләгән кадәр генә белерләр. Аның көрсисе (тәхете) күкләрне дә, җирне дә сыйдыручы. Җир вә күкне сау тоту Аллаһы тәгаләгә һич авырлык түгел. Ул Аллаһы тәгалә бөектер».

## НАМАЗ ЭЧЕНДӘГЕ ДҮРТЕНЧЕ ФАРЫЗ—РӨКҮГЪ

Рөкүгъ дип намазда аяк өсте басып укыганнан соң башны, билне, арканы тигез итеп бөгеп, ягъни алга таба иелеп, Аллаһы тәгалә каршысында хөрмәтеңне белдерүгә әйтәләр.

Әгәр дә намаз укый торган кеше рөкүгъ кылганда башы белән билен тигез итеп бөкмәсә һәм шулай иелүе аяк өсте баскан хәлгә, ягъни кыямга якын икән, ул вакытта аның рөкүгы дөрес түгел.

Әгәр дә рөкүгъ кылганда кулын сузып, тезенә кулы җитмәсә, укыган намазы дөрес түгел, рөкүгы һәм намазы бозык исәпләнелә.

Әгәр дә имам рөкүгъ кылуга күчсә, берәү әле җитешеп кенә килсә, колак кагып тәкбир алса, имам рөкүгътан башын күтәргәнче рөкүгъка барып өлгерсә, тәсбихны әйтү-әйтмәвенә карамастан, аның намазы дөрес булыр.

Әгәр дә берәү имамга җитешәм дип колак каккannan соң рөкүгъка киткәндә тәкбир алса, аның намазы дөрес булмас. Тәкбир аяк өсте әйтелер.

Имамга соңарып җитешкән кеше, әгәр дә имам «Фатиха»ны һәм аңа ияртеп укыган сүрәсен яшертен укыса, «Сөбханәкә»не укыр, әгәр дә имам кычкырып укыса, тыңлап торыр, үзлегеннән уку кирәкмәс.

Әгәр дә имам рөкүгъка киткән вакытта берәү җитешеп килсә, «Сөбханәкә»не укып җитешермен,

дисә, укыр, әмма имамга җитешүдән күңеле шикләнсә, укымаса да дөрес. Чөнки имамга ою — саваплы.

Бер кеше бүтәннәр сәҗдәдә вакытта килсә, өммәт белән намаз укуга катнашу өчен әүвәлге сәҗдәдә килеп катнашкан бәндә кебек гамәл кылыр, ягъни укып җитешермен дип уйласа, «Сөбханәкә...»не укыр, ә юк исә, имамга оер. Әгәр дә берәү икенче сәҗдә вакытында җитешеп килсә, ул вакытта «Сөбханәкә...»не бөтенләй дә укып тормастан рөкүгъ хәленә китәр.

Фарыз, сөннәт һәм нәфел намазларында рөкүгъ хәленә барганда:

اَللّٰهُ اَكْبَرُ ۞ *Аллаһү әкбәр* —

диярга кирәк, рөкүгъ хәлендә имам һәм аның җәмәгате, ягъни аңа ияреп намаз укучылар өч мәртәбә:

سُبْحَانَ رَبِّىَ الْعَظِيمِ ۞ *Сөбханә раббийәл-газыйм* —

дип әйтерләр. Моның мәгънәсе: «Олуг Аллаһы тәгалә һәрбер кимчелекләрдән дә азат, пакь!» — дигән сүз.

Биш яки жиде тапкыр шушы кәлимәне әйтү саваплы. Имам булган кешегә биш мәртәбә тәсбих әйтү тиешле эш. Җәмәгате өч тапкыр әйтеп өлгерсен өчен һәм аларны ялгыштырмаска моннан артыгын кабатламасын.

Рөкүгъ хәленнән торган вакытында имам:

سَمِعَ اللّٰهُ لِمَنْ حَمِدَهُ ۞ *Сәмигәл-лаһү лимән хәмидәһ* —

диярга тиеш, ягъни (мәгънәсе): «Аллаһы тәгалә үзен мактаган кешенең мактауларын ишетеп кабул итә!»

Имамга оеп намаз укучылар исә, рөкүгъ хәленнән торганда, ягъни күтәрелгәндә:

﴿رَبَّنَا لَكَ ٱلْحَمْدُ﴾ *Раббәнә ләкәл-хәмде* — дисеннәр. Аның мәгънәсе: «И Раббыбыз, һәрбер мактаулар Сиңа гына хас, тиешле!»

Үзләре генә ялгыз укыган кешеләр исә икесен дә әйтерләр. Бу рөкүгънең тәкбирләре һәм тәсбихләре сөннәт санала.

## НАМАЗНЫҢ БИШЕНЧЕ ФАРЫЗЫ—СӘҖДӘ

Сәҗдә җиде әгъзаңны җиргә кую белән башкарыла. Иң элек тезләреңне, аннан соң ике кулыңның учларын, маңгаеңны һәм борыныңны, аяк бармакларыңның очларын җиргә терисең, ягъни куясың. Бу рөкүгъ хәленнән соң аяк өсте баскач кабат сәҗдәгә китеп башкарыла, сәҗдәгә китү дип йөртелә.

Әгәр дә берәр кешенең сәҗдәне тәмам җиде әгъзасы белән дә башкарырга мөмкинлеге юк икән, ул вакытта сәҗдәне ишарәт белән кылыр.

Әгәр дә бер кеше сәҗдәдә маңгаен җиргә куеп та борынын терәмәсә, намазы, борыны авырту яки бүтән сәбәп белән икән, дөрес санала. Ләкин сәбәпсез-гозерсез икән, мәкруһ атала. Әгәр дә борынын гына терәп, маңгаен җиргә куймаса, намазы дөрес булмас. Әгәр дә маңгаен җиргә терәмәүдә сәбәп бар икән, ул вакытта намазы дөрес саналыр. Әгәр дә маңгаен терәмәү өчен сәбәбе була торып та яки һичбер сәбәпсезгә сәҗдәдә чигәсен яисә яңагын җиргә терәсә, намазы дөрес булмас, ялгышлыдыр.

Намаз укый торган кешенең намаз укый торган урыны сәҗдәгә киткәндә маңгае батарлык булырга тиеш түгел, ягъни артык йомшак булмасын. Маңгае катылыкны сизәрлек урын дөрес. Әгәр дә мамык яки су кебек икән, түшәк, ястык һәм башка шундый йомшак җир икән, аның намазы дөрес түгел.

Намаз укый торган кешенең басып торган урыныннан сәҗдәгә китеп, маңгаен терәячәк җире ике кирпеч калынлыгы яки ярты аршин, 30 см. биек булса да укыган намазы дөрес санала, әгәр дә болардан да биегрәк икән, ул вакытта дөрес түгел.

Һәр намазда да сәҗдәгә барганда:

اَللّٰهُ اَكْبَرْ ۝ *Аллаһү әкбәр* —

дип әйтергә кирәк. Сәҗдәдә вакытта исә:

سُبْحَانَ رَبِّىَ الْاَعْلٰى ۝ *Сөбханә раббийәл-әгъләә* —

диләр, өч мәртәбә! Мәгънәсе: «Бөек Раббым һәрбер кимчелектән азаттыр!».

Биш яки җиде тапкыр шушы сүзне әйтү нур-савап була. Сәҗдәдән торганда шулай ук «Аллаһү әкбәр» дияргә кирәк. Рөкүгъ вакытында әйтелә торган шушындый тәсбих һәм тәкбирләр җәмәгать белән бергәме, аерыммы, имаммы син, имамга оючымы, барыбер үз телең белән әйтү сөннәт санала һәм дөрес була.

## НАМАЗНЫҢ АЛТЫНЧЫ ФАРЫЗЫ— НАМАЗ ТӘМАМЛАНГАННАН СОҢ БЕРАЗ УТЫРЫП ТОРУ

Фарыз, сөннәт, нәфел һәм һәртөрле намазлардан соң ахырында бераз вакыт, ягъни иман кәлимәсе микъдары кадәр утырып тору фарыз-тиешле санала. Әгәр дә кимрәк вакыт утырса, намазы дөрес булмый. Бу иман кәлимәсе яки инанулык сүзләре микъдары кадәр утыруның вакыты:

تشهّد ۝

اَلتَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ وَ الصَّلَوَاتُ وَ الطَّيِّبَاتُ۝اَلسَّلَامُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِىُّ وَ رَحْمَةُ اللّٰهِ وَ بَرَكَاتُهُ۝اَلسَّلَامُ عَلَيْنَا وَ عَلٰى عِبَادِ اللّٰهِ الصَّالِحِينَ۝اَشْهَدُ اَنْ لَا اِلٰهَ اِلَّا اللّٰهُ وَ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ ۝

*Әт-тәхийәтү лилләһи вәс-саләвәтү вәт-таййибәт. Әс-сәламү галәйкә әййүһа-н-нәбийү вә рәх-

мәтул-лаһи вә бәрәкәтүһ. Әс-сәламү галәйнә галә гыйбадил-лаһис-салихин. Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ* — дигән сүзләрне укып чыгуга тигез яки артыграк булырга тиеш, боларны шушында уку важиб гамәл саналыр. Ким микъдарда гына утыру фарыз гамәлне бозу дип каралыр, намазы дөрес булмас.

Бу сүзләрнең тәрҗемәсе һәм мәгънәсе: «Тел гыйбадәтләре дә, тән гыйбадәтләре дә һәм мал гыйбадәтләре дә һәркайсы Аллаһы тәгалә өчен. И пәйгамбәребез, сиңа Аллаһы тәгаләнең рәхмәте һәм сәламе һәм бәрәкәтләре булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһы тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә, телем белән әйтеп, күңелем белән ышанып ышанычлык итәмен, чыннан да бер Аллаһы тәгаләдән башка һич илаһи зат юк, шулай ук телем белән әйтеп, күңелем белән инанып ышаныч итәмен, чыннан да Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы тәгаләнең колы һәм илчеседер!»

Бу сүзләрне гарәпчә әйтергә белеме һәм зиһене җитмәгән кешеләр аны, һич булмаса, үз ана телендә әйтсәләр дә ярый. Намазда бары тик кыйраәт, ягъни Коръән аятьләрен укыганда гына гарәпчә әйтелеп, калган урыннарда, һич булмаса, үз ана телеңдә сөйләсәң дә ярый. Чөнки ул сүзләр кылган гамәлеңне телең белән раслауны аңлаталар, үз ана телеңдә әйтелү белән аларның чын күңелдән сөйләнелгәнлеген белдерәләр.

Намаздан соң шушы рәвешле иман сүзләре әйтелеп бетерелгән вакыт микъдарында утырганнан соң, ягъни аларны тел һәм күңел белән әйткәч, берәр дога уку сөннәт санала. Монда дога уку фарыз гамәл түгел, шунлыктан, намаз бетеп, бер микъдар утыргач, сәлам биреп, намаздан чыгарга кирәк. Әмма дога укуның мактаулы гамәл икәнен дә онытырга ярамый. Аны әбиләребез салават әйтү дә диләр. Ул дога болай укылыр:

صَلَوات ۞

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى آلِ مُحَمَّدٍ۞كَمَا صَلَّيْتَ عَلٰى اِبْرٰاهِيمَ وَ عَلٰى آلِ اِبْرٰاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞اَللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى آلِ مُحَمَّدٍ۞كَمَا بَارَكْتَ عَلٰى اِبْرٰاهِيمَ وَ عَلٰى آلِ اِبْرٰاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞

*Аллаһүммә салли галә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд. Кәма салләйтә галә Ибраһимә вә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид. Аллаһүммә барик галә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд. Кәма бәрактә галә Ибраһимә вә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид*

Мәгънәсе: «И Аллаһы тәгалә: Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның халкына рәхмәт кыл, ничек Ибраһим пәйгамбәреңә һәм аның халкына рәхмәт кылган идең, чыннан да Син мактаулы һәм олуг! И Аллаһы тәгалә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның халкына бәрәкәтлек бир, ничек Ибраһим пәйгамбәргә һәм аның халкына биргәнеңчә, чыннан да Син мактаулы һәм олуг!»

Доганы, һич булмаса, шушы рәвешле үз ана телеңдә укысаң да ярый, һичбер тыелмый, киресенчә чын күңелдән булганлыгы белән яхшы икәнлеге аңлашыла. Аллаһы тәгалә үзенең колларына һәрдаим миһербанлы һәм мәрхәмәтле, ана телебез дә Раббының сөекле телләреннән берседер!

## НАМАЗДАН ЧЫГУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Намаздан чыгу мәсьәләсенең *беренчесе* шуннан гыйбарәт, имам Әгъзам, ягъни Ногман бине Сабит әйтер, намаздан үз ихтыярың белән сәлам биреп чыгу, бүтәннәрне көтеп тормау — дөрес, дип. Әгәр дә намаз укып бетергәннән соң сәлам бирмичә кыйбладан китсәң, дөнья сүзләрен сөйләшсәң, ашасаң, намаздан киткән саналырсың, әмма сәлам би-

релмәү сәбәпле бу рәвешле намаздан китү мәкруһ саналыр. Үз теләгең белән намаздан китү намазыңны бозмас.

Намаздан чыгуда *икенче* мәсьәлә: намаз укыгач, сәлам бирергә генә ниятләнгән вакытта тәһарәтең бозылса, дин галимнәренең белдерүенчә, имам Әгъзам аңлатканча, әүвәле тәһарәт яңартыла, бүтән чит гамәл эшләнелми һәм, әттәхияткә утырып, сәлам биреп, намаз тәмам була. Чөнки үз ихтыярың белән намаздан чыкмаганлык өчен. Әгәр дә тәһарәтең бозылып, аны яңарткач, дөнья гамәле кылсаң, намазыңны яңабаштан кылу тиеш.

## НАМАЗДА ХӘРӘКӘТТӘН ТЫЕЛУ МӘСЬӘЛӘСЕ

Намаз укыган вакытта, рөкүгъ хәленнән торгач, сәҗдәгә китәр алдыннан һәм ике сәҗдә арасында тәмам тураеп, әгъзаларны хәрәкәттән туктатып алырга кирәк. Шулай хәрәкәтсез калганнан соң гына алга таба ниятләнеп хәлеңне үзгәртү сорала. Бу хәрәкәтсез калу вакыты микъдары ким дигәндә «Сөбханаллаһ» сүзләрен әйтүдән ким булырга тиеш түгел.

Шушылай хәрәкәттән тыелып торудан башка, аны исәпкә алмыйча намаз укуның зарарлары бар. Дөньялыкта яшәгән вакытларында бу кешеләр фәкыйрь һәм мохтаҗ булырлар, бүтәннәр аннан күреп шулай ук аныңча укып, гамәлләренә зыян китерерләр. Шушы намазда тыелып торуны исәпкә алмаган кешеләрне Аллаһы тәгалә ачуланыр, ахырда имансыз үлем якасында калырлар, намазлары кабул кылынмас, күкләргә ирешмәс, өметсез итерләр.

Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытында рөкүгъ хәленнән тәмам тураеп, тыелып тору хәләтенә кермәсә яки сәҗдә белән сәҗдә арасында бераз вакытка тураеп утырмаса, ул кешенең намазы бозык була.

Әгәр дә бер кеше боларны исәпкә алмыйча намазын укыган икән, соңыннан хатасы хәтеренә

килсә, төзәтеп укыса, яңабаштан намазын кылсын, шул вакытта хата төзәтелгән исәпләнер.

## НАМАЗНЫҢ ВАҖИБЛӘРЕ, ЯГЪНИ ТАЛӘП ИТЕЛГӘН ТИЕШЛЕ ЭШЛӘРЕ

*Беренчесе:* Намазда хәрәкәттән тыелу тиешле урыннарда ят хәрәкәтләр ясамау.

*Икенчесе:* Намаз укыганда әүвәлге рәкәгать фарызда «Фатиха» сүрәсен уку.

*Өченчесе:* Бер рәкәгать эчендә ике тапкыр «Фатиха» сүрәсен укырга ярамас, онытылып китсә, хаталанган хисапланыр.

*Дүртенчесе:* «Фатиха» сүрәсенә бер аерым кыска сүрә яки өч кыска аять кушып уку тиешле.

*Бишенчесе:* Кушылып укыла торган сүрә бары тик «Фатиха»дан соң булырга тиешле.

*Алтынчысы:* Өч-дүрт фарызлы намазларда кушыла торган сүрәне беренче икесендә кушып уку дөрес. Ике рәкәгатьле намазларда, витр, сөннәт, нәфел намазларында һәрбер рәкәгатенең эчендә «Фатиха»дан соң сүрә кушып уку тиешле.

*Җиденчесе:* Имам булган кеше иртәнге, ахшам, йәсигъ, җомга һәм гайд намазларында кыйраәтне, ягъни Коръән аяте укыла торган җирләрдә, кычкырып укырга тиеш. Әгәр дә берәү шушы намазларны ялгызы башкара икән, ул вакытта үз ихтыярынча, яки кычкырып, яки яшерен укыса да мөмкин.

*Сигезенчесе:* Өйлә һәм иkенде намазларында имам һәм аерым укучы кеше кыйраәтне, ягъни Коръәнне укый торган урынында, яшерен рәвештә укырга тиешле, ләкин үзе ишетерлек тавыш белән булганда — дөрес, инде дә үзе дә ишетерлек түгел икән, ул бәндә Коръән укыган саналмас.

*Тугызынчы:* Витр намазында, өченче рәкәгатендә, сүрә кушып укыганнан соң, рөкүгъ хәленә китүдән элгәре «Аллаһү әкбәр» — дип колак каккannan ары Кунут догасын кылу тиешле. Кунут догасы моннан гыйбарәт:

## ❀ قُنُوت

اَللّٰهُمَّ اِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَ نَسْتَغْفِرُكَ، وَ نُؤْمِنُ بِكَ وَ نَتَوَكَّلُ
عَلَيْكَ وَ نُثْنِى عَلَيْكَ الْخَيْرَ نَشْكُرُكَ وَ لَا نَكْفُرُكَ وَ نَخْلَعُ
وَ نَتْرُكُ مَنْ يَفْجُرُكَ ❀ اَللّٰهُمَّ اِيَّاكَ نَعْبُدُ وَ لَكَ نُصَلِّى وَ
نَسْجُدُ وَ اِلَيْكَ نَسْعٰى وَ نَحْفِدُ نَرْجُو رَحْمَتَكَ وَ نَخْشٰى
عَذَابَكَ اِنَّ عَذَابَكَ بِالْكُفَّارِ مُلْحِقٌ ❀

Кунут догасының укылышы: *Аллаһүммә иннә нәстәгыйнүкә вә нәстәгъфирүкә вә нүэминү бикә вә нәтәвәккәлү галәйкә вә нүсни галәйкәл-хәйрә нәшкүрүкә вә лә нәкфүрүкә вә нәхләгу вә нәтрүкү мәй-йәфҗүрүк. Аллаһүммә иййакә нәгъбүдү вә ләкә нусалли вә нәсҗүдү вә иләйкә нәсга вә нәгъфидү нәрҗу рәхмәтәкә вә нәхша газабәкә иннә газабәкә билкүффари мүлхикъ*

Кунут догасының т а т а р ч а с ы: «И Аллаһы тәгалә, без чыннан да Синнән ярдәм эзлибез һәм гөнаһларыбызны ярлыкавыңны телибез, һәм дә иненабыз һәм тәвәккәл кылып, һәрбер эшләребезне Сиңа тапшырабыз. Һәм Сине мактыйбыз. Сиңа шөкер кылабыз, көферлек эшләмибез, Сиңа гөнаһ кылган кешеләрне ташлыйбыз. И Аллаһы тәгалә, без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синең өчен генә намаз укыйбыз һәм сәҗдә кылабыз. Һәм гыйбадәт кылып, Сиңа якын булырга ашыгабыз, рәхмәтеңне өмет итәбез. Газабыңнан куркабыз. Чыннан да Синең газабың имансыз кешеләргә тиючедер!»

*Унынчысы:* Әүвәлге утырганда һәм соңгысында иман кәлимәсен уку тиешле:

اَشْهَدُ اَنْ لَا اِلٰهَ اِلَّا اللّٰهُ وَ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

*Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ* — дип.

*Унберенчесе:* Өч һәм дүрт рәкәгатьле фарызларда, өйләнең һәм җомганың сөннәтләрендә һәм

шундый сөннәтләре макталган намазларда әүвәлгесендә үк утыру мактаулы.

Сөннәт мөстәхәб булган намазларда, мәсәлән, икенде һәм йәсигъның әүвәлге сөннәтләре кебек, һәм нәфел намазларының һәр ике рәкәгатьләре бер намаз исәпләнеп, боларның әүвәлге утырышы фарыз булып, әттәхиятне һәм догаларны укып, өченче рәкәгатькә торгач, «Сөбханәкә...», «Әгузү...», «Бисмилләһ...» илә башлау мәҗбүри. Өйлә һәм ястүнең соңгы сөннәтләрен дүрт рәкәгать укыса, боларның әүвәлге ике рәкәгате сөннәт мөвәкдә, соңгы ике рәкәгатьләре сөннәт мөстәхәб санала. Боларның шулай ук әүвәлге утырышы — фарыз, әттәхияттән соң салават һәм догаларны укып, аякка торгач, «Сөбханәкә...» һәм «Әгузү...», «Бисмилләһ...» белән башлап кителә, мөстәхәб намазларын теләсә, икедә бер сәлам биреп уку тиешле.

*Уникенчесе:* Әгәр дә сәждәдә ялгышынган икән, сәламнән соң ике мәртәбә сәждә итү тиешле.

*Унөченче:* Имам да, ялгыз укыганда да намазда сәждә аятен укыса, сәждәсен дә кылырга тиеш.

Намазда сәждә аятен укыган кеше бу рәвешле сәждә кылсын: намазда сәждә аятен укыгач та яки сәждә аятеннән соң бер яки ике аятьне укыгач та рөкүгъ хәленә китсә, сәждәи тилавәт өчен, ягъни сәждәдә Коръән уку өчен үз алдына сәждә кылу соралмый, шул рәкәгатьнең сәждәсе белән бергә сәждәи тилавәт үтәлгән исәпләнелә.

Әгәр сәждә аятеннән соң өч аять укыса, теләли икән, сәждәи тилавәт өчен үз алдына сәждә итәр, теләсә ул рәкәгатьнең рөкүгында яки сәждәсендә, сәждәи тилавәткә ниятләнеп, ул рәкәгатьнең сәждәсе белән башкарыр. Икесе дә дөрес саналыр.

Әгәр дә сәждә аятеннән соң дүрт яки артык аять укыса, сәждә аяте өчен үз алдына сәждә тиешле булыр. Бу вакытта сәждәне болай кылыр: «Аллаһү әкбәр» — дип сәждәгә баргач, өч мәртәбә «Сөбханә раббийәл-әгълә» дияр, соңыннан торыр, торгач өч аять яки артык укып, рөкүгъ хәленә китәр. Сәждәсеннән торгач, бер микъдар аять укы-

мыйча рөкүгъ итсә, мәкруһ, ягъни киңәш ителми торган гамәлне кылган булыр.

*Ундүртенчесе:* Бер фарыздан икенче фарызга өч тәсбих кадәрле тормыйча китү. Мәсәлән, рөкүгъ хәленнән соң сәҗдәгә бармыйча өч тәсбих микъдары яки артык кичексә, яки ике рөкүгъ кылып, фарыз булган сәҗдәне кичектерсә, йә өч сәҗдә итеп, кыямны яки соңгы утырышны кичектерсә, яки өченче рәкәгатьнең башында бер микъдар вакыт аралыгы утырып, дүртенче рәкәгатьнең кыямын кичектерсә, бу сурәтләрдә фарызларны урыныннан, тиешле җиреннән кичектерү сәбәпле оныткан булса, сәҗдәдә ялгышлык күренер, сәҗдә сәһү тиешле саналыр. Белеп торып шулай эшләсә, мәкруһ гамәлгә керер.

*Унбишенчесе:* Намаз эчендә һәр рәкәгатьнең һәр фарызларын төгәл тәртипләре буенча кылу.

Әгәр берәү намазын тәртип буенча кылмаса, аның намазы дөрес булмас, кабаттан укуы шарт ителер.

*Уналтынчы:* Намаздан чыкканда әүвәл уң ягына, аннан соң сул ягына карап:

❀ اَلسَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَ رَحْمَةُ اللّٰهِ ❀

*Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтул-лаһ* — дип сәлам бирү тиешле.

Аның мәгънәсе: «Аллаһы тәгаләнең сезгә сәламе һәм рәхмәте булсын!»

Әгәр дә бер кеше намазының тәртипләрен бозса һәм кай урыннарын онытып калдырса, гөнаһ иясе саналыр. Намазын кабаттан башлап уку таләп ителер.

## НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ

*Беренчесе:* Намазларда азан әйтү сөннәт санала. Ваҗиб һәм сөннәт намазларында азан сөннәт түгел. Шулай ук һәр каза һәм фарыз намазларында ирләргә камәт уку, ягъни намаз алдыннан әйтелә

торган сүзләрдән үк башлап уку сөннәт санала. Хатын-кызларга азан һәм камәт әйтү сөннәт түгел.

Вакыты кермичә әйтелгән азан кайтарылырга тиешле, ягъни кабат әйтелә. Әмма иртәнге намаз алдыннан әйтелгән азан, әгәр дә әле вакыты кермәгән исә дә, кайтарылмас. Дивана, авыру һәм исерек кешеләрнең азаны, шулай ук хәрефләрен дөрес аваз белән әйтмәүчеләрнең, бала-чагаларның азаннары кайтарылырга тиешле. Мәгәрем ки сабый бала авазларны дөрес белдереп азан әйтсә, аның азаны кайтарылмас.

Намазга мөэминнәрне мөәззин (халык арасында кыскартып кына «мәзин» яки «мөэзин» дип тә әйтәләр), манарадан торып тавышы белән ачык әйтеп чакырыр.

Мөәззиннән болар таләп ителер, аның сыйфатлары:

1. Мөәззин кеше акыллы булырга тиеш.
2. Изгелек иясе.
3. Гөнаһтан сакланучы.
4. Намаз вакытларын белүче.
5. Сөннәтне белүче, аны ташлаудан куркучы.
6. Бүтәннәрнең хәлен белешеп торучы, ни өчен намазга килмәүләре белән кызыксынучы һәм аларга: «Намаздан калмагыз!» — дип әйтүче.
7. Халык каршында хөрмәтле булырга тиешле.

## АЗАН ШӘРИФНЕҢ УКЫЛУ РӘВЕШЕ

| | |
|---|---|
| اَللّٰهُ اَكْبَرُ ۞ | ∗Аллаһү әкбәр∗ — дүрт мәртәбә. |
| اَشْهَدُ اَنْ لَا اِلٰهَ اِلَّا اللّٰهُ ۞ | ∗Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһ∗ — ике мәртәбә. |
| اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللّٰهِ ۞ | ∗Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-рәсүлүл-лаһ∗ — ике мәртәбә. |
| حَيَّ عَلَى الْفَلَاحِ ۞ | ∗Хәййә галәс-саләһ∗ — ике мәртәбә. |

حَيَّ عَلَى الْفَلَاحِ ❁ — *Хәййә галәл-фәлах* — ике мәртәбә.

اَللّٰهُ اَكْبَرُ ❁ — *Аллаһү әкбәр* — ике мәртәбә.

لَا اِلٰهَ اِلَّا اللّٰهُ ❁ — *Лә иләһә иллал-лаһ* — бер мәртәбә.

Әгәр дә иртәнге намазга чакыру икән, ягъни иртәнге намаз булса,

حَيَّ عَلَى الْفَلَاحِ ❁

*Хәййә галәл-фәлах* — дигәннән соң:

اَلصَّلَاةُ خَيْرٌ مِنَ النَّوْمِ ❁

*Әс-саләтү хайрүм-минән-нәүм* — дип ике мәртәбә әйтү тиешле.

Әгәр дә авылда яки шәһәрдә мәсҗид булып, анда азан әйтелә икән, ул вакытта өеңдә ялгыз намаз укыган вакытыңда азанны үзең әйтеп тору таләп ителми. Чөнки мөэминнәр өчен азан мәсҗидтә әйтелде һәм намаз укыла башлады.

Мөсафирлар исә, юлда булулары сәбәпле, азан яки камәт әйтерләр, икесен дә әйтү дөрес, әмма икесен дә укымау — бозыклык.

Азан әйткән вакытта мөәззин яки азанны әйтүче кеше, иң әүвәл, тәһарәтле, икенче, кыйблага каршы аяк өсте торырга, өченче, имән бармакларын колак эченә тыгып, азанның сүзләрен ачык итеп, сузып-сузып, ике сүзне бергә кушмыйча, аерым-аерым әйтергә тиешле:

حَيَّ عَلَى الصَّلَاةِ ❁

*Хәййә галәс-саләһ* — дигән сүзләрне әйткәндә, кычкырганда уң якка карап әйтергә,

حَيَّ عَلَى الْفَلَاحِ ❀

*Хәййә галәл-фәлах*—дип кычкырганда сул ягына карап әйтергә тиешле!

Азан һәм камәт әйткән вакытта сүз сөйләшү мәкруһ гамәлләрдән санала. Шулай ук, ахшам намазыннан тыш, бүтән намазларда азан һәм камәт арасында дүрт рәкәгать намаз уку, һәр рәкәгатьтә унике аять уку кадәрле вакыт үтәргә, ягъни аеру таләп ителә. Әгәр дә аермаса, азан әйтеп, соңыннан аңа камәт кушса, мәкруһ гамәл исәпләнелер. Ахшам намазында исә азан белән камәт арасында өч кыска аять укырлык вакыт калырга тиешле.

Әгәр бер кеше азан тавышын ишетсә, ул шушы мөәззингә ияреп әйтергә тиеш, әмма «Хәййә галәссаләһ, хәййә галәл-фәлах» диясе урында:

لَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ اِلَّا بِاللّٰهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ ❀

*Лә хаулә вә лә кувәтә иллә билләһил-галиилгазыйм*—дисен, иртәнге азандагы:

الصَّلَاةُ خَيْرٌ مِنَ النَّوْمِ ❀

*Әс-саләтү хайрүм-минән-нәүм*—дигәндә:

صَدَقْتَ وَبِالْحَقِّ نَطَقْتَ ❀

*Садактә вә бил-хаккый нәтактә*—дию кирәк. Шушы рәвешле җавап бирү лаеклы эш. Азан авазын ишеткән кешегә, һәртөрле эшләрен калдырып, мәсҗидкә бару таләп ителә.

Бер шәһәрдә яки авылда берничә мәсҗид булып, кем дә кем һәр мәсҗиднең дә азанын ишетсә, алдан ишеткән азан тавышына буйсыныр, хәтта ул бүтән мәсҗиднең әһеле саналса да, бу азан аның өчен дә дөрес дип каралыр. Намазын үз мәсҗидендә яки йортында укыр.

Әгәр дә бер кеше Коръән укыган вакытында азан әйткәннәрен ишетсә, мөәззинне тыңлау һәм аңа ияреп азан әйтү дөрес гамәл күрелгәнлектән, мөәззинне тыңлар һәм аңа иярер. Әгәр дә Коръән укыган вакытында үз мәсҗиденең азанын ишетсә, ягъни үзләренең мәхәлләсендә мөәззин азан әйтсә, Коръән укуыннан туктамас. Шулай ук Коръәнне мәсҗидтә укыган вакытында азан әйтсәләр, шулай ук Коръән укудан тукталып, азанны тыңлау һәм аңа ияру таләп ителми.

Азан әйтелеп беткәннән соң бу доганы уку кирәк:

اَللّٰهُمَّ رَبَّ هٰذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَ الصَّلَاةِ الْقَائِمَةِ ❀
اٰتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ وَ الْفَضِيلَةَ وَالدَّرَجَةَ الْعَالِيَةَ الرَّفِيعَةَ ❀
وَ ابْعَثْهُ مَقَامًا مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَهُ وَ ارْزُقْنَا شَفَاعَتَهُ
يَوْمَ الْقِيَامَةِ ❀ اِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَادَ ❀

*Аллаһүммә раббә һәзиһид-дәгъвәтит-тәммәти вәс-саләтил-каимәһ. Әти Мөхәммәдәнил-вәсиләтә вәл-фадыйләтә вәд-дәрәҗәтәл-галийәтәр-рафигаһ. Вәбгасһү мәкамәм мәхмүдәнил-ләзи вә гадтәһү вәрзукна шәфәгатәһү йәүмәл-кыямәһ. Иннәкә лә түхлифүл-мигадъ*

Татарчасы: «И шушы камил азанның вакыты кергән намазның хуҗасы булган Аллаһы тәгалә, Мөхәммәд пәйгамбәргә ярдәмчелекне һәм артыклыкны һәм югары вә өстен булган дәрәҗәне бирсәң иде, һәм дә аны үзең вәгъдә кылган мактаулы урынга китерсәң иде, һәм дә Кыямәт көнендә безгә аның шәфкатен насыйп итсәң иде, чыннан да Син вәгъдәгә һичбер хилафлык кылмыйсың!»

Мөхәммәд пәйгамбәребезнең хәдисендә болай диелгән: «Һәркем азан шәрифне тыңлап, мөәззин әйткән кебек әйтеп, моның соңында бу доганы укыса, минем рәхим-шәфкатем шул кешегә тиешле булыр!» Шулай итеп, азанны ишеткәннән соң аны

кабатлап, бу доганы укысаң, Кыямәт көнендә рәхим-шәфкать таләбендә була аласың икәнлеге аңлашылып тора.

Намаз сөннәтләренең *икенчесе:* Намазга керешкән вакытта «Аллаһү әкбәр» — дип белдергәндә ирләр ике кулларын да колакларына кадәр, хатыннар иңбашлары турысына чаклы күтәрү тиешле.

*Өченчесе:* Намаз укыганда ирләр уң кулларын сул куллары өстенә куеп, аны кендек астындарак тотарлар. Һәр ике кулларының да баш һәм чәнчә бармаклары учның эчке ягыннан бер-берсенә каратылып, боҗра сурәтендәрәк булырга тиешле. Хатын-кызлар исә шушы рәвештәрәк итеп күкрәкләре өстенә куярлар.

*Дуртенчесе:* Фарыз һәм сөннәт намазларында колак кагып, кулларын бәйләгәч, ягъни баглагач, ялгыз рәвештә яки имамга оеган сурәттә намаз укуларына карамастан, һәм дә ир яисә хатын булуларына да карамастан, яшерен рәвештә, тавыш белән түгел, моны уку сорала:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ وَ تَبَارَكَ اسْمُكَ وَ تَعَالٰى جَدُّكَ وَلَا اِلٰهَ غَيْرُكَ ❀

*Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкә исмүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә иләһә гайрүк*

Бу доганың т а т а р ч а с ы моннан гыйбарәт: «И Аллаһы тәгалә, Сине бар яманлыктан саф дип беләмен һәм Сиңа мактау әйтәмен, Синең исемең бәрәкәтле булды, Синең олылыгың өстен булды, Синнән башка илаһи зат юк!»

*Бишенчесе:* Имам укыймы, әллә инде ялгыз башына ир яки хатын намаз укыймы, «Сөбханәкә...»дән соң:

اَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ❀

*Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим* кәлимәсен яшерен әйтергә тиешле.

Татарчасы: «Рәхмәтеңнән сөрелгән шайтанның явызлыгыннан Аллаһы тәгалә үзеңә сыенам!»
Шуннан соң гына:

بِسْــــــــمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим* — дисең.

Татарчасы: «Дөньялыкта һәм Ахирәттә рәхмәтле Аллаһы тәгаләнең исеме белән башлыйм!»

Әмма имамга оеганда, боларны укымыйча, бары тик «Сөбханәкә...» генә укып, тик торырга тиешле.

Әгәр дә бер кеше имамга берничә рәкәгатькә җитешмәгән исә, имамның сәламеннән соң аягына калкып, калган рәкәгатьләрне укыганда, ягъни башкарганда, һәр рәкәгатьнең башына «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим»ны һәм «Фатиха» сүрәсен укыр. Әгәр дә сүрә кушылачак рәкәгатьләр икән, аларны да өстәп укыр, әгәр дә «Фатиха» сүрәсе, ягъни «Әлхәм...» үзе ялгыз гына укыла торган рәкәгатьләр икән, ул вакытта «Фатиха»ны башкарыр.

*Алтынчысы:* Имам һәм аңа оеган җәмәгать, шулай ук ялгыз башына намаз укучы ир яки хатын, «Фатиха» сүрәсен укыганнан соң, ягъни «...вәләддальлин» дип тәмамлаганда яшертен тавыш белән «Амин» дип әйтү сөннәт. آمِينَ *Амин* сүзенең татарча мәгънәсе «Кабул кыл!» дигән сүз.

*Җиденчесе:* Имам һәм аңа оеган җәмәгать, ялгыз намаз укучы ир яки хатын һәр намазда рөкүгъ хәленә һәм сәҗдәгә киткәндә «Аллаһү әкбәр» — дип әйтү сөннәт.

*Сигезенчесе:* Имам рөкүгъ хәленнән аякка торганда:

سَمِعَ اللّٰهُ لِمَنْ حَمِدَهُ

*Сәмигәл-лаһү лимән хәмидәһ* — дип әйтү сөннәт.

Татарчасы: «Аллаһы тәгалә үзен мактаган кешенең мактавын ишетеп кабул итә!»

Имам рөкүгъ хәленнән аякка күтәрелгәндә ул сүзләрне әйткән вакытта аңа оеган җәмәгать исә:

رَبَّنَا لَكَ ٱلْحَمْدُ ۞

*Раббәнә ләкәл-хәмде*—дип әйтсә, сөннәт.

Татарчасы: «И Раббыбыз, һәрбер мактаулар сиңа гына тиешле-хас!»

Әгәр дә намаз ялгыз башка укыла икән, ул вакытта боларның икесен дә әйтү сөннәт санала.

*Тугызынчысы:* Имам өчен рөкүгъ һәм сәҗдә тәкбирләрен кычкырып әйтү, аңа оеган җәмәгатькә һәм ялгыз укучыларга яшерен әйтү сөннәт санала.

*Унынчысы:* Имам һәм аңа оеган җәмәгать, шулай ук ялгыз намаз укучы ир яки хатын өчен һәр намазның рөкүгында булганда өч мәртәбә:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَظِيمِ ۞

*Сөбханә раббийәл-газыйм* тәкбирен әйтү сөннәт. Әгәр дә биш тапкыр әйтсә, тагын да саваплырак.

*Унберенчесе:* Имамга да, аңа оеган җәмәгатькә дә, ялгыз укучыларга да сәҗдәдә вакытларында өч мәртәбә:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْأَعْلَى ۞

*Сөбханә раббийәл-әгълә*—дип әйтү сөннәт, биш яки җиде тапкыр кабатлау исә тагын да саваплырак.

*Уникенчесе:* Намазларда, әттәхияткә утырганда, ирләргә уң аякларының бармакларына, кыйблага каршы карап, сул аяклары өстенә утыру, хатыннарга исә аякларын уң якка чыгарып, сул як ботлары өстенә утыру сөннәт санала.

*Уночинчесе:* Һәр намазларның да соңгы утырышында, әттәхияттән соң салават һәм догалар уку сөннәт. Шулай да нәфел намазларда, мәсәлән, икенденең һәм йәсигъның әүвәлге сөннәтләре кебек

дүрт рәкәгатьне бер сәлам белән кылса, боларның һәр ике рәкәгате бер намаз булып, әүвәлге әттәхияткә утыруы фарыз булып, әттәхияттән соң салават һәм догаларын укып аякка калыкканда «Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкә исмүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә иләһә гайрүк» һәм «Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим» һәм «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» тәкбирләрен укыр. Ләкин дә өйләнең әүвәлге сөннәте һәм җомганың әүвәлге һәм соңгы сөннәтләре боларның һәр дүрт рәкәгате бер намаз булганлыктан, әүвәлге утырышы важиб саналып, әттәхияттән соң салават укылмас.

*Ундүртенчесе:* Намазлардан соң укылган салаватларга өстәп бу доганы уку сөннәт санала:

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ ❀

*Раббәнә әтинә фид-дөньйа хәсәнәтән вә филахирәти хәсәнәтән вә кыйнә газабән-нар*

Татарчасы: «И Раббыбыз, безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге нигъмәтләр бирсәң иде һәм безне җәһәннәмнең газап утыннан сакласаң иде!»

Яки бу дога укыла:

رَبَّنَا اغْفِرْلِي وَوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابِ ❀

*Раббәнә-әгъфирли вәл-вәлидәййә вә лил-мөэмининә йәүмә йәкумүл-хисаб*

Татарчасы: «И Раббыбыз, минем гөнаһларымны, ата-анамны, барча мөэминнәрне хисап көнендә ярлыкасаң иде!»

Әгәр дә бер кеше шушы сөннәтләрне намазыннан чыгарса, аларны калдырса, моның өчен һичбер гөнаһ юк. Фарызларны гына башкарып, сөннәтләрне калдыру бары тик савапны һәм Аллаһы тәгаләнең рәхмәтен генә киметер.

## НАМАЗНЫҢ ӘДӘПЛӘРЕ

*Беренчесе:* Кыямда вакытта сәҗдәгә китәсе урынынны карау намазның әдәпләреннән санала.

*Икенчесе:* Рөкүгъ кылганда аякларыңның өстенә карау — әдәп.

*Өченчесе:* Сәҗдәдә борыныңа карау — әдәп.

*Дүртенчесе:* Рөкүгъ һәм сәҗдә тәкбирләрен биш яки җиде мәртәбә әйтү — әдәп.

*Бишенчесе:* Сәлам биргән вакытта имам да, аңа ойган җәмәгать тә яки ялгыз намаз кылучы ир һәм хатын да янындагы фәрештәләрнең барлыгын онытмыйча, аларга да сәлам бирүе икәнлеген аңлап сәлам юллавы әдәп гамәлләреннән санала.

*Алтынчысы:* Әттәхияткә утыргач, алдыңа карау.

*Җиденчесе:* Сәлам биргән вакытта ике яктагы иңбашларыңа карау һәм болай дип әйтү:

اللّٰهُمَّ اَنْتَ السَّلَامُ وَمِنْكَ السَّلَامُ تَبَارَكْتَ يَا ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ ۞

*Аллаһүммә әнтәс-сәламү вә минкәс-сәламү тәбарәктә йә заль-җәлали вәл-икрам*

Татарчасы: «И Аллаһы тәгалә, Син бар бәлаләрдән саклаучы, һәрбер сәламәтлек Синнән генә, бәрәкәт иясе Син, и олылык һәм хөрмәт иясе булган Аллаһы тәгалә!»

*Сигезенчесе:* Фарыз белән сөннәт арасында зарур күрелмәгәндә дөнья хакында сөйләшмәү.

*Тугызынчысы:* Иснәгән вакытта мөмкин кадәр авызны зур итеп ачмаска тырышу, әгәр дә тыела алмый икән, авызны кул белән ябарга кирәк.

*Унынчысы:* Йөткермәскә тырышу. Әгәр дә ялгышлык белән йөткергән вакытында берәр аваз хасил булса, намазы бозылыр.

*Унберенчесе:* Намаз башлау тәкбирендә ирләр кулларын җиңнәреннән чыгарырга тиеш, хатыннар исә, киресенчә, кулларын җиңнәрендә калдырсалар яхшырак.

*Уникенчесе:* Намаз беткәннән соң, «Аятел-көрси» укып, утыз өч мәртәбә «Сөбханаллаһ», утыз өч тапкыр «Әлхәмдүлиллаһ», утыз өч кат «Аллаһү әкбәр» — дип әйтеп, ахырда:

لَا إِلَهَ إِلَّا ٱللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ ۝ لَهُ ٱلْمُلْكُ وَلَهُ ٱلْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ۝

*Лә иләһә иллал-лаһү вәхдәһү лә шәрикә ләһ. Ләһү-л-мүлкү вә ләһү-л-хәмдү вә һүвә галә күлли шәйин кадиир* — дип кулны күтәреп, дога кылу.

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгаләдән гайре илаһи зат юк һәм Аның шәриге булмас, барча мактауларыбыз Аңа тиешле. Ул барча нәрсәләрдән дә бөектер!»

## СӘҖДӘИ СӘҺҮ ЯКИ НАМАЗЛАРДА ЯЛГЫШЛЫКЛАР ХАКЫНДА ҺӘМ АЛАРНЫ ТӨЗӘТҮ

Сәҗдәи сәһү, ягъни намазларда ялгышулар *өч* төрле булырга мөмкин. Беренчесе, намазның эчендә фарызлардан берсен тиешле урынында эшләмичә кичектерү, икенчесе, намазның ваҗибләреннән берсен онытып калдыру, өченчесе, ваҗибләрнең берсен урыныннан кичектерү. Әгәр дә ир яки хатын намазларында шушыларның берсен эшләсә, аннан сәҗдәи сәһү таләп ителә. Әмма бу ялгышлыклардан намаз бозылмый, аларны төзәтү кирәк була. Шушы төзәтүне исә сәҗдәи сәһү дип атыйлар.

*Сәҗдәи сәһүне кылу рәвеше:*

Сәҗдәи сәһү намазның ахырында әттәхиятне укыганнан соң, имам булса, бер ягына, ялгыз укыган кеше булса, ике ягына сәлам биреп, намаз сәҗдәсе кебек ике сәҗдә итеп, тагын да әттәхиятне һәм салават, догаларны укып, сәлам биреп, намаздан чыгар.

Әгәр дә бер кеше сәҗдәи сәһү соралган эшне берничә мәртәбә кылса, аларның барсы өчен дә бер мәртәбә генә сәҗдәи сәһү үтәр.

Әгәр дә бер кеше намазда бер фарызны онытса, шул фарызны калдырганлыгы намаз эчендә хәтеренә төшсә, шулвакыт каза кылырга тиеш. Каза кылмаса, намазы бозылыр. Шунлыктан, намазы бозылу сәбәпле, намазын яңадан укыр. Чөнки сәҗдәи сәһү бары тик фарызны кичектерү сәбәпле генә була, әгәр дә фарызны калдырган икән, намазы бозылганлыгы беленер. Шуңа күрә дә намазы беткәннән соң хәтеренә фарызны калдыруы килсә, намазын кабаттан укыр.

Имамга оеган кеше сәҗдәи сәһү тиешле гамәлләр кылса да, аңа сәҗдәи сәһү тиешле булмас.

Әгәр дә сәҗдәи сәһү тиешле эшне кылган кеше имамга берничә рәкәгатькә соңарып оеган икән, имамның сәламеннән соң аягына торып, калган рәкәгатьләрне башкарса, шулвакыт сәҗдәи сәһү тиешле ялгышлык эшләсә, аңа сәҗдәи сәһү итү тиешле.

Бер кеше сәҗдәи сәһү тиешле булган эшне эшләп, онытып, сәлам биреп, «Аллаһүммә әнтәс-сәламү вә минкәс-сәламү тәбарәктә йә заль-җәлали вәл-икрам»ны укыса, шул вакытта хәтеренә төшсә, әгәр дә кыйбладан борылмаган икән һәм намазын боза торган гамәл кылмаган икән, сәҗдәи сәһүне үтәр. Әгәр дә кыйбладан борылган һәм намазны боза торган эшне кылган булса, намазы тәмам ителер. Онытып калдырганы өчен һичнәрсә лазем күрелмәс.

Имам булган кеше өйлә һәм икенде намазларында, онытып, кычкырып укыса, шулай ук иртәнге һәм ахшам, йәсигъ намазларының берсендә яшерен укыса, кычкырып укыла торган намазларда кычкырып, яшерен укыла торган намазларда яшерен укымак тиешлеге өчен, важибне куйганлыгы сәбәпле сәҗдәи сәһү таләп ителер.

Әгәр дә бер кеше ялгызы намаз укыса һәм кычкырып намаз кыласы урында яшерен, яшерен намаз укыйсы урында кычкырып укыса, аңа сәҗдәи сәһү важиб күрелмәс.

Бер кеше намазының ахырында сәлам бирер урынга җиткәч яки сәлам биргәннән соң намазын ким кылганын белсә, кыйбладан китмәгән икән яки намазын бозарлык һичнәрсә эшләмәгән икән, шунда ук аякка калкып, калган рәкәгатьләре ничә булса да, аны кылып, әттәхияткә утырып, сәлам биреп, сәҗдәи сәһү итәр.

Сәҗдәи сәһү мәсьәләсе шактый катлаулы һәм намазның һәр урынына бәйле яклары бар. Шунлыктан намазда мөмкин кадәр игътибарлы һәм сак булырга тырышлык кую кирәк. Моның өчен намазның фарыз һәм ваҗибләрен яхшы өйрәнергә, белемеңне җентекләп язылган китапларга таянып ныгытырга омтылу тиешле.

## НАМАЗНЫ БОЗУЧЫ ӘЙБЕРЛӘР

*Беренчесе:* Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытта кешеләр арасында сөйләнелә торган сүзләрне, дөнья хәлләрен сөйләшсә, ул вакытта аның намазы бозылыр. Намаз бозылу өчен ике ят авазхәреф җитә. Шунлыктан намазын яңабаштан укырга тиеш була. Намазда дөнья хәлләрен сөйләшергә ярамый, чын күңелдән Аллаһы тәгаләгә бирелү таләп ителә. Шулай ук намаздагы кешегә эндәшергә, аны ялгыштырырлык сүз әйтергә, намазыннан читләштерергә, кыйбладан борылдырырга ярамый, намазы бозылыр.

*Икенчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында көлсә һәм көлгәне янындагы кешегә ишетелсә, ул вакытта шулай ук намазы бозылыр, тәһарәте сынар. Әгәр дә көлгәнен үзе генә ишетеп яки белеп, янындагы кеше ишетмәсә һәм белмәсә, тәһарәте сынмас, әмма намазы бозылыр. Әгәр дә тәһарәте бозылмаслык рәвештә йоклап, шул вакытында көлсә, намазы бозылыр, әмма тәһарәте сынмас.

*Өченчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында туган-тумачасы, мал-мөлкәте, әти-әнисе, бала-чагасы хәсрәтеннән еласа, шулай ук елавына сәбәп тәнендәге авыру икән, сыктау тавышы белән булса, намазы бозылыр. Әгәрем ки елавына сәбәп тәмуг,

кабер кебек газаплардан курку, җәннәт хакында хәсрәтләнү һәм Аллаһы тәгаләдән, аның ачулануыннан курку сәбәбеннән исә, ул вакытта күңел йомшаклыгы дөрес һәм урынлы булыр, намазы да бозылмас.

*Дүртенчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында үзенең авыруы сәбәпле яки бер-бер кыенлык күрүеннән һәм башка төрле сәбәпләр аркасында «аһ, ух, уф» кебек ике хәрефле һәм авазлы авырыксыну сүзләрен ычкындырса, намазы бозылыр. Әмма кайбер шәригать китапларында бу ымсынулары ике хәрефле генә аваз булып, өч хәрефле түгел икән, бозылмый, диләр. Әмма хәнифиләр мәзһәбендә, ягъни ата-бабаларыбыз гадәтенчә, аңлатмалардан күренгәнчә, намаз бозыла.

*Бишенчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда төчкерсә яки кикерсә, үзенең ихтыярыннан тыш ике яки өч хәреф хасил булса да намазы бозылмас.

*Алтынчысы:* Әгәр дә бер кеше намазында бербер җире авыртудан «Йа Аллаһ», яки «Йа Рабби», яисә «Бисмилләһ» дисә, намазы бозылмас.

*Җиденчесе:* Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытта икенчесе аннан: «Аллаһы бармы?—дип сораса, намаз укучы җавабында: «Лә иләһә иллал-лаһ»—дисә, хәнифиләр мәзһәбеннән күренгәнчә, намазы бозылыр. Әгәр дә берәүгә икенчесе: «Синең фәлән эшеңне башкардым!»—дип әйтсә, җавабында намаз укучы: «Әлхәмдүлиллаһ»—дисә, хәнифиләр мәзһәбенчә, намазы бозылыр. Шулай да намаз укучы шушындый сүзләр белән үзенең намазда икәнлеген генә белдерергә уйласа, ул вакытта намазы бозылмас.

*Сигезенче:* Әгәр дә бер кеше намаз укыганда төчкерүдән «Әлхәмдүлиллаһ» дип иреннәрен кыймылдатмыйча күңеленнән генә әйтсә, намазы бозылмас, әгәр дә ишетелерлек итеп әйтсә, бозылыр.

*Тугызынчысы:* Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытта төчкерсә, аңа җавап итеп янындагы кеше: «Йәрхәмүкә Аллаһ»—дисә, намазы бозылыр. Шушы җавапка җавап итеп, беренче кеше: «Амин»—дисә, аның намазы да бозылыр.

*Унынчысы:* Әгәр дә имам намаз вакытында укый торган аятенең ахырын онытса, аңа намазда булмаган кеше әйтеп бирсә, имам аны кабатласа, шулай ук намазы бозылыр. Чөнки бу дәрес алу гамәленә карар, дөньяви эшләрдән хисапланыр.

*Унберенчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында борчак кадәрле нәрсә ашаса яки бер тамчы су эчсә, намазы бозылыр.

*Уникенчесе:* Әгәр дә ике кул белән эшләнелә торган гамәлне, ягъни чалма чалу, күлмәк-чалбарны күтәрү яки төзәтүне намаз эчендә бер кулы белән генә эшләсә, намазы бозылыр. Әгәр гадәттә бер кул белән эшләнелә торган эшне бер яки ике кулы белән бер-бер артлы өч тапкыр эшләмәсә, намазы бозылмас.

Әгәр бер эшне бер кулы белән туктап торганнан соң тагын туктап өч тапкыр кылса, әйтик бер урынын шул рәвештә өч тапкыр кашыса, намазы бозылыр. Әгәр дә аның шулай итүен икенче бер намаздагы кеше күреп торса һәм: «Бу намазда түгел икән!» — дип уйласа, аның да намазы бозылыр, әгәрем ки, «Бу кеше намаздамы-түгелме?» — дип уйлап алса, намазы бозылмас.

*Унөченчесе:* Әгәр бер хатын намазда вакытында күкрәгеп баласына каптырып, сөте чыкса, намазы бозылыр. Әгәр дә сөте чыкмаса, намазы бозылмас, әгәр дә бала өч мәртәбә суырып та сөте чыкмаса, намазы шулай ук бозылыр.

*Ундүртенчесе:* Намазда дошманлык, тәрбия, уен кебек эшләр кылынмас, шунлыктан, әгәр дә берәү намазда вакытта икенче кешегә камчы белән сукса, үзенең намазы бозылыр.

*Унбишенчесе:* Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытында мөәззиннең азан тавышын ишетсә һәм аны кабатласа, аның намазы бозылыр.

*Уналтынчысы:* Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытында Аллаһы тәгаләнең исемен яки Мөхәммәд пәйгамбәр исемен ишетсә һәм аңа җавап бирсә, ул вакытта аның намазы бозылыр.

*Унҗиденчесе:* Әгәр бер кеше намаз укыган вакытта аңа икенчесе якын килеп: «Урын бир!» — дип әмер итсә, намаз укучы беренче кеше аның әмеренә

буйсынса, ягъни Аллаһы тәгаләнең әмеренә буйсынудан читләшеп, бәндәнең сүзен тотса, ул вакытта аның намазы бозылыр.

Әгәр дә бер кеше үз теләге белән намазда урын күчсә, бераз тартылса, ул вакытта аның намазы бозылмас.

*Унсигезенчесе:* Әгәр дә намазда бүтән кешеләрдән дөньялыкта сорарга мөмкин нәрсәләрне Аллаһы тәгаләдән сорасаң, намазың бозыла. Әйтик, «Йа Аллаһы тәгалә, миңа бер хайваннан мал бир!», яки «Йа Аллаһы тәгалә, миңа бер хатын бир!», яисә «Йа Аллаһы тәгалә, минем бурычымны үтә!» — дисә, намазы бозылыр.

Әгәр дә намазда вакытында:

اَللّٰهُمَّ اغْفِرلِى وَلِوَالِدَىَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ*

*Аллаһүммә-әгъфирли вә ли вәлидәййә вә лилмөэминийнә вәл-мөэминәти* ягъни «Йа Аллаһы тәгалә, мине ярлыка, ата-анамны ярлыка, вә мөэминнәрне һәм мөэминәләрне ярлыка!» — дисә, яки:

اَللّٰهُمَّ ارْزُقْنِى جَنَّتَكَ*

*Аллаһүммә арзукни җәннәтәкә* ягъни: «Йа Аллаһы тәгалә, оҗмахыңны насыйп ит!» — дисә, яисә:

اَللّٰهُمَّ ارْزُقْنِى حَجَّ بَيْتِكَ*

*Аллаһүммә арзукни хаҗҗә бәйтикә* ягъни: «Йа Аллаһы тәгалә, хаҗ кылуны насыйп ит!» — дисә, намазы бозылмас. Чөнки боларны адәмиләрдән сорау мөмкин түгел, бары тик Аллаһы тәгаләнең иркендәге гамәлләрдер.

*Унтугызынчысы:* Әгәр берәү намазда кәгазьдән, яки китаптан, яки диварга язылганнан аять укып гамәл кылса, намазы бозылыр.

*Егерменчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында җирдән таш алса, бүтән адәмгә яки кошка аны ыргытса, намазы бозылыр. Шулай ук намаздагы кешегә бүтән бер адәм таш ыргытса, бу эше уен яки дошманлык белән булса, намазы бозылыр. Әмма ләкин ташы тимәсә, бүтән нәрсәгә ыргытылган исә, намазы бозылмас.

*Егерме беренчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында аның өенә икенче берәү килеп керсә, узарга рөхсәт сораса, шул вакытта намаз укучы хуҗа үзенең намазда икәнлеген белдереп, кычкырып укый башласа, яки «Әлхәмдүлиллаһ», яисә «Аллаһү әкбәр», яки «Сөбханаллаһ» — дип әйтеп куйса, намазы бозылмас.

*Егерме икенчесе:* Әгәр дә бер кеше, кыйбладан борылмыйча, намаз кылган вакытында бер саф алга яки артка китсә, намазы бозылмый. Әгәр дә ике сафны берьюлы, туктамыйча үтсә, намазы бозылыр. Мәгәрем ки бер саф күчеп, өч мәртәбә «Сөбханаллаһ» дигән вакыт микъдары туктап торып, тагын бер сафны күчсә һәм туктаса, намазы бозылмас. Әгәр дә шушы рәвешле йөреп, ике сафны узуга мәсҗидтән чыгып китсә, намазы бозылыр. Әгәр дә дала яки сахрада булса, алдындагы сафны узуга намазы бозылыр. Әгәр алдында саф булмаса, намазны мәсҗидтә башкарса, сәҗдә урыныннан узуга намазы бозылыр.

*Егерме өченчесе:* Әгәр дә бер кеше намазда вакытында икенче берәүне күреп, аңа «Сәлам» — дисә, шунда үзенең намазда икәнлеген белеп туктаса, «...галәйкүм»не әйтмәсә дә, ягъни сәламен «Әс-сәламү галәйкүм» дип тутырып әйтмәсә дә намазы бозылыр.

*Егерме дүртенчесе:* Әгәр намаздагы кешенең авызында татлы ризыктан тешенә ябышкан әйбер яки суыра торган ризык булып, аны йотса, намазы бозылыр. Чөнки намазда ризык ашаучы булыр, ә бу гамәл ярамый.

*Егерме бишенчесе:* Әгәр дә бер кешенең авызында ашаган вакытыннан теш арасына яки ирен астына борчак бөртегеннән кимрәк зурлыкта ризык калган булып, намаз вакытында аны йотса, уразада

булса да, ураза һәм намазы бозылмас. Әгәр дә борчак зурлыгында исә, уразасы бозылыр.

*Егерме алтынчысы:* Әгәр бер ир намазда вакытында хатыны янына килеп, аны кочакласа, ирендә иркәләтү теләге тумаса, намазы бозылмас. Әгәр намаздагы хатынын ире кочакласа яки үпсә, намазы бозылыр.

*Егерме җиденчесе:* Әгәр дә намазда Коръән аятьләрен укыганда авазлары дөрес әйтелмичә, буталып укылса, шулай ук намаз бозылыр.

*Егерме сигезенчесе:* Әгәр дә намазда ирләр хатыннар белән бер сафта аралашып яки буталып укысалар, намаз бозылыр.

*Егерме тугызынчысы:* Иртәнге намазны укыганда кояш чыга башласа, намаз бозылыр.

*Утызынчысы:* Намаз шунда бозыла, әгәр дә гаурәт әгъзаның дүрттән бер өлеше ачылса, намаздагы фарыз булган берәр гамәл кылынмыйча калдырылса, күкрәк кыйбла тарафыннан борылса, тәне, киеме яки намаз укый торган урыны нәҗесләнсә, тәһарәте үз ихтыяры белән бозылса.

Күңеленне бары тик Аллаһы тәгаләгә генә багышлап, игътибарлы рәвешендә укыганда намазың һичвакыт бозылмас!

## НАМАЗНЫ ҮТӘГӘНДӘ КИҢӘШ ИТЕЛМИ ТОРГАН, ЯГЪНИ МӘКРУҺ БУЛГАН ГАМӘЛЛӘР ХАКЫНДА

*Беренчесе:* Намазда авызны һәм борынны нәрсә белән булса да каплау, авызны ачып иснәү киңәш ителми. Әгәр дә инде иснәмәү бөтенләй дә мөмкин түгел икән, ул вакытта аны кул белән каплап, яшереп иснәү рөхсәт ителә.

*Икенчесе:* Намаз укыганда киерелү киңәш ителми, чөнки бу халәт бәндәнең намазга ихтыяры юклыгын күрсәтеп тора.

*Өченчесе:* Сәҗдәгә киткәндә кулларны тезләреңнән алда җиргә һичбер сәбәпсез кую киңәш ителми, шулай ук сәҗдәдән күтәрелгәндә кул белән җиргә яки бүтән нәрсәгә таяну да киңәш ителми.

Зарурлык күренмәгәндә, ике аякларны кадап, янбаш өстенә утыру, сәждәдә беләкләрне җиргә тидереп тору, тиз ятып, тиз тору киңәш ителми, мәкруһ санала.

*Дүртенчесе:* Намазда ике кулны да билгә таянып тору, масайган кыяфәт чыгару, киемнең итәген җиргә тимәсен дип тотып тору, сәбәпсездән аякларны бөкләп утыру, рөкүгъ хәлендә башны биленнән югарырак яки түбәнгә таба бөгү һәм күзләрне йому киңәш ителми, мәкруһ гамәлләрдән санала.

*Бишенчесе:* Намаз укыганда бармакларны шартлату киңәш ителми, шулай ук өйлә вакытында, намаз кылганчы яки кылганнан соң да бармакларны шартлату начар гадәт исәпләнелә, чөнки бармак шартлату Лут пәйгамбәрнең кавеме гамәлләреннән булган һәм бозык эшләрдән исәпләнгән.

*Алтынчысы:* Намазны яланбаш уку мәкруһ исәпләнелә. Әмма дә ләкин сәҗдәгә киткәндә баштан кәләпүш яисә чалмаң төшә икән, бүтәннәр аннан көлергә мөмкин исә яки көлүләренә сәбәпче булса, бер кул белән шул чалмаңны яки кәләпүшеңне кию сорала, әмма мөмкин түгел икән, ул вакытта яланбаш намаз уку мәкруһ саналмас.

*Җиденчесе:* Ислам динендә булган кешеләргә Мөхәммәд пәйгамбәр таякка таянып торуны, диварга сөялүне, бармакларны бер-берсе арасына тыгып торуны тыйган. Намазны укыганда да һичбер сәбәпсез таякка таянып, диварга сөялеп, бармакларны аралаштырып тору бозык һәм киңәш ителми торган гамәлләрдән санала.

*Сигезенчесе:* Әгәр дә киемең була торып та күлмәк-ыштаннан гына, өстеңә башка киемнәр кимичә намаз укысаң, шулай ук бозык гамәлләрдән санала. Инде дә алардан бүтән кияр киемең юк икән, ул вакытта мәкруһ түгел.

*Тугызынчысы:* Укыган сүрәне рөкүгъ хәленә кергәч тәмамлау мәкруһ була, чөнки рөкүгъ хәле Коръән аяте уку урыны түгел, шулай ук рөкүгъ һәм сәҗдә тәсбихләрен калдыру яки өчтән ким әйтү мәкруһ гамәлләрдән санала, чөнки сөннәт бозыла.

*Унынчысы:* Намазда йөткерү мәкруһ санала, әмма дә ләкин йөткерергә көчле булса, ихтыярсыз килсә яки какырыгы аны Коръән аятен укудан аерса, комачауласа, ул вакытта йөткерү мәкруһ саналмас. Әмма йөткермәскә тырышырга кирәк. Чөнки йөткергән вакытында өч хәреф-аваз хасил булырга мөмкин, шул вакытта аның намазы да бозылачак.

*Унберенчесе:* Рөкүгъ хәленнән кайткач һәм ике сәҗдә арасында торганда бер тапкыр гына булса да «Сөбханаллаһ» дип әйтерлек вакыт аралыгы тынып калуны ташлау шулай ук мәкруһ гамәл исәпләнелә, вәҗиб бозыла.

*Уникенчесе:* Намазда ис иснәү — мәкруһ гамәл, әмма ул ис ихтыярсыз рәвештә борынына керә икән, мәкруһ булмас. Шулай ук намазны беләккә кадәр җиңнәреңне сызганган хәлдә уку мәкруһ.

*Уноченчесе:* Намазда беренче рәкәгатьтә укыган сүрәне фарызның икенче рәкәгатендә уку мәкруһ гамәл санала. Әгәр дә онытып укыса яки бүтән сүрәне белмәсә, ул вакытта мәкруһ түгел. Әмма нәфел намазларында икенче рәкәгатьтә дә шул ук сүрәне уку мәкруһ түгел.

*Ундүртенчесе:* Беренче рәкәгатьтә укыган сүрәдән икенче рәкәгатьтәге сүрәсендә өч аять микъдары артык уку мәкруһ. Әмма икенденең һәм йәсигъның сөннәтләрендә һәм дә нәфел намазларында өченче рәкәгатьнең сүрәсен озын уку мәкруһ түгел, дүрт рәкәгатьне бер сәлам белән кылса да, һәр ике рәкәгате бер намаз исәпләнгәнлектән, өченче рәкәгать әүвәлге рәкәгать кебек була.

*Унбишенчесе:* Кыямнан бүтән урында, ягъни рөкүгъ хәлендә, сәҗдәдә, әттәхияттә Коръән аятьләре уку мәкруһ санала. Әмма намаздан соң дога нияте белән аятьләр уку ярый торган догалар бар, аларда Коръән уку мәкруһ түгел.

*Уналтынчысы:* Намаз вакытында йөзеннән тирне сөртү, туфрак-тузанны кагу мәкруһ була, әмма дә ләкин бу гамәлендә үзе өчен файдалы нәрсә бар исә, ягъни бер-бер авыртудан арындырса, ул вакытта бу гамәлендә мәкруһлык юк.

*Унҗиденчесе:* Кешенең йөзенә каршы утырып намаз уку киңәш ителми торган гамәлләрдән санала. Әгәр дә икесенең арасында бер кеше булып, ул адәм намаз укучыга аркасы белән торса, ул вакытта мәкруһлык юк. Кешенең йөзенә карап намаз уку сурәткә гыйбадәт кылу буларак аңлатыла.

*Унсигезенчесе:* Сурәт төшерелгән намазлык өстендә һәм сурәтле кием киеп намаз уку киңәш ителми, мәкруһ санала. Әгәр дә сурәт түшәмдә, яки диварда, кыйбла ягында, яки аякларында, яисә кулларында һәм бүтән шуның кебек намаз укыганда күренә торган урыннарда булса, намаз уку мәкруһ була. Әгәр дә сурәт намаз укучының аркасында исә, артында бүтән берәү намаз укымаса, мәкруһ булмас. Әгәр дә сурәт бәндәнең артында икән, ул вакытта бу рәвешле намаз укуы шул сурәтне хурлау буларак аңлатыла. Шулай ук намазда гына түгел, бүтән вакытларда да мөселман кешеләргә сурәтле кием кию киңәш ителми. Әгәр дә ул сурәтләрнең башлары булмаса яки бик кечкенә рәвештә ясалып, бик җентекләп карамыйча, сурәт икәнлекләре беленмәсә, андый киемне кию мәкруһ түгел.

*Унтугызынчысы:* Җәмәгать белән намаз кылганда, алдындагы сафта урын була торып та артта үзеңә саф ясап, намазны шулай уку мәкруһ санала. Әгәр дә алдагы сафта ачык урын булмаса, ул вакытта — ярый. Шулай да җәмәгать белән намаз укыган вакытта үзеңә аерым саф ясап намаз кылу дөрес түгел.

*Егерменчесе:* Җәмәгать фарызны укыганда, саф эчендә яки артында икенче берәүнең сөннәтне укуы мәкруһ була. Шунлыктан ул ашыгучы зат, яки мәсҗиднең сөннәт бүлмәсендә, яки бер почмакта намазының сөннәтен укыр.

*Егерме беренчесе:* Буш урында, далада, кырда, намаз укыган вакытта алдыннан кеше узарга мөмкин икән, ул вакытта каршысына таяк кадап куймыйча намазга утыру мәкруһ санала. Шулай ук кеше йөри торган җирдә, мунчада, юл өстендә, каберләр арасында намаз уку мәкруһ санала. Әмма мунчаның шул мунчада аерым, чиста тотылган почмагы булса, каберлектә бер йорт кебек

урын эшләнелеп, анда кабер куелмаса, ул урыннарда намаз уку мәкруһ түгел.

*Егерме икенчесе:* Намазда бер сүрәне укый башлап, аны тәмамламыйча ташлау яки укыган сүрәсендә берәр аятьне онытып калдыру шулай ук мәкруһ санала. Әгәр дә инде намаздагы кеше шул сүрәсенең ахырын онытса, әмма намазы дөрес булырлык микъдарда аятьләрне укыган булса, яки рөкүгъ хәленә китәр, яки бүтән сүрәне укып тәмам итәр, ул вакытта мәкруһ саналмас.

*Егерме өченчесе:* Имам булган кеше әгәр дә артык озын сүрәне намазда укыса, җәмәгате ялыгырлык исә, ул вакытта мәкруһ саналыр, мәгәрем ки җәмәгать ялыгырлык түгел икән, мәкруһ исәпләнмәс. Әгәр дә имам сөннәт хасил булырлык дәрәҗәдә укып та аятенең ахырын онытса һәм рөкүгъ хәленә китмәсә яки сөннәт хасил булырлык дәрәҗәдә укымаса, икенче аятькә күчмичә, аятьнең ахырын җәмәгатенең укып бетергәнен көтеп торса, мәкруһ саналыр.

*Егерме дүртенчесе:* Сөннәт булмаган намазлардан соң имам әгәр дә кыйблага карап, утырып кала икән, ягъни җәмәгатенә борылмаса, хәтта бер генә кеше аңа оеган булуга да карамастан, бу гамәле мәкруһ исәпләнелә.

*Егерме бишенчесе:* Колны, divананы һәм сукыр кешене имам итү мәкруһ исәпләнелә. Шулай ук бозык кешене имам итәргә ярамас. Әгәр дә кол һәм авыру кеше гыйлем иясе икән, ул вакытта аларны имам итәргә ярый. Сукыр кеше нәҗестән саклана алмаганлыктан, имам була алмый, әмма чисталык-пөхтәлектә өстен һәм бик тә сизгер икән, ул вакытта мәкруһ булмас.

*Егерме алтынчысы:* Мөхәммәд пәйгамбәрдән шундый хәдис кылә, ул әйткән: «Әгәр дә бер кеше намаз кыла торган бәндәнең каршыннан узуның ни кадәр зур гөнаһ икәнлеген белсә, кырык ел көтеп торыр иде!»,— дигән. Шунлыктан, намаз кыла торган кешенең алдыннан узу мәкруһ санала. Әгәр дә намаз укучы чаршау артында, яки арты белән торган кешенең артында, яки таяк кадалган урында булса, ягъни намаз укучы белән үтеп баручы ара-

сында аларны аерырлык нәрсәдер булса, ул вакытта үтеп китү мәкруһ түгел.

Шунсы да мәгълүм булсын, әгәр дә бер кеше алдагы сафта урын буш икәнлеген күрсә, анда күченсә, намазы бозылмас, киресенчә, аңа карата җәмәгатьнең хөрмәте артыр. Әгәр дә инде алдындагы сафта урын буш калып та, аны күрү белән күченмәсә, ул намаз кылучыга хөрмәт бетәр.

*Егерме җиденчесе:* Мәсҗидтә кешеләрнең җилкәсе аша атлап, алдагы сафка үткән кешенең бу рәвешле йөреше дөрес булмас. Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Бер кеше мәсҗидтә мөселман карендәшләренең җилкәсеннән атлап узса, ул кеше Кыямәт көнендә тәмугка узучыларның аяк асларында күпер булып, өстеннән таптап барырлар!» — дигән. Дөньялыкта кешеләрнең җилкәсеннән һичкайчан атлап чыгарга ярамас.

Әгәр дә аш хәзерләнелеп, күңелләр ризыкка тартылса, пешерелгән азык суынырга мөмкин икән, ул вакытта алдан тукланмыйча намазга керү мәкруһ була. Шулай ук утка каршы намаз уку мәкруһ, имамнан алда башны кую яки күтәрү дә мәкруһ. Әмма чыра, лампа, электр уты кебек утлар каршысында намаз уку дөрес булыр.

*Егерме сигезенчесе:* Намазда кул һәм аяк бармакларын кыйбла тарафыннан читкә сузу һәм һәртөрле ваҗиб, сөннәтне бозу мәкруһ санала.

*Егерме тугызынчысы:* Әгәр дә намаз укучы кешене тиз кирәк булуы сәбәпле чакырсалар, аның файдасы үзенә яки башкага булуына да карамастан яки бәладән коткару өчен исә, намазны дәвам итүе дөрес түгел, тәмамласын яисә өзсен.

*Утызынчысы:* Намазда гозерсез бер яки ике адым йөрү мәкруһ санала. Әгәр дә рәттән өч адым атласа, намазы бозыла. Әгәр дә һәр адым саен бераз туктап тору рәвешендә йөрсә, намазы бозылмый, әмма мәкруһ гамәлләрдән исәпләнелә. Әгәр дә мәкруһ икәнлеген белә торып та шуны намазда берничә тапкыр эшләсә, намазы бозыла. Мондый очракта намазны яңабаштан укуы таләп ителә. Әгәр дә алай киңәш ителмәгәнлеген белеп тә, онытып кылса, сәҗдәи сәһү таләп ителә.



5 н-330

## НАМАЗДА ТӘҺАРӘТНЕҢ БОЗЫЛУ ОЧРАКЛАРЫ ХАКЫНДА

Бер кешенең намазда ихтыярсыз тәһарәте бозылса, шунда ук урыныннан торып, бүтән эшләр белән шөгыльләнмичә, китеп, намаз бозылырлык гамәлләр кылмыйча, тәһарәт алыр һәм шул намазында кайсы урында калган булса, шуннан башлап, намазын ахырына кадәр үтәр. Тәһарәт өчен су алу, кыйбла тарафыннан авышу сәбәбеннән намазы бозылмас. Әгәр дә ул кешенең тәһарәте рөкүгъ хәлендә бозылган икән, аягына торган вакытта «Сәмигәл-лаһү лимән хәмидәһ» дисә, яки тәһарәте сәҗдәдә сынып, башын күтәргәндә «Аллаһү әкбәр» дисә, яки тәһарәте бозылгач, бераз вакыт югалып калса, яңадан тәһарәтләнгәндә, тәһарәт алу урынына барганда яисә кайтканда сүз сөйләшсә, яки Коръән укыса, шул намазын дәвам итү дөрес түгел. Тәһарәте бозылган урыннан башлап китмичә, бу очракта намазын яңадан башлап укыр.

Әгәр бер кешенең ялгыз башына намаз укыганда тәһарәте бозылса, аны яңартканнан соң, теләгенә карап, намазын, яки элек намаз укыган җиренә кайтып тәмамлар, яисә үзе теләгән урында укып бетерер. Шулай да намазын яңабаштан башлап укып бетерү дөресрәк булыр.

Әгәр дә берәү намазын җәмәгать белән кылган вакытта тәһарәте сынса, ул вакытта, җәмәгать белән бергә намаз уку саваплырак булганлыгы өчен, намазын тәһарәте сынган урынга кайтып, шул җирдән башлап китеп тәмам итәр. Әмма ул вакытта җәмәгать намазны тәмамлаган исә, бу кеше үз ихтыяры белән, яки элекке урынына кайтып, намазын ахырына кадәр укып бетерер, яки яңадан башлап кылыр, яисә бүтән урынга күчеп, намазын яңадан башлап ахырына кадәр укып бетерер.

Бер кеше имамга оеп, намазында бер рәкәгать укыганнан соң икенче рәкәгатьнең кыямында тәһарәте бозылса, шунда ук борынын тотып китәр, тәһарәтен яңартып килер. Ул кеше килгәндә имамы әттәхияткә кергән булса, элгәре калган рәкәгатьләрне караәтсез генә башкарыр, аннан соң

имамга әттәхияттә ияреп, имам белән сәлам бирер. Намазы үтәлер.

Әгәр дә намаз укыган вакытта имамның тәһарәте бозылса, җәмәгатьтә имам була алырлык бер кешене ишарәт илә яки киеменнән тартып, үзе урынына имам итеп калдырыр, тәһарәтен яңартырга юнәлер. Үзе урынына калдырган кешесе белән сүз сөйләшмәс, әгәр дә сөйләшсә, намазы бозылыр.

Имам үз урынына калдырган кеше җәмәгатькә соңарып кушылган мөэмин булса да имамлыгы дөрес була, әмма арада бүтән берәү имамлык итәрлек дәрәҗәдә исә, аны калдыруы яхшырак санала.

Намазга соңга калган кеше, имамлык итсә дә, сәламне бирер өчен җәмәгатьтән берәүне үз урынына кертер.

Әгәр дә имам, бер аятьне укыгач, тәһарәтен ихтыярсыз сындырса, үз урынына килгән, имамлыкка чыгарган кешесенә белдерер өчен авызына кулын куяр, бу исә аны караәт итмәгәнлегенә ишарәт булыр, аның урынына кергән кеше караәт укыр. Әгәр тәһарәте рөкүгъ хәлендә бозылса, моны белдерү өчен имам ике кулын да тезләре өстенә куяр. Әгәр дә тәһарәте сәҗдәдә бозылган исә, кулын маңгаена куяр, әгәр әүвәлге рәкәгатьтә бозылган булса, бер бармагы белән, икенчесендә — ике бармагы, өченчесендә — өч, дүртенчесендә — дүрт бармагы белән ишарәт итәр. Әгәр дә сәҗдәи тиләвәт кыласы булса, телен чыгарып, бармакны теле өстенә куеп, соңыннан маңгаена куяр. Мәгәрем ки сәҗдәи сәһү кыласы булса, бармагын кендеге өстенә куеп ишарәт ясар.

Әгәр дә бер кеше намаз укыган вакытта күршедәге мөэмин ишетерлек итеп көлсә, шулай тәһарәте бозылса яки тәһарәте берәр хайван тешләгәннән соң кан чыгу белән бозылса, ул намазын, тәһарәт яңартып, бозылган урыныннан башлап тәмамлау ярамас, аны яңадан укыр.

Әгәр дә бер кешенең намазда тәһарәте бозылып, янындагы сөннәт кадәрле суны калдырып, икенче урынга суга китсә, бу ике су арасы ике саф арасына тигез икән, болай эшләвендә зыян юк,

тәһарәтен яңартып, намазын тәмамлавы дөрес була. Әмма дә ике су арасында ике саф намаз укучылар арасыннан ераграк ара икән, ул вакытта намазы бозылыр, яңабаштан башлап уку таләп ителер. Әмма дә ләкин, ике суның беренчесе коеда булып, икенчесе савытта яки елгада икән, ул вакытта намазы бозылмас, хәтта ике сафтан артыграк адым йөрсә дә. Шулай ук беренче очраткан суы сөннәт микъдары тәһарәт алырга җитәрлек булмыйча, икенче чыганакка күчсә, шулай ук намазы бозылмас.

Әгәр дә тәһарәтен яңартырга барганда гаурәт җире ачылса яки үзе ачса, моны эшләүдә ихтыяҗ күренмәсә, намазы бозылыр. Әмма гаурәтен ачмыйча мөмкин түгел икән, ул вакытта намазы бозылмас.

Әгәр дә бер кешенең сәҗдәдә яки рөкүгъ хәлендә тәһарәте бозылса, тәһарәтен яңартканнан соң шушы сәҗдәсен яки рөкүгын кайтаруы тиешле.

Тәһарәте бозылганнан урынын калдырып киткән кешене җәмәгать тәһарәте сынудан дип белмичә, борыны канаудан дигән рәвешле уйларга тиешләр.

*Уникe очракта намазны тәһарәт яңартудан дәвам итмичә, кабаттан башлау таләп ителә:*

1. Тәһарәтен үз ихтыяры белән бозу сәбәпле.
2. Намаз эчендә һушы китү аркасында бозылу сәбәпле.
3. Диваналанып бозуы сәбәпле.
4. Намаз өчен госел ваҗиб булу сәбәпле.
5. Тавыш белән кычкырып көлү сәбәпле.
6. Тимер акча зурлыгы нәҗеснең киемгә яки тәнгә тиеп, аны юарга китү сәбәпле.
7. Бүтән берәүнең ялгышына игътибарлык белән тәһарәт бозылу сәбәпле.
8. Тәһарәт бозылып, су эзләргә киткәч, ишарәт белән суны барлау сәбәпле.
9. Тәһарәткә барып кайткан арада Коръән укуы сәбәпле.
10. Тәһарәт өчен суны акча белән сатып алу сәбәпле.

11. Тәһарәт бозылганнан соң тиз ара күтәрелми китмичә, бераз вакыт аралыгы утырып тору сәбәпле.

12. Тәһарәтем бозылды дип уйлап, тәһарәт алырга бару һәм бозылмаганлыгын белү, ялгышу сәбәпле.

## НАМАЗДА КОРЪӘННЕ ЯЛГЫШ УКУ МӘСЬӘЛӘСЕ

Билгеле булырга тиеш: намазда Коръән аятьләрен ялгыш уку намазның бозылуына китерә.

Әмма кайбер урыннарда Коръәндә булмаган сүзләрне укудан намаз бозылмаска да мөмкин. Бу исә *дүрт* төрле очракта күзәтелә:

*Беренчесе:* Укыган сүзе Коръәндә бүтән урында булса, әмма мондагы сүз белән мәгънәләре туры килсә яки якын мәгънәдә икән, ул вакытта намазы бозылмас. Әйтик, «Әл-Галим» дип укыйсы урынга «Әл-Хәким» дисә, мәгънәләре якынлык сәбәпле һәм Коръәндә ул сүзнең кулланылуы аркасында намаз бозылмас.

*Икенчесе:* Әгәр дә намазда укыган сүзе Коръәндә булмаса, әмма мәгънәләре якын исә, намазы бозылмас.

*Өченчесе:* Намазда Коръәндә булмаган һәм мәгънәсе тиешле сүздән ерак булса, намазын Коръәнне ялгыш укуы сәбәпле бозар.

*Дүртенчесе:* Намаз укыган вакытта Коръәндә булган, әмма мәгънәләре капма-каршы сүзне дөрес сүз урынына куеп уку сәбәпле намазы бозылыр.

Әгәр дә намаз укыганда Коръән сүзләренең авазларын дөрес әйтмәсәң, намаз бозыла. Әмма дә ләкин сакау «с» урынына йомшак «с», каты «т» урынына йомшагын һәм шуның төсле яңгырашта бер-берсенә якын торган авазлар белән укысаң, намазың бозылмас. Шулай да капма-каршы мәгънә хасил ителмәскә тиешле. «А» урынына «ә» уку, «ү» кирәктә «у» яки «ө», «о» авазларын әйтү дә намазны бозмас. Әгәр дә күплек сан урынына берлек сандагы сүзне кулланса да, мәгънәгә хилафлык кил-

мәве сәбәпле, намаз бозылмас. Әгәр дә хәрефләрнең урыннарын алыштырып укыса, ягъни «кадир» урынына «карид» дип укыса, мәгънәгә хилафлык китерсә, намазы бозылыр.

Әгәр дә намазда Коръән аятен укыганда сүзләрен калдырып китсә, шул сәбәпле мәгънә бозылса, намазы да бозылыр. Бу бигрәк тә инкарь сүзләрен калдырудан була. Мәгәрем ки, мәгънә аятьнең берәр сүзен калдырудан бозылмаса, намазы да бозылмас. Әйтик, «Фатиха» сүрәсендә: «Әл-хәмдү лиллаһи раббил-галәмин. Әр-рахмәнир-рахим. Мәлики йәүмид-дин...»—диясе урынга, «Әр-рахмәнир-рахим»ны калдырып, «Әл-хәмдү лиллаһи раббил-галәмин. Мәлики йәүмид-дин»,—дип укыса, намазы бозылмас.

Намазда Коръән укыган вакытта бер сүзнең ахыргы хәрефен икенче сүзнең әүвәлге хәрефенә кушып укыса, әйтик «Иййәкә нәгъбүдү»не «Иййә кәнәгъ бүдү»,—дип укыса, намазы бозылмас.

Әгәр дә Коръән укыган вакытта тәшдитле хәрефне тәшдитсез укыса, намазы бозылмас. Әмма дә ләкин «иййәкә» урынына «ийәк» дисә яки «Рабби» урынына «Раби» дип укыса, мәгънәгә хилафлык килү сәбәпле намазы бозылыр.

Әгәр дә сакау кеше икән, Коръәннең хәрефләрен дөрес әйтеп укырга тырышырга тиеш, мөмкин түгел исә, ул вакытта намазы бозылмас. Шулай да сакау ирләргә имамга оеп уку дөрес булыр.

Шунсы мәгълүм, кемнәр намазларын дөрес итеп, хәрефләрен төгәл һәм ачык сөйләп укыдылар, алар газаплардан арындырылып, савапка ирешерләр. Шунлыктан Коръәнне яхшы белгән кешеләрдән аятьләрне укырга өйрәнү киңәш ителә. Ялгыш уку савап бирми, киресенчә, газапларга гына салырга юл ача. Һәр халык үзенә күрә үз телендәгечә итеп сүзләрне укый. Бу—мәгълүм әйбер. Ә Коръән гарәп телендә иңдерелгән, никадәр генә тырышсак та, авазларны үзебезчә әйтә бирәбез. Шул сәбәпле намазда, ялгыштан куркып, догаларны, һич булмаса, татарча укысаң да ярый. Бары тик кыйраәт өлешендә генә гарәпчә уку фарыз икәнлеген онытмыйк.

## МӨСАФИРЛАР ХАКЫНДА

Мөсафир булу өчен вакытында ашап һәм йоклап сәяхәт иткәндә өч көнлек юл исәпләнер, туксан чакрымлы юл белән җәяүлегә исәпләнелер. Әгәр дә уртача йөрешле машина белән яки бүтән төрле хәрәкәт чарасы исә, шулай ук өч көнлек юл йөрүе мөсафирлык булыр. Авыл капкасыннан яки шәһәрнең соңгы йортыннан үтеп киткән вакытыннан башлап кеше мөсафир булыр. Шунда әйләнеп кайтуына мөсафирлыктан чыгар. Әгәр дә бер җиргә кыскарак юл белән, ягъни өч көннән азрак вакыт сарыф ителә торган юнәлештә барып кайтса яки тиз йөрешле хәрәкәт чарасы белән өч көннән азрак йөрсә, мөсафир исәпләнмәс, намазларын вакытында укыр, кыскарту кылмас.

Мөсафир исәпләнгән мөэминнәр дүрт рәкәгатьле фарызны ике рәкәгать кенә укырлар, ике-өч рәкәгатьле намазларны кыскартмаслар. Әгәр дә рамазан аенда юлга чыкса, беренче көнендә уразасын тотар, икенче көненнән башлап уразасы ярамас, кайткач тотуы өчен казага калдырылыр.

Мөсафир кеше бары тик иртәнге намазының гына сөннәтләрен укыр, калганнарыныкын куяр. Әгәр дә мәшәкате күренмәсә, аларын да укыса ярый.

Мөсафир кеше дүрт рәкәгатьле намазны ике рәкәгать кенә укымыйча, дүртесен дә укыса, гөнаһлы булыр. Чөнки аңа ике рәкәгать уку гына фарыз, дөрес укымавы сәбәпле намазы бозылыр.

Әгәр дә бер мөсафир кеше мөсафир булмаган имамга оеса, бар рәкәгатьләрне укыр, шулай дөрес булыр. Әмма имам кеше үзе мөсафир икән, аңа намазга оюю дөрес булыр. Әмма мондый имам ике рәкәгатьне укыгач, сәлам биреп, намазын тәмамлар, аңа оеган җәмәгатькә: «Мин — мөсафир»,— дип белдерер, алар исә калган ике рәкәгатьне караәтсез генә тәмамларлар.

Әгәр дә бер мөсафирның намазы казага калса, әйләнеп кайткач, аны ике рәкәгать укып кайтарыр. Әгәр дә өйдә вакытында казага калган намазы булса, мөсафир вакытында аны кайтарырга теләсә,

ул намазы дүрт рәкәгатьле булган икән, казаны кайтарган вакытында да дүрт рәкәгать укыр.

Мөсафир кеше үзенең шәһәреннән яки авылыннан китеп, икенче бер шәһәр яки авылга килгәч, әгәр дә унбиш көн яки аннан да артыграк торырга ниятләсә, мөсафирлыктан чыгар, мәгәрем ки унбиш көннән азрак торырга уйласа, мөсафир булып калыр. Әгәр дә сахрага чыгып, чатырларда торуны ниятләгән исә, ул вакытта, унбиш көннән артыграк торса да, барыбер мөсафир булып кала бирер.

Әгәр дә юлчы-мөсафир бер шәһәр яки авылга килеп, монда эшем өч-дүрт көннән бетәр, кире кайтырмын дип уйласа, әмма теләгенә каршы эше унбиш көн яки артыгракка китсә, хәтта берничә елларгача сузылса да һаман мөсафир хөкемендә кала бирер. Монда торуны ният итмәгәнлеге өчен мөсафирлыктан чыкмас һәм мөсафирга фарыз булганча намазларын башкарыр.

Әгәр дә мөсафир имам дүрт рәкәгать намаз укыса, аңа җәмәгать оеса, намазлары бозылыр. Чөнки мөсафир имамның беренче ике рәкәгать намазы фарыз булып, калган икесе нәфел саналыр. Фарыз намазын башкаручыларның нәфел намазын кылучыга оюлары наданлык һәм бозыклык исәпләнелер.

Әгәр дә бер хатын, кол, гаскәр кебек хуҗаларына, башлыкларына буйсынган кешеләр мөсафир икән, әмма унбиш көн торырга хуҗалары ниятләгән исә, мөсафирлыктан чыгалар. Аларның үз башларына ниятләүләре дөрес булмас. Хатын иренә буйсыныр һәм бүтәннәр дә шулай. Ирләре ниятләсә, хуҗалары уйласа, шул булыр. Чөнки болар үз теләкләре белән генә хәрәкәт итмәсләр, кешеләрен тыңларлар.

Әгәр дә гаскәр башы ният иткәнне гаскәре белмәсә, ире ниятләгәнне хатыны белмәсә, буйсынган кеше хуҗасының ниятен белмәсә, мөсафир рәвешендә калуын уйласа, мөсафирлар кебек намаз кылуы дөрес. Әмма билгеле булуга, намазларын тәмам тутырып укый башларлар.

# КАЗА МӘСЬӘЛӘСЕ

Балигълык яшенә җитеп, камил акыл иясе кеше әгәр дә намазларын укымаган, ураза тотмаган, зәкәт бирмәгән, корбан чалмаган икән, бу фарызларны үтәмәгәнлеге өчен алар каза кылынырлар, үз вакытында үтәлмәгән эшне үтәп, өстән төшерерләр. Шулар аркасында, соңыннан бар фарызларны да камил итеп үтәп тә каза кылмаган икән, ул кеше бәлаләнер, газапка тиешле булыр. Никадәр генә казаланган гамәлләре булса да, Аллаһы тәгаләдән гафу сорап, казаларын кайтарса, ул ярлыкаланылыр, гафу ителер. Шунлыктан казаны кайтару тиеш эш. Әгәр дә сау-сәламәт вакытында казага калдырып, авырый башлагач казаларын ишарәт белән кире кайтарса да дөрес булыр, кабул ителер. Шулай ук кичтән калган казаларын көндез, көндезгеләрен исә кич белән кайтарса да дөрес булыр. Аллаһы тәгалә рәхим һәм шәфкать иясе, тәүбә сорап килгән бәндәләренә мәрхәмәт итәр!

Әгәр дә бер кеше үзенең никадәр намазы казага калганлыгын белмәсә, инде утыз яшьләренә, әйтик, ирешкән булса, әүвәле ун елын сабыйлык яшенә кертеп, калган егермесен каза итәр. Шулай ук витр намазларын каза итеп кайтарыр. Бары тик фарыз намазлары гына каза ителер, сөннәт намазлары каза итеп кайтарылмас. Әгәр дә ялгышып укыган булса, аларын да каза итәр.

Кояш чыкканда һәм ике аршин буе күтәрелгәнчегә кадәр, кояшның төшлек вакытында, баткан чагында — шушы өч вакытта казаларны кайтарып уку дөрес түгел. Каза кайтару үлгәнчегә кадәр эшләнеп бетерелергә тиешле, юкса ул кеше газапка юлыгыр. Бүтән вакытларда, ягъни казаны кайтару дөрес булмаган чакларны санамаганда, казаны кайтару дөрес һәм тиешле.

Каза кайтарганда һәр намазны башлап укырга кирәк. Бишвакыт намазны берьюлы каза иткәндә дә ирләргә үзе ишетерлек итеп азан әйтү сөннәт санала, хатыннардан таләп ителми, алар азан әйтмәсләр һәм башлап укымаслар.

Казага калган намазын укыганда иң элек ният ителер, ягъни кайсы калдырылган намазны каза итүе билгеләнелер, әйтик, иртәнге намазларын каза иткән икән, иң әүвәлге яки соңгы калдырылган иртәнге намазымны каза итәм дип билгеләр. Шул рәвешле һәрбер намазларын белдереп, кайсына каза кайтаруын әйтер, шуннан соң гына намазына керешер. Ниятләнмичә укылган намаз дөрес булмас.

Әгәр дә уразалары калган икән, аларның да кайчан кайсысы калганлыгын белдерер һәм шуны ниятләп, Аллаһы тәгаләдән тәүбә үтенеп, казасын кайтарыр.

Әгәр дә зәкәте калган икән, хәтта берничә елныкы булса да, аларның барсын бергә җыеп, шул зәкәтен каза итеп кайтаруын ният итеп, ниятләнгән хәлендә шул зәкәтен фәкыйрьләргә өләшер.

Әгәр дә бер кешенең хаҗ кылырлык байлыгы булса, аңа хаҗ итү фарыз саналыр. Әмма ул кеше хаҗ кылмыйча, фарызны калдырса, акчасын бүтән эшләргә тотса да хаҗы казага калдырылыр һәм хаҗга берәр кешене булса да җибәрүе таләп ителер. Инде байлыгы беткән исә дә, теләнеп, хаҗга барыр өчен акча җыяр, теләнеп акча җыюы фарыз саналыр. Зәкәт, корбан шулай ук шушы рәвешле каза кылыныр, фәкыйрьлеккә төшүенә карамастан, бай вакытындагыча каза итүе таләп ителер.

Казага калган намазы булмаган кешене яки биш намазы гына казага калган икән, ул мөэминне сахиб тәртип, ягъни тәртип иясе дип атыйлар.

Бер кеше сахиб тәртип булып, ягъни намазын казага калдырган икән, әйтик иртәнге намазын укымаган исә, ул намазы хәтерендә була торып та, аны каза итмичә, фарыз намазының вакыты ирешеп, ягъни өйлә вакыты кереп, аны укыса, бу намазы бозык намаз булыр. Әмма имам Әгъзам белдерүенчә, бөтенләй үк бозылган саналмас. Әгәр дә ул кеше, калган намазы хәтерендә була торып та, аны каза итмичә, алты вакыт намаз укыса, барлык намазлары да дөрес саналыр. Әгәр дә алты намазын да укымас борын калган иртә намазын каза итсә, укыган фарызлары һәммәсе дә бозылыр.

Галимнәрнең: «Бер намаз биш намазны бозар, бер намаз биш намазны төзәтер!» — дигән сүзе нәкъ менә шуның хакында әйтелгән. Бу сүз сахиб тәртип хакында. Шулай итеп, әгәр бер кешенең, әйтик, иртәнге намазы калса, ул аны хәтерендә саклар, әмма каза кылырга ашыкмас. Әүвәле өйлә, икенде, ахшам, йәсигъ намазларын укыр, аннан соң икенче көнне шулай ук иртәнге намазын, өйләне үтәр, барлык намазлары дә дөрес саналыр.

Әгәр дә сахиб тәртип булган кешенең, әйтик, иртә намазы онытылып калган булса, аны каза кылмыйча, өйлә намазына керешсә, шунда берничә рәкәгатьтән соң хәтеренә төшсә, өйлә намазы бозылыр. Иртәнге намазын каза кылганнан соң гына өйлә намазын укыр. Казага калган намазы, намаз вакыты кергән вакытта исенә төшсә дә, ул шушы рәвешле итәр.

Сахиб тәртип булган кеше, казасы була торып та, аны онытып, вакыты кергән намазын укый башласа, хәтеренә казага калган намазы килмәсә, бу укыган намазы дөрес булыр, бозылмас. Әгәр дә намазлары күп калган икән, вакыт намазын кылу өчен вакыты чыгудан курыкса, җитешкән кадәрле намазларын каза итәр һәм вакытыннан чыкмас борын вакыт намазын укыр, намазы дөрес булыр.

Әгәр дә өйлә намазы казага калган икән, икенде намазын кылу вакыты кергән булуга карамастан, әүвәл өйләсен каза итеп укыр, аннан соң икендене үтәр.

Әгәр бер кеше йәсигъ һәм витр намазларын укымыйча йокласа, кич белән уянмыйча, таң аткач кына торса, үзе сахиб тәртип булса, вакыты бар икән, йәсигъ һәм витр намазларын каза итеп укыр, аннан соң иртәнге намазын үтәр. Әгәр дә вакыт сыйдырырлык булмаса, иртә намазын гына кайтарыр, калганнарын казага калдырып, алты намаздан соң гына каза итәр.

Әгәр дә бер кеше бер намазын онытса, аның кайсы намаз икәнлеген хәтереннән чыгарган булса, биш намазны укып, казасын кайтарыр. Әгәр дә ике көн эчендә ике намазын оныткан икән, ун

намазны тәртипләре белән укыр, казасын кайтарыр.

Әгәр дә бер кеше бер сәҗдә фарызны онытса, шулай ук биш намазын да каза итеп укып, ялгышын кайтарыр.

## МӘСҖИД ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ

Җәмәгать белән мәсҗидтә намаз уку саваплырак, һәм өстенрәк, һәм яхшырак санала.

Җәмәгать белән намаз укуның өстенлекләре болардан гыйбарәт:

1. Җәмәгать белән ике рәкәгать намаз уку ялгыз башыңа егерме җиде рәкәгать намаз кылудан саваплырак санала.

2. Мөэминнәр бер урынга җыелганлык сәбәпле, араларында дуслык һәм бер-берсенә яхшы мөнәсәбәт, хөрмәт хасил була.

3. Галимнәрдән күреп, наданнар да намаз укырга, яхшылыкка өйрәнерләр.

4. Намазлары кабул булмаган кешеләрнең дә намазлары, намазы кабул була торган мөэминнәргә иярүләре сәбәпле, Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән кабул кылыныр.

5. Риваятьләрдән билгеле булганча, җәмәгать белән намаз укучылар Ахирәт көнендә дә бергә йөрерләр һ. б.

Имам белән бергә җәмәгать төзеп кайда гына намаз укысаң да савабы зур, әмма мәсҗидкә баруның савабы артыграк санала.

Мәсҗидкә кергәндә, уң аяктан атлап керү әдәплерәк. Шул рәвешле мәсҗидкә үткәндә:

اَللّٰهُمَّ افْتَحْ لِى اَبْوَابَ رَحْمَتِكَ وَانْشُرْ عَلَىَّ خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ

*Аллаһүммә-фтәх ли әбвабә рәхмәтикә вәншүр галәййә хәзәинә рәхмәтик* — дигән доганы укырга кирәк. Ул татарча болай укылыр: «И Аллаһы

тәгалә, миңа рәхмәт ишекләреңне ачсаң иде һәм рәхмәт хәзинәләреңне чәчсәң иде!»

Мәсҗидтән чыкканда сул аяктан атлап чыгарга кирәк һәм бу доганы укырга киңәш ителә:

اَللّٰهُمَّ اِنِّى اَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِيمِ

*Аллаһүммә инни әс-әлүкә мин фадликәл газыйм*

Бу дога татарча болай әйтелер: «И Аллаһы тәгалә, чыннан да чиксез яхшылыкларыңны һәм рәхмәтләреңне үтенермен!»

Мәсҗидкә кергәч, ике рәкәгать намаз уку мактаулы. Мәсҗид эчендә әдәп һәм хөрмәт күрсәтү, утырып тору, *зикер:* «Лә иләһә иллал-лаһ», *тәсбих:* «Сөбханаллаһ», *тәхмид:* «Әлхәмдүлиллаһ», *тәкбир:* «Аллаһү әкбәр» әйтү, тәүбә догалары уку, Коръән яки китап укып утыру, вәгазь сөйләү яки тыңлау, гыйлем өйрәтү яки өйрәнеп утыру мактаулы.

Мәсҗид эченә суган, сарымсак һәм шуның ише авыз сасыта торган нәрсәләр ашаганнан соң керү яки анда ашап утыру ярамый. Шулай ук мәсҗид эчендә акча бүлешү, дөньяви эшләр белән шөгыльләнү, гайбәт сату, сурәтләр карау, уен уйнау, көлешү, кычкырышу, күп сөйләшү тыела торган эшләрдән санала. Хатын-кызлар мәсҗиде ачу шулай ук мәкруһ санала, хатын-кыз имамлык итү шулай ук бозыклык галәмәте дип исәпләнелә. Әгәр дә имам иргә хатын-кызлар да оеп намаз укыйлар икән, алар да җәмәгать савабын табарлар. Әмма җәмәгать намазы өчен хатыннарга мәсҗидкә бару ярамаган эшләрдән санала һәм киңәш ителми.

## ҖОМГА НАМАЗЫ МӘСЬӘЛӘСЕ

Шартлары булганда, җомга намазын уку фарыз санала.

Җомга намазының важиб булган *алты* шарты бар:

*Беренчесе:* Ир кеше булу. Хатыннарга шарт түгел.

*Икенчесе:* Шушы шәһәр яки авылда яшәү. Мөсафирларга шарт түгел.

*Өченчесе:* Күзләре күргән кеше булу. Әгәр дә ике күзе дә сукыр икән, аңа җомга намазы шарт түгел.

*Дүртенчесе:* Аяклары сау-сәламәт булу. Әгәр дә ике аягы да юк икән, ул кешеләргә җомга намазы шарт түгел.

*Бишенчесе:* Сау-сәламәт булу. Саулыгы киткән, сихәтлеге кимегән кешеләргә шарт түгел.

*Алтынчысы:* Азат кеше булу. Колларга, тоткындагы кешеләргә җомга намазын уку шарт түгел. Әгәр дә сукыр кешене җитәкләп йөртүче булса, колны хуҗасы җомгага барыр өчен рөхсәтле итсә, ул вакытта аларга да җомга намазы важиб күрелер.

Әгәр дә мөсафир, сукыр һәм шуның кебек җомга намазына бармаска сәбәпле кешеләр, мәсҗидкә барып, җомга намазын укысалар, һичбер гөнаһы юк, бәлки савабы гына артык саналыр, намазлары дөрес күрелер. Яңадан өйлә намазын уку кирәк булмас. Әгәр дә җомгага бармаска сәбәпләре бар икән, ул вакытта алар өйлә намазын укырлар, җомгага бармаганлыклары өчен гөнаһ булмас.

Җомга намазын укыр өчен *алты* шартның үтәлүе таләп ителә:

*Беренчесе:* Җомга укыла торган җирдә шәригать хөкемнәрен яхшы белгән түрә һәм казыйның булуы шарт. Ул кеше шәригать хөкемнәре буенча ялгышсыз эш йөртә алырга тиеш. Әмма җомга намазын уку өчен мәсҗиднең булуы шарт түгел.

*Икенчесе:* Җомга намазында имамлык итүче кеше бу гамәлгә мөэминнәрдән рөхсәтле булырга тиеш. Әгәр дә шәригать хөкемнәре белән идарә ителә торган ил түгел икән, мөэминнәр ул илне инкарь кылырга тиешләр яки үзләре атап бер кешене илләренә башлык-хуҗа итеп танырга хаклары бардыр. Шул вакытта гына андый илдә җомга намазының шартларыннан берсе үтәлер, ялгыштан сакланыр.

*Өченчесе:* Җомга намазы өйлә вакытында укылыр. Өйләгә кадәр яки өйлә вакыты чыккач җомга намазын уку тыела. Бар намазлардан аермалы буларак, җомга намазы каза кылынмый һәм кайтарылмый.

*Дүртенчесе:* Хөтбә. Җомга намазында хөтбә уку фарыз санала. Хөтбәне имам укыр. Хөтбә җәмәгать өчен аңлашылырлык телдә булырга тиеш, имамның тавышы һәркемгә ишетелеп, күңеленә үтәрлек дәрәҗәдә камил сөйләнелсен. Әгәр дә хөтбәнең телен җәмәгать аңламый икән, дөрес булмас. Хөтбәнең важибе — имам аяк өсте басып, җәмәгатькә каршы карап сөйләр. Нәҗасәттән, яман сүздән сафланган, гаурәтләре пакьләнгән, чиста кием һәм тән белән, усаллыктан арынган хәлендә уку таләп ителер. Юкса савабы булмас.

*Бишенчесе:* Җомга укыр өчен имамга иң кимендә өч кеше оеган булырга тиеш, ике кешегә яки бер мөэмингә җомга намазы дөрес түгел. Әгәр дә ул имамнан тыш өч кешенең өчесе дә, яки сукыр, яки мөсафир, яки кол икән, җомга намазы дөрес. Ә инде ул өч кешенең берсе хатын-кыз яки бала икән, җомга намазы дөрес түгел, аның урынына өйлә укылыр.

*Алтынчысы:* Җомга укыла торган җиргә һәр кешегә керергә рөхсәт булу шарт. Әгәр дә җомгага килер өчен халыкка рөхсәт бирелеп тә, алар ниндидер бер сәбәп белән килмиләр икән, ул вакытта үзләренә аерым, бер җәмәгать төзеп, җомга намазын уку дөрес.

Җомга намазы тиешле булып та аны укый алмаган кешеләр аның урынына өйлә укырлар. Әмма аларга җәмәгать төзеп, имамнан башка җомга намазы уку яисә җәмәгать төзеп, өйлә уку мәкруһ санала. Әгәр дә җомга намазы тиешле булып та, аңа бармаган кешеләр бар икән, аларга мәсҗидтә җомга укылганга кадәр өйлә намазын үтәү мәкруһ. Әмма җомга намазына барырга тиеш булып та, һичбер сәбәпсез аны калдырса, ул кешегә гөнаһ ирешер, бик күп саваплардан коры калыр.

Җомга намазына бармаска сәбәпле булып та кемнәр җомга намазын укысалар, савап табарлар,

намазлары дөрес булыр. Шулай ук мөсафир, кол һәм бүтән сәбәп белән җомгага бармаучылар икән, өйлә намазын укысалар, гөнаһлы ителмәсләр. Әмма аларга да җомга укылудан алда өйлә намазын кылу мәкруһ саналыр. Шулай ук аларга җәмәгать белән җомга намазы вакытында өйлә намазын уку мәкруһ икәнлеген онытмаска кирәк. Шулай да җомга укылмый торган авылларда, җәмәгать төзеп, җәмәгать белән өйлә намазын уку дөрес, мәкруһ түгел.

Әгәр дә бер кеше әүвәле өйлә намазын өендә укып, аннан соң мәсҗидкә барып, җомга намазын укыса, укыган өйлә намазы нәфел намазы хисабыннан саналыр, җомга намазы фарыз намаз булыр. Мәгәр җомгага соңарса, укыган өйләсе нәфел түгел, фарыздыр.

*Җомга намазын уку рәвеше:*

Азан шәриф әйтелгәннән соң иң элек ният итү тиешле. Ул болай әйтелә: «Бүгенге җомга намазының сөннәтен укырга ниятләндем!» — дип дүрт рәкәгать кылыр, бу намаз сөннәт мөвәкдә исәпләнер. Әгәр дә бер кеше җомганың сөннәтләрен укырга керешсә, шул вакытта имам хөтбә әйтә башласа, ике рәкәгатен тәмамлап, сәлам әйтеп, ул кеше хөтбәне тыңлар. Аның өчен хөтбәне тыңлау фарыз. Мәгълүм булганча, фарыз сөннәттән өстендер! Ә шушы фарызны үтәгәч, дүрт рәкәгать итеп каза итәр. Әгәр дә имам хөтбәгә керешкәндә ул кеше өченче рәкәгатькә күтәрелгән булса, дүрт рәкәгать итеп тәмамлар. Хөтбә укучы мөнбәргә күтәрелгәндә сөннәткә керешү мәкруһ гамәлләрдән санала.

Имам хөтбә укыганнан соң, җәмәгать, ул михрабка керүгә: «Ният иттем Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен җомга намазының фарызын кылуга, оедым имамга!» — дип, «Аллаһү әкбәр» — дигәч, колак кагып, «Сөбханәкә...» укыр, имамның кыйраәт укыганын тыңлап торыр, шушы рәвешле ике рәкәгать фарызны башкарыр.

Әгәр дә бер кеше соңга калып, имамга әттәхияттә яки сәҗдәдә җитешсә, имамга оер. Имам, сәлам биргәннән соң торып, ике рәкәгать кылыр. Намазы кабул булыр. Әмма имам Мөхәммәт бел-

дергәнчә, әгәр дә бер кеше имамга икенче рәкәгатенең рөкүгында җитешсә, кушылып китсә, имам артыннан рөкүгъ кылса, җомгага җитешкән саналыр, әгәр дә моннан да соңга калган исә, җомга намазына өлгерүче исәпләнмәс. Имам сәлам биргәч, торып, дүрт рәкәгать итеп өйләнең фарызын үтәр.

Җомганың фарызыннан соң тагын да дүрт рәкәгать итеп сөннәт намазлары укылыр.

Бу дүрт рәкәгать сөннәттән соң: «Ният иттем вакытында җитешеп кылмавым сәбәпле ахыр өйлә намазына!»—дип дүрт рәкәгать укылыр. Әгәр дә өйлә намазы казага калмаган булса, дүрт рәкәгатендә дә сүрә кушар. Әгәр җомга намазы җомгадан китсә, бу дүрте нәфел исәпләнелер. Ә нәфелнең һәр рәкәгатендә сүрә кушу важиб икәнлеге аңлашыладыр. Әгәр җомгадан китмәгән икән, ул дүрт рәкәгать шул көннең өйлә фарызыннан булыр. Дүрт рәкәгатендә дә сүрә кушуның зарары юк.

Өйлә намазы казага калган кеше булса, алдагы ике рәкәгатендә сүрә кушып, соңгы икесендә «Фатиха» сүрәсен генә укыр. Чөнки җомга җомгадан китмәсә, шул ахыргы өйлә нияте белән кылган ул дүрт рәкәгате шул көннең өйлә фарызыннан булып, өйләне укуы булыр. Әгәр дә җомга җомгадан китсә, ул дүрт рәкәгать аның казага калган өйләсеннән исәпләнелер. Аларның икешәр рәкәгатьләрендә сүрә кушу важиб, соңгы икесендә исә бары тик «Фатиха» укылыр. Өйләсе казага калган кеше дә шушы рәвешле гамәл итәр.

Соңыннан, дүрт рәкәгать кылгач, өйлә нияте белән кылуга: «Ният иттем шушы вакытның сөннәтен үтәргә!»—дип ике рәкәгать тагын намаз укыр. Барсы бергә уналты рәкәгать намаз укыган булыр. Әгәр дә җомга дөрес укылган икән, сөннәтләре белән бергә үтәлер. Җомгасы дөрес булмаса, өйләсе кабул кылыныр.

Кайбер кешеләр җомганың сөннәтләрен ташлап китәләр. Әмма җомганың фарызыннан соң укыла торган намазларны укымыйча китүләре асылда дөрес түгел. Чөнки җомгалары дөрес булырлык ка-

дәр намаз укымаулары сәбәпле шул көннең өйләсен калдырган кешеләрдән хисап ителерләр.

Әгәр дә кылган җомгасы дөрес булса, казага калган өйләсе бар икән, өйләсен каза итәр иде. Әгәр дә өйләсе калмаган икән, нәфел намазын укыган исәпләнеп, зур савапларга ирешер иде. Аларны укымыйча чыккан кеше болардан мәхрүм калыр. Җомганың шартлары үтәлгәндә генә җомга намазы дөрес булыр.

*Җомга намазына килү өчен һәрбер мөселманга болар таләп ителә:*

1. Җомга намазы өчен алдан госел коену, мунча керү.
2. Хушбуйлар, ислемайлар сөртенү.
3. Яңа яки чиста, үтүкләнгән киемнәр кию.
4. Тырнакларны кисү.
5. Мәсҗидкә, азан ишетелгәнче, иртәрәк бару.
6. Азанны ишетүгә, һәр эшне ташлап, намазга ашыгу.

Кемнәр җомга намазына бармыйча калырлар, гөнаһлы булырлар.

*Җомга намазының мәкруһлары:*

1. Мөнбәргә имам хөтбә укырга чыккач, сөннәт намазларын кылу гамәленә керешү.
2. Хөтбә әйтелгән вакытта Коръән уку.
3. Хөтбә вакытында дөнья сүзләре сөйләшү.
4. Алда урын күреп, шунда барам дип кешеләр аша атлап, аларны рәнҗетү.
5. Һичбер сәбәпсез төчкерү, тәсбих әйтү.
6. Кычкырып салават әйтү, дога уку.
7. Сәхабәләрнең исемнәрен ишетүгә: «Аларга Аллаһы тәгаләнең ризалыгы булсын» (*Разаллаһу ганһ*)—дию.

Болардан тыш билгеле булсын: Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен дип хөтбә укылганда бар күңелне багышлап, тыныч кына тыңлап тору фарыз гамәл санала. Бу тынычлыкны бозу, бүтәннәргә комачаулау, хөтбәгә катнашып китү һәм шуның кебек бүтән төр гамәлләр бары тик бозыклыкларның галәмәтләре генә. Җомга намазының иң әһәмиятле урыннарыннан берсе—хөтбәдер, аннан баш чөерү килешмәс. Әгәр дә имам хөтбәне оста

итеп әйтми икән, мөэминнәрнең күңелен кайтарса, бу аның өчен бер дә килешә торган эш түгел, ояты үзенәдер!

## ҖЕНАЗА НАМАЗЫ

Җеназа намазын уку өчен үлекнең юылган булуы һәм кәфенләнүе шарт. Үлекне юу фарыз кифая санала.

*Үлекне юу:*

1. Үлекнең гаурәт җирләре сафландырыла. Үлекне юучы кулына бер чүпрәк бияләй кия яисә чүпрәк урый һәм үлекнең гаурәт әгъзасын юа. Тәмам тазарганчы юу шарт. Моннан соң:

2. Намаз тәһарәте кебек тәһарәт алдыра, ләкин авызына һәм борынына су салмый, бармагына бер чүпрәк урап, шул бармагы белән тешләрен-ирennәрен мәсех кыла-сөртә, борын тишекләренә дә шул рәвешле мәсех чыга. Шуннан соң:

3. Үлекне сул кабыргасына яткырып, уң ягыннан, башыннан аягына кадәр өч мәртәбә юа, аннан соң:

4. Үлекне уң кабыргасына яткырып, сул ягыннан башыннан алып аягына кадәр өч мәртәбә юа, моннан соң:

5. Үлекне азрак утырткан шикелле итеп, корсагыннан сыйпый. Әгәр нәҗес чыкса, шул нәҗес чыккан җирен юа, госелне кайтармый, шуннан соң гына:

6. Чиста һәм пакь булган бер йомшак чүпрәк белән үлекнең тәнен сөртә-корыта да кәфенгә сала.

*Кәфенләү:* Кәфен — фарыз кифая.

Кәфен өч төрле була: сөннәт кәфен, кифая кәфен, зарур кадәрле кәфен.

Ирләргә сөннәт кәфене өч кат була: ахирәт күлмәге, азар, лифафә. Хатыннарга исә сөннәт кәфене биш кат була: ахирәт күлмәге, азар, бөркәнчек, лифафә, хирка.

Ахирәт күлмәге муеннан аякка чаклы була.

Азар — баш очыннан аяк очына кадәр була.

Лифафә — ул да шулай ук азар кебек баш очыннан аяк очына кадәр була, әмма аны бераз озынрак итү яхшырак, соңыннан бәйләр өчен дип.

Хатын-кызларга бөркәнчек — иңгә чәчен капларлык, буе исә ике аршин кадәр озынлыкта була.

Хирка — күкрәкләреннән алып кендегенә кадәр киңлектә була.

Кәфен кифая ирләргә ике кат азар һәм лифафә, хатыннарга — өч кат азар, лифафә, бөркәнчек.

Зарур кадәрле кәфен — ни табылса, шуның белән кәфенләү.

Үлекне кәфенләгән вакытта, ирләр өчен әүвәле лифафәне җәяләр, аның өстенә — азарны, аның өстенә ахирәт күлмәгенең бер читен салалар. Алар өстенә үлекне куеп, ахирәт күлмәген кидерәләр. Аннан соң азарның сул ягын ябалар, аннан уң ягын каплыйлар. Шуннан соң лифафәнең сул ягын ябып, аннан уң ягын ябалар. Кәфеннең таралып китүеннән курыксалар, аяк очыннан да, баш очыннан да бәйлиләр.

Хатыннар болай кәфенләнелә: әүвәле хирканы җәяләр, аның өстенә лифафәне, аның өстенә азарны, аның өстенә бөркәнчекне, аның өстенә ахирәт күлмәген салалар. Шунда мәетне куеп, аңа ахирәт күлмәген кидерәләр. Аннан чәчләрен ике толым итеп күкрәкләренә салалар, шуннан бөркәнчекне ябалар. Шуннан соң азарны һәм лифафәне каплап, хирка белән бәйлиләр. Кәфеннең сүтелүеннән курыксалар, баш очыннан һәм аяк очыннан бәйлиләр.

Мәет шушы рәвешле итеп җеназа намазына әзерләнелә. Җеназа намазын уку фарыз кифая гамәлләрдән исәпләнелә. Җеназа намазын уку өчен намазның тышында булган шартларның үтәлүе фарыз. Боларга өстәп тагын да өч шарт бар:

1. Җеназаның мөселман булуы.
2. Үлекнең юылган булуы.
3. Җәмәгатьнең алдында булуы.

Имам кеше, җеназа ир яки хатын булуына карамастан, үлекнең күкрәге каршысында торыр.

Җеназа намазына бу рәвешле ният итәрләр: «Ният иттем Аллаһы тәгаләә өчен намазга, бу мәет

өчен догага, оедым шушы имамга!»—дип, «Аллаһү әкбәр»—дип колак кагып, кул багларлар. Имам һәм җәмагать:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ وَ تَبَارَكَ اسْمُكَ وَ تَعَالٰى جَدُّكَ وَلَا اِلٰهَ غَيْرُكَ ۞

*Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкә исмүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә иләһә гайрүк*—дип тәкбир укырлар, бу—шарт. Аннан соң, кулларын күтәрмичә генә: «Аллаһү әкбәр» диярләр.

Шушы икенче тәкбирдән соң имам һәм җәмагать бу салаватны укырлар:

صَلَوَات ۞

اللّٰهُمَّ صَلِّ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلٰى اِبْرَاهِيمَ وَ عَلٰى آلِ اِبْرَاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞ اللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى آلِ مُحَمَّدٍ ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلٰى اِبْرَاهِيمَ وَ عَلٰى آلِ اِبْرَاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ ۞

*Аллаһүммә салли галә Мөхәмәддин вә галә әли Мөхәммәд. Кәма салләйтә галә Ибраһимә вә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид. Аллаһүммә барик галә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд. Кәма бәрактә галә Ибраһимә вә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид*

Бу дога-салаватны укыганнан соң, шулай ук кулларны күтәрмичә генә: «Аллаһү әкбәр»—дип өченче тәкбирне әйтәләр. Аннары бу дога укыла:

اللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَ مَيِّتِنَا وَ شَاهِدِنَا وَ غَائِبِنَا وَ صَغِيرِنَا وَ كَبِيرِنَا وَ ذَكَرِنَا وَ اُنْثَانَا ۞ اللّٰهُمَّ مَنْ اَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَاَحْيِهِ عَلَى الْاِسْلَامِ وَ مَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الْاِيمَانِ ۞

اللّٰهُمَّ اِنْ كَانَ هٰذَا الْمَيِّتُ مُحْسِنًا فَزِدْ فِى اِحْسَانِهِ وَاِنْ كَانَ مُسِيئًا فَتَجَاوَزْ عَنْهُ ❀

*Аллаһүммә-әгъфир лихәййинә вә мәййитинә вә шаһидинә вә гаибинә вә сәгыйринә вә кәбийринә вә зәкәринә вә үнсана. Аллаһүммә мән әхйайтәһү миннә фә-ахйиһи галәл-ислами вә мән тәвәффәйтәһү миннә фәтәвәффәһү галәл-иман. Аллаһүммә ин кәнә һәзал-мәййитү мөхсинән фәзид фи ихсаниһи вә ин кәнә мүсий-ән фәтәҗавәз ганһ* Шуннан соң дүртенче мәртәбә: «Аллаһү әкбәр» — дип тәкбир алына.

Әгәр дә гарәпчәсен белмәсәләр, бу дога һәм салаватлар, һич булмаса, татар телендә әйтелерләр. Ул болай булыр:

Ният итеп, имамга оегач, «Аллаһү әкбәр» — дип колак кагып, кул баглагач: «И Аллаһы тәгалә, Сине саф-пакь дип беләмен һәм Сиңа мактауларымны әйтәмен, Синең исемең бәрәкәтле булды, Синең өстенлегең билгеле булды, Синнән башка илаһи зат юктыр!» — дип тәкбир әйтерләр һәм, кулларын күтәрмичә генә: «Аллаһү әкбәр» — дигәч, бу салаватны укырлар: «И Аллаһы тәгалә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның кавеменә рәхмәт кылгыл, ничек Син Ибраһим пәйгамбәргә һәм аның кавеменә рәхмәт кылган идең. Чыннан да Син мактаулы һәм олугсың! И Аллаһы тәгалә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның кавеменә бәрәкәтлек бирсәң иде, ничек Син Ибраһим пәйгамбәргә вә аның кавеменә биргән идең! Чыннан да Син мактаулы һәм олугсың!»

Моннан соң «Аллаһү әкбәр» — дип өченче тәкбирне әйтерләр дә бу доганы укырлар: «И Аллаһы тәгалә, безнең терекләребезне, үлекләребезне, хазирләребезне, гаибләребезне, кечеләребезне, олыларыбызны, ирләребезне, хатыннарыбызны ярлыка! И Аллаһы тәгалә, терек булганнарыбызны Ислам дине белән терек кыл, үлгәннәребезне иман белән вафат кыл! И Аллаһы тәгалә, әгәр бу мәет изге

кеше булган икән, изгелеген арттыр, әгәр дә гөнаһлы кеше булган икән, гөнаһларын гафу кыл!»

Бу догадан соң дүртенче тапкыр «Аллаһү әкбәр» — дип тәкбир әйтерләр.

Шушы дүртенче тәкбир белән дога беткәнлектән, «Аллаһү әкбәр» — дигәннән соң, ике якларына сәлам биреп, җеназа намазыннан чыгарлар. Җеназаның беренче тәкбире шарт булып тора, калган өч тәкбирләре — рөкеннәр исәпләнелә, шунлыктан «Аллаһү әкбәр» — дигәндә әүвәлге тәкбирдә генә куллары күтәрелеп, колак кагыла, калганнарында куллар багланган килеш кала.

Әгәр дә җеназа сабый бала булса, ягъни үлгән балага җеназа намазы укылса, әүвәлге ике тәкбир олыларга укылган төсле башкарыла, өченче тәкбирнең догасында ахыргы сүзләр үзгәртелә. Шулай итеп, өченче тәкбирнең догасы болай укыла:

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَ مَيِّتِنَا وَ شَاهِدِنَا وَ غَائِبِنَا وَ
صَغِيرِنَا وَ كَبِيرِنَا وَ ذَكَرِنَا وَ اُنْثَانَا ❀ اَللّٰهُمَّ مَنْ اَحْيَيْتَهُ مِنَّا
فَاَحْيِهِ عَلَى الْاِسْلَامِ وَ مَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الْاِيمَانِ ❀
اَللّٰهُمَّ اجْعَلْ هٰذَا الْمَيِّتَ لَنَا فَرَطًا ❀ اَللّٰهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا اَجْرًا
وَ ذُخْرًا ❀ اَللّٰهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا شَافِعًا وَ مُشَفَّعًا ❀

*Аллаһүммә-әгъфир лихәййинә вә мәййитинә вә шаһидинә вә гаибинә вә сәгыйринә вә кәбийринә вә зәкәринә вә үнсана. Аллаһүммә мән әхйайтәһү миннә фә-ахйиһи галәл-ислами вә мән тәвәффәйтәһү миннә фәтәвәффәһү галәл-иман. Аллаһүммә-әҗгаль һәзал-мәййитә ләна фәратан, аллаһүммә-әҗгальһү ләна әҗран вә зухран, аллаһүммә-әҗгальһү ләна шафиган вә мүшәффәга*

Татарчасы: «И Аллаһы тәгалә, безнең терекләребезне, үлекләребезне, хазирләребезне, гаибләребезне, кечеләребезне, олыларыбызны, ирләребезне, хатыннарыбызны ярлыка! И Аллаһы тәгалә, терек булганнарыбызны Ислам дине белән терек

кыл, үлгәннәребезне иман белән вафат кыл! И Аллаһы тәгалә, бу мәетне безнең өчен алдан барган изгелек кебек кыл! И Аллаһы тәгалә, бу мәетне безнең өчен әҗер һәм киләчәк өчен хәзерләнгән азык кебек кыл! И Аллаһы тәгалә, аны безнең өчен шәфкать теләүче һәм шәфкатьне кабул итүче буларак кыл!»

Мәҗнүн һәм диваналарга да җеназада сабыйлар өчен укыла торган дога башкарыла. Әгәр диваналыгы балигъльлыкка ирешүдән элгәре беленсә шушы сабыйларга укыла торган җеназа догасы дөрес булыр. Әгәр дә мәҗнүн-диваналыкка балигъльлыкка чыккач күченгән булса, балигъларга укыла торган доганы укырлар.

Җеназа догасына соңарып җитешкән кеше, җеназа догасына кайсы урынында кушылуына, керүенә карамастан, имамның тәкбирен көтеп тормастан тәкбир әйтеп, имамга оер. Имамның сәламеннән соң үзенең калган догаларын-тәкбирләрен каза итеп укып бетерер. Әгәр бер кеше, имам дүртенче тәкбирне әйтеп, сәлам биргәндә җеназага җитешсә, тиз ара әүвәлге тәкбирне алып, имамга оер. Имам сәлам бирүгә, ул кеше өч тәкбирне әйтеп, дүрт тәкбире дә тәмам булыр, сәлам биреп, ул тәкбирләрнең догаларын укымас. Чөнки үлекнең догасы тәмам булып, халык аны җилкәләренә күтәрер. Җеназаны җилкәләргә күтәрүгә җеназа догасы тыелыр, ул вакытта җеназа уку җеназа намазын бозар. Әгәр дә укып җитешерлек икән, ул вакытта тәкбирләрнең догаларын башкару тиешле булыр.

Мәет юылганга кадәр аның янында Коръән уку киңәш ителми, мәкруһ санала. Үлгән кешенең хәсрәтеннән йөзләрне җимереп, якаларны ертып елау, такмаклап һәм кычкырып елау зур гөнаһлардан исәпләнелә һәм хәрәм булып тора. Әгәр дә берәр кеше шулай итсә, аны тыярга кирәк. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Үлек өчен йөзләрне тырнап, якаларны ертып, кычкырып елаган кеше безнең милләтебездән түгел!» — дип белдергән. Шулай да кычкырмыйча елаудан зарар юк.

# ГАЙД, ЯГЪНИ БӘЙРӘМ НАМАЗЫ

Җомга намазы тиешле булган кешеләргә шулай ук Гайд намазлары да важиб санала. Җомга намазына шартлар шулай ук гайдкә дә шарт булып тора. Кемгә җомга намазы важиб түгел, аларга гайд намазы да тиешле күрелми. Гайд намазларында, намаз укыганнан соң, хөтбә сөйләү сөннәт. Исебезгә төшерсәк, җомга намазларында хөтбә сөйләү һәм тыңлау — фарыз.

Бәйрәм намазлары кояш чыгып, ике аршын биеклеге күтәрелгән вакыттан алып, төшлеккә ирешкәнчегә кадәр укылыр. Төштән соң Бәйрәм намазын уку ярамас. Имам кеше гайд намазын кайчан башкарырга исәпләвен җәмәгатенә алдан белдереп куяр.

Бәйрәм намазлары азансыз һәм камәтсез, ике рәкәгать кылыныр. Рамазан һәм Корбан гайденең намазлары икесе дә бер, аермалары юк. Ләкин Корбан бәйрәменең Гарәфә көнне иртә намазында сәлам биргәннән соң тәкбир әйтү важиб булыр. Бу намаздан башлап, бәйрәмнең дүртенче көнендә икенде намазында тәмамланыр. Шушы егерме өч вакыт намазларының фарызлары соңында важиб булыр. Моңа «тәкбир тәшрыйк» диләр.

Бу тәкбир, сәлам биргәннән соң:

اَللّٰهُ اَكْبَرُ ❀ اَللّٰهُ اَكْبَرُ ❀ لَآاِلٰهَ اِلاَّ اللّٰهُ وَاللّٰهُ اَكْبَرُ ❀
اَللّٰهُ اَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❀

*Аллаһү әкбәр. Аллаһү әкбәр. Лә иләһә иллаллаһү вә Аллаһү әкбәр. Аллаһү әкбәр вә лиллаһилхәмде* — дип әйтелер. Бу тәкбирне җәмәгать белән бергә намаз укыганнан соң да, ялгыз укыгач та, мөсафирмы, авырумы, ирме, хатынмы — барысына да важиб. Калдырса яки куйса, гөнаһлы булыр, әгәр дә онытса, гафу ителер.

Рамазан гайден беренче көнендә бер-бер сәбәп белән укымыйча калдырсалар, икенче көнне укысалар, дөрес булыр.

Әгәр дә икенче көнендә дә берәр сәбәп белән укымыйча калдырсалар, өченче көнне гайд уку дөрес булмас. Укымыйча, шул килеш калдырырлар.

Корбан гайден исә, әгәр дә бер-бер сәбәп белән беренче көнендә укымыйча калдырсалар, икенче һәм өченче көннәренең берсендә башкарсалар, гайд намазы дөрес булыр. Әгәр дә һичбер сәбәпсез беренче көнендә укымыйча, икенче яки өченче көненә калдырсалар, мәкруһ булыр, әмма намаз үзе — дөрес, бозылмас. Әмма Рамазан гайден сәбәпсез икенче көнгә калдыру дөрес түгел. Корбан бәйрәменең намазын вакыты керүгә уку саваплы, Рамазан гайденең намазын беразга кичектереп уку шулай ук саваплырак.

Бәйрәм намазлары соңыннан каза итеп кайтарылмаслар, шунлыктан аларда катнашу тиешледер.

Рамазан бәйрәмендә намаздан алда ашау-сыйлану, Корбан бәйрәмендә гайд соңында ашау-сыйлану саваплы. Гайд намазларына госел коенып, хушбуйлар сибенеп, яңа яки чиста-саф, үтүкләнгән киемнәр киеп бару мактаулы. Рамазан гайденә баргында җәяү йөрү, юлда яшерен тәкбир әйтү саваплы. Корбан гайденә килгәндә, шулай ук җәяү барып, кычкырып тәкбир әйтү мактаулы.

*Гайд намазлары бу рәвешле укыла:*

Әүвәле ниятләнелә: «Ният иттем ике рәкәгать Рамазан гайде намазына, оедым шушы имамга» яки: «Ният иттем ике рәкәгать Корбан гайде намазына, оедым шул имамга», — диелә, аннан: «Аллаһү әкбәр» — дип колак кагып, кулларын баглыйлар. Шуннан имам һәм җәмәгать:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ وَ تَبَارَكَ اسْمُكَ وَ
تَعَالٰى جَدُّكَ وَلَا اِلٰهَ غَيْرُكَ ✿

*Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкә исмүкә вә тәгалә җәддүкә вә лә иләһә гайрүк* — дип укырлар, аннан баглаган кулларын җи-

бәреп, түбән төшереп, өч мәртәбә: «Аллаһү әкбәр» — дип колак кагарлар, һәр тәкбирне әйткәндә дә кулларын ике якка төшереп, өченче тәкбирдә кулларын кабат бағларлар. Имам булган кеше «Фатиха» һәм берәр сүрә укыр, шуннан соң рөкүгъ һәм сәждә итәрләр. Аннан тагын аякка басарлар, бу юлысы да имам «Фатиха» һәм берәр сүрә укыр. Әмма рөкүгъ хәленә китмәсләр. Бәлки аякта торган килеш өч тапкыр «Аллаһү әкбәр» тәкбирен колак кагып әйтерләр, кулларын ян-якларына төшерерләр. Моннан соң дүртенче кат: «Аллаһү әкбәр» — дип тәкбир әйтүгә рөкүгъ хәленә китеп, сәждә итәрләр. Әттәхиятне укып, салават әйтеп, сәлам бирерләр. Бәйрәм намазы шушы рәвешле тәмамланыр.

Бер кеше бәйрәм намазына имам рөкүгъ хәлендә вакытта җитешеп килсә, әгәр дә имамга рөкүгъ кылуында өлгерермен дип күңеле ышанса, ифтитах тәкбирен һәм бәйрәм тәкбирләрен әйтеп, рөкүгъ хәленә китәр. Әгәр дә имамга рөкүгъ вакытында җитешүенә күңеле ышанып җитмәсә, ифтитах тәкбирен генә әйтеп, рөкүгъ хәленә китәр. Әмма рөкүгъ тәкбирләре урынына өч мәртәбә: «Аллаһү әкбәр» — дияр, ә кулларын колак кагарга күтәрмәс. Әгәр дә тәкбирләрен әйтеп бетергәннән алда имам аякка торса, имамга ияреп кыямга басар, калган тәкбирләре өстеннән төшәр.

Әгәр дә бер кеше беренче рәкәгатькә гайдтә җитешмәсә, икенчесен генә укырга өлгерсә, имамның сәламеннән соң аягына калкып, «Фатиха» һәм берәр сүрә укыр, аннан «Аллаһү әкбәр» — дип өч мәртәбә тәкбир әйтеп, һәрберсендә колак кагып, аннан рөкүгъ һәм сәждә кылып, әттәхияткә утырып, сәлам бирер.

Әгәр дә имам бәйрәм намазларында тәкбирләрне онытып, «Фатиха»ның бер өлешен яки тулысын укыса, соңыннан исенә төшсә, тәкбирләрне алыр, аннан «Фатиха»ны яңадан укыр. Мәгәрем ки тәкбирләрне онытып, «Фатиха»дан соң берәр сүрә дә укыган булса, тәкбирләрне генә әйтер, «Фатиха» һәм укыган сүрәсен кабатламас, кайтармас. Әгәр тәкбирләрнең берсен онытса, рөкүгъ вакытында

исенә төшсә, аны рөкүгъ хәлендә каза итәр. Рөкүгъ вакытында каза иткән тәкбирләрен әйткәндә кулларын күтәрмәс.

## КОРБАН МӘСЬӘЛӘСЕ

Билгеле булганча, Корбан бәйрәмнәрендә корбан чалу тиешле эш, важиб санала. Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Бер кеше, көче житә торып та, корбан чалмаса, безнең мәсжидләребезгә якын килмәсен!» — дигән.

Корбан өчен чалыначак малның яше һәм нәселе билгеле булып, аны Корбан бәйрәме көннәрендә Аллаһы тәгаләнең ризалыгын теләп чалу тиешле.

Корбан чалу шул кешеләргә тиешле, алар мөселман кеше, бай, азат, ягъни коллыкта тормаган, үз авылында яки йортында яшәүче булырга тиешләр. Корбан зөлхиҗҗә аеның унынчы, унберенче һәм уникенче көннәрендә чалына. Әгәр бер кеше корбан чалуны инкарь итсә, кяфергә чыгар; чалмый калдырса, газапка тиешле булыр; үтәсә, бөек савапка ирешер.

Акчасы, яки алтыны, яки көмеше бар икән, ул кеше корбан чалырга тиеш. Әгәр дә Корбан бәйрәме көннәрендә байлык иясе булып китсә, шулай ук корбан чалу тиешле. Шулай ук, әгәр дә бер кешенең ике бертөрле киеме булса, яки үзе яшәгән йортыннан тыш тагын бер өе бар икән, яки ике бертөрле китабы һәм башка шуның кебек бер-бер әйберсемалы икәү икән, ул кеше корбан чалырга бурычлы. Хатыннарының һәм йорт эчендәге хаҗәттән арткан һәммә әйберләр корбан чалу бурычын иясенә йөкләр. Байлыгы бар кешеләр мохтаҗларга фитра һәм нәзер садакалары өләшергә бурычлылар. Әмма байларның үзләренә садака алу хәрәм.

Корбан чалу өчен *дүрт* төрле мал дөрес: дөя, сыер, кәҗә, сарык (куй).

Корбан сарыгы (куй) бер яшеннән узып, икенчегә чыккан булырга тиешле.

Корбанлык кәҗә дә бер яшеннән узып, икенчесенә чыккан булу сорала.

Корбанга китерелгән сыер исә ике яше үтеп, өченчегә чыккан булырга тиеш.

Корбан дөясе биштән узып, алтыга киткән булырга тиеш.

Сарык белән кәҗә бер кеше өчен дөрес, берничә кешегә корбан була алмый. Дөя һәм сыер исә җиде кешегә кадәр дөрес, җидедән артыкка дөрес түгел. Әмма дөя яки сыерны бер кеше яки ике кеше атап чалсалар, аларга дөрес була.

*Корбанга китерелгән малларның түбәндә саналачак унбер төрле җитешсезлегенең берсе генә бар икән, корбаны дөрес булмый:*

1. Ике иреннәре киселгәндә.
2. Ике күзе дә сукыр исә.
3. Бер күзле булса.
4. Колакларының өч өлешеннән бер өлешенең артыграгы киселгән булса.
5. Койрыгының өч өлешеннән бер өлешенең артыгы өзелгән булса.
6. Авыру хайван булса.
7. Корчаңгысы булса.
8. Юләрләнгән мал булса.
9. Аксак булса.
10. Бик арык булса.
11. Мөгезе сынып, җилегенә кадәр төшкән булса.

Әгәр дә бер кеше корбанга бар шарты да туры килгән хайван алса, әмма чалганчыга кадәрле берәр гаебе ачылса яки ул мал бәлаләнсә, әйтик аягы сынса һәм башка төрле зәгыйфьләнсә, ул вакытта корбанга бүтәнне сатып алырга тиешле. Әгәр бүтәнне алу мөмкинлеге юк икән яки көче җитмәсә, шул элек сатып алган, әмма бәлаләнгән хайванны чалса да корбаны дөрес була.

Гайд укыла торган урыннарда, авылларда, шәһәрләрдә корбан хайванын намаздан чыккач ук бугазласалар, яхшы була. Әгәр дә гайд укылмый торган авыл яки шәһәрдә икән, ул вакытта гайд көненең таңы аткач та бугазларга мөмкин. Әмма кояш чыккач корбан чалу дөресрәк.

Корбан чалуның ахыры — гайднең өченче, соңгы көне, кояш батканчыга кадәр мөмкин.

Бай кешегә корбан үзе өчен генә важиб, сабый балалары өчен корбан чалуы кирәкми. Әгәр дә ул балалары мал ияләре икән, бу вакытта алар да корбан чалдырырга мөмкиннәр һәм алар өчен дә корбан дөрес санала. Шулай да корбан бары тик балигъ кешеләр өчен генә дөрес икәнлеген онытырга ярамый.

Әгәр дә берәр кеше азарынган булса, әмма аңа корбан чалу важиб гамәл түгел исә, әмма азарынганлыгы сәбәпле корбан малы алып, аны чалдыруы дөрес. Ә итен үзе һәм гаилә кешеләре ашау хәрәм. Ул кеше малның итен, азарынган булуы сәбәпле, фәкыйрьләргә садака итеп таратыр.

Нәзер болай була. Бер кеше: «Бу максатыма ирешсәм, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен шул эшне кылырмын!» — дип азарынган булу. Әмма нәзер, шәригать нигезләреннән күренгәнчә, фарыз яки важиб җенесеннән булырга тиеш. Әйтик, өч көн ураза тотармын, яки фәкыйрьләргә ризык-азык өләшермен, яки фәлән сум садака бирермен дигән кебек, яки мәсҗид төзетермен һәм башкалар.

Әгәр дә бер кеше: «Фәлән әүлиянең рухына корбан чалырмын» яки: «Әүлияләр рухына садака бирермен», — кебек сүзләр белән бер-бер әүлияга атап кына нәзерләнсә, ягъни азарынса, бу дөрес булмас, ул аларны үтәсә дә, бу гамәле хәрәмнән саналыр. Чөнки нәзер — ул шулай ук гыйбадәтнең бер рәвеше! Ә гыйбадәт Аллаһы тәгаләдән бүтәнгә аталып кылынса, дөрес булмый! Шуның өчен алай нәзер иткәндә: «Әгәр дә бу-бу эшем барып чыкса, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен, бер әүлиянең рухына корбан бугазлармын!» яки: «...садака бирермен!» — дисә, бу азарынуы дөрес булыр. Әйтерләр, нәзер — хикмәтледер, ул теге яки бу эшнең уңышлы барып чыгуы өчен көч-куәт бирә. Әмма нәзер, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен дип әйтү белән, Аллаһы тәгаләгә атала. Борынгылардан шул билгеле, Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен теге яки бу әүлия, пәйгамбәр, галим рухына багышланган корбан, садака бик котлыдыр.

Корбанның максаты — кан агызу. Моны онытырга ярамый. Шунлыктан бугазланыла торган

мал көр, яхшы, дәү булырга тиеш. Каны никадәр күп булса, шулай ук мактаулыдыр.

Корбан ите тигез *өч* өлешкә бүленер. Беренче өлеше фәкыйрьләргә садака буларак бирелер; икенче өлешен, пешереп, якыннарына, туган-тумачасына, күрше-күләменә аш ясап ашатыр; өченчесен исә үз җәмәгатьләре белән ашар, гаиләсенә калдырыр.

Әгәр дә бер кешенең бары тик корбан алырлык кына байлыгы булса яки ул артык бай кеше булмаса, ул вакытта корбан итен фәкыйрьләргә тaратмыйча, садака итеп өләшмичә, шулай ук туган-тумачасын, күрше-күләмен аш ясап сыйламыйча, гаиләсен туклaндырырга гына калдырса да дөрестер. Чөнки корбанның максаты, исебезгә алсак, кан агызу. Әмма байлыгы бар кешеләр корбаннарының итен өчкә бүлеп, инде сөйләп узылганча гамәл итмәсәләр, корбаннары дөрес булмас.

Корбан малының тиресен, әгәр дә үзенең мәхәлләсендәге имам яки мөәззин ярлы булсалар, аларга бирер. Бай булсалар, аны ярлы кешегә тапшырыр. Корбан тиресен сатып, аның акчасын бирсә дә бу дөрес гамәлдер.

Әгәр дә берәү корбанны үзе бугазлый белсә, барлык хөкемнәрен җиренә җиткереп башкара алса, үзе бугазлар, саваплырактыр. Әгәр үзе белмәсә, яхшы кешедән үтенер. Алай да дөрес булыр.

*Корбан хайванын бугазлау шартлары:*

Корбан өчен яки иткә булуга карамастан, хайванны «Бисмилләһ» — әйтеп чалырга тиешле. Моннан тыш тагын да дүрт нәрсәне кисеп җиткерү шарт: беренчесе, бугазын, икенчесе, ашау һәм эчү юлын, ягъни җенен; өченчесе һәм дүртенчесе, муенның ике ягындагы юан тамырларны. Шушы дүрт нәрсәнең дүртесен дә тәмам кисәргә кирәк. Өчесен генә кисә икән, ул да дөрес, әмма икесен генә киссә, корбаны дөрес булмас.

Корбанны бугазлаганда һәм гомумән мал чалганда бугаз төенен баш ягында калдыру шарт.

Әгәр бер кеше хайванны бугазлаганда «Бисмилләһ»не әйтергә онытып калдырса, шулай гына чалса, ул итне ашау дөрес булыр. Әмма белә торып, максатчыл рәвештә «Бисмилләһ»не әйтмәсә, шулай

бугазланган малның итен ашарга ярамас, ул үләксә хисабына керер. Ә үләксә ашау — хәрәм.

Корбан малын чалганда һәм гомумән мал бугазлаганда, хайванны кыйблага каршы сул ягына яткырырлар. Аякларын бәйләрләр. Шулай да арт аягының уңын бәйләмичә калдыру яхшырак. Пычак бик тә үткен булсын. Хайванны җененнән (үңәченнән) һәм койрыгыннан тартып рәнҗетү ярамас. «Бисмилләһ. Аллаһү әкбәр» — дип чалып җибәрерләр һәм бу доганы укырлар:

اَللّٰهُمَّ اِنَّ صَلَاتِى وَ نُسُكِى وَ مَحْيَاىَ وَ مَمَاتِى لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ لَا شَرِيكَ لَهُ ❁ اَللّٰهُمَّ تَقَبَّلْ هٰذِهِ الْاُضْحِيَّةَ مِنِّى ❁

*Аллаһүммә иннә саләти вә нүсүки вә мәхйәйә вә мәмати лилләһи раббил-галәминә лә шәрикә ләһ. Аллаһүммә тәкаббәл һәзиһил-удхийййәтә минни*

Шулай итеп, корбан үзе өчен булса, догасын шушы рәвешле «минни», ягъни «үзем өчен» дигән сүз белән бетерер. Әгәр дә үзе өчен булмыйча, кемгәдер багышланган икән, әйтик, ир кешегә, ул вакытта «мин фәлән бине фәланин», ягъни «фәлән улы фәләнгә» дип бетерер, әйтик, Латыйп улы Әхмәткә икән, «мин Әхмәд бине Латыйбин» дияр. Әгәр дә корбан бирәр хатын-кызга икән, ул вакытта «мин фәләнәтә бинте фәланин», ягъни «фәләннең кызы фәләннән» диеп тәмамланыр, әйтик, Латыйп кызы Хәлимә икән, «мин Хәлимә бинте Латыйбин» булыр.

Бу доганы корбанын бугазлагач укыса да ярый, алдан да, ахырдан да дөрес санала.

Әгәр дә теләсә, бу доганы, һич булмаса, татарча укыса да ярый. Ул болай укыла: «И Аллаһы тәгалә, чыннан да минем намазым һәм гыйбадәтләрем, тереклегем һәм үлемем — барча галәмнең хуҗасы булган Аллаһы тәгалә өчен, аның кодрәтендәдер! Аллаһы тәгаләнең тиңдәше юк! И Аллаһы тәгалә, шушы корбанны миннән кабул кыл-

саң иде!» — дияр яки ахырдан, әгәр дә бүтән кешенең корбаны икән: «И Аллаһы тәгалә, шушы корбанны фәлән улы фәләннән кабул кылсаң иде!» — дияр. Әмма «фәлән улы фәлән» урынына ул кешенең әтисенең һәм корбан хуҗасы исемен әйтү шарт. Монда «фәлән улы фәлән» дип гомуми рәвештә генә әйтелде. Әгәр дә хатын-кызның корбаны икән, «фәлән кызы фәләннең корбанын кабул кылсаң иде!» — дип тәмамлау тиешле, әлбәттә әтисенең һәм ул хатынның асыл исемнәрен атап. Бу очракларда үзеңне кыстырудан саклану тиешле, юкса кеше корбанын үзеңә урлаган кебек булып, яхшылык урынына хәрәмгә батачаксың. Корбан кем исеменнән бугазланылса, кем чалуга да карамастан, бары тик аларның гына исеме, зур мал икән, исемнәре догада әйтелергә тиеш.

Корбан бугазлаганнан соң ике рәкәгать намаз уку киңәш ителә. Бу исә бәйрәмне тагын да бөтенәйтеп җибәрер. Шушы намаздан соң дөньялык һәм Ахирәт өчен Аллаһы тәгаләдән изгелекләр соралыр.

Хаҗиларга охшар өчен корбан бугазлаган кеше зөлхиҗҗә ае буена чәчен алдырмыйча, тырнакларын кисмичә йөрсә, шулай ук мактаулы була. Болар барысы да мөстәхәб гамәлләргә керәләр, ягъни аларны үтәсәң — савап, ташласаң, моның өчен шелтә һәм ачулану ирешмәс, начарлыгы юк.

Болар мөстәхәб булу сәбәпле, гәрчә корбанны кыйблага каратмасаң да, хайванның йоннарын йолкып, койрыгыннан тартсаң да, дүрт аягын бәйләп чалсаң да, бик алай үткен булмаган пычак белән бугазлаган вакытта берничә кат ышкысаң да, дога укымасаң да ярый. Әлбәттә болар килешсез гамәл кебек күренсәләр дә һичбер зыян юк, әмма савабы аз булыр. Бары тик «Бисмилләһ» — дип әйтергә генә онытма, аны гына ташлама, корбаның хәрәм булмас, кабул ителер. Шулай да йоласына һәрьяктан туры китереп корбан бугазлау мактаулы һәм яхшыдыр! Корбанны бугазлаганнан соң ике рәкәгать намаз укымасаң да, чәчләрне алдырып, тырнакларны кистерсәң дә ярый, һичбер гөнаһы булмас.



6 Ч-330

Корбанны бугазлагач, корбанның ашарга киңәш ителми һәм ярамый торган җирләрен урамга яки чүплеккә ыргытырга ярамый. Аларны бергә җыеп, җиргә күмеп куярга кирәк. Әмма бу да бары тик киңәш кенә ителә, тәртип өчен.

Мөселманнарга корбан итенең һәм гомумән хайваннарның җиде әгъзасын ашарга ярамый. Аларның алтысы — мәкруһ, әмма берсе — гөнаһ. Гөнаһ булганы шул — корбан чалгач, агызылган канын эчәргә, куырып һәм бүтән рәвешкә кертеп ашау яки эчү тыела. Бу катгый кагыйдә. Кан эчәргә һәм ашарга ярамый, гөнаһы бик зур икәнен онытмаска кирәк!

Калганнары: сарыкларның җенес әгъзасын ашау тыела, шулай ук тәкәнең җенес әгъзасын ашарга киңәш ителми. Хайваннарның күкәйлек йомыркаларын шулай ук ашарга киңәш ителми, мәкруһ санала. Сидек куыкларын, ягъни куык кабын ашарга ярамый. Бизләрне ашарга киңәш ителми. Үт куыгын да ашарга ярамый. Боларның барсын да бергә җыеп, җиргә күмәрләр. Ә калган һәммә әгъза вә урыннарын ашарга ярый.

Әгәр дә бер кеше корбанын үзе бугазламый икән, ул вакытта сугымчының янында торуы дөрес булыр һәм тиеш күрелә. Моның сәбәбе шуннан: Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең күз алмасы кызына болай дип әйткәнлеге мәгълүм: «И кызым,— дигән ул,— корбаныңны бугазлаткан вакытта янында бул, шуның өчен, җиргә төшкән беренче тамчы каны белән барча гөнаһларың гафу кылыныр!»

Бу мәсьәләләргә бик тә игътибарлы булырга кирәк!

## ТӘРАВИХ НАМАЗЫ ХАКЫНДА

Тәравих намазы рамазан аенда кылына һәм сөннәт мөәккәдә санала. Аны ирләр дә, хатыннар да укырлар. Бигрәк тә өйдә яки мәсҗидтә ирләр, җәмәгать корып, тәравих намазларын укыйлар икән, яхшыдыр һәм савабы да артыктыр.

Тәравих намазы егерме рәкәгать итеп башкарыла. Һәр дүрт рәкәгатьтән соң бер сәлам бирергә яки егерме рәкәгатьнең барсын укыганнан соң сәлам әйтеп тәмамларга мөмкин. Әмма һәр ике рәкәгатьтә бер сәлам биреп, һәр дүрт рәкәгать арасында дүрт рәкәгать намаз уку вакыты кадәрле утырып тору сөннәт мөстәхәб санала. Шушы утыру вакытында, әгәр дә теләгеңдә бар икән, Коръән укырга мөмкин, яки тәсбих әйтергә, яисә тик торырга да ярый. Бу утыруны «ял итү», ягъни тәравихәт дип йөртәләр.

Тәравих намазына бу рәвешле ният ителер: «Ният иттем бу кичәнең тәравих намазын укырга!» — дип. Әгәр дә имамга оеса: «Оедым шушы имамга!» — дип тә өстәү шарт. Арада сәлам биргәннән соң дөнья сүзләре сөйләшенмәсә, ашамаса-эчмәсә, дөнья гамәлләрен башкармаса, шул бер ният белән егерме рәкәгатьне ахырына кадәр башкару дөрес булыр. Тәравих өчен егерме рәкәгать бер намаз исәпләнә.

Тәравих намазы йәсигъ (йәстү//ястү) намазының вакыты кергәннән алып, тәмамланганчы, ягъни соңгы минутына кадәр, теләсәләр, кич ахырында, яки төн уртасында, яки таңга кадәр укылыр. Ләкин йәсигъ намазының фарызыннан соң кылыныр. Аннан алда дөрес булмас. Ә витр намазы тәравихтан соң укылыр, әмма алдан укылса да ярый.

Бер кеше имамга тәравих намазы башлангач җитешсә, ул башта йәсигъ намазының фарызын һәм сөннәтен укыр, соңыннан имамга тәравих намазына оер. Имам белән витр намазын кылып, соңыннан, ничә рәкәгать тәравих намазы калган икән, аларны каза итеп укыр. Теләсә, тәравих намазын башта каза итәр, витр намазын соңыннан башкарыр. Икесе дә дөрес.

Әгәр дә имам һәм җәмәгать тәравих намазын укыганда, егерме рәкәгать укыдык инде, юк, унсигез генә булгандыр, дип шикләнә калсалар, санын ачыклый алырлык төгәл фикергә килмәсәләр, ул вакытта һәрберсе аерым-аерым итеп тагын ике рәкәгать намаз укырлар. Чөнки бу ике рәкәгать

артык булса, нәфел намазыннан китәр. Ә нәфел намазларын җәмәгать белән уку мәкруһ санала, шунлыктан аны аерым-аерым укырга тиешледер.

Тәравих намазларында иң азы «Фатиха» сүрәсеннән соң өч кыска аять яки шушы өч кыска аять озынлыгында бер озын аять уку вәҗиб. Ике рәкәгатькә бер яки дүрт рәкәгатькә бер тапкыр сәлам биреп, һәр утырганда салават чыгып, аякка баскач, «Сөбханәкә...», «Әгузү...», «Бисмилләһ...» белән башлап укырга кирәк. Рөкүгъ хәленнән торганда, ике сәҗдә арасында тәгъдил әркәнне онытып калдырмау шарт. Чөнки тәгъдил әркән фарыз һәм вәҗиб булып тора. Әгәр дә фарыз икән, ул вакытта, аны онытып калдырудан, намазы бозылыр. Әгәр дә онытып калдырса, сәҗдәи сәһү тиешле булыр.

## НӘФЕЛ НАМАЗЛАРЫ

Нәфел намазы дип арттырып укылган намазга әйтәләр. Әгәр дә фарыз һәм вәҗиб түгел икән, ул намаз нәфел намазы дип йөртелә. Бишвакыт намазларның фарыздан тыш укылган барча сөннәтләре нәфел намазлары була. Аларны укымыйча калдырудан Аллаһы тәгаләдән ачулану һәм газап ирешми. Укысаң, макталырсың, савабы артык булыр. Калдырсаң, газапка тартылмассың.

Нәфел намазларын укырга керешеп, аны бозсаң, каза тиешле була. Әгәр дә дүрт рәкәгатьтән бер сәлам биреп, нәфел намазларын дүрт рәкәгать кылырга ниятләнеп укырга керешкәч, ике рәкәгатьтән соң сәлам биреп чыксаң, яки ике рәкәгатен соңыннан каза кылырга кирәк, яисә барлык дүрт рәкәгатен дә башкарасың, ул очракта да каза итәсең.

Әгәр дә нәфел намазын дүрт рәкәгать укырга ниятләнеп, ике рәкәгатен тәмамлап, өченче рәкәгатьтә кыямнан алдарак намазын бозса, ул чагында каза тиешле түгел, чөнки нәфел намазы тәмамланган исәпләнер. Нәфел намазы дүрткә бер сәлам белән, ягъни дүрт рәкәгатенә бер сәлам белән укы-

луга карамастан, ике рәкәгате бер намаз булганлыктан, ике рәкәгать кылуга намазы тәмамланган исәпләнер. Әмма өченче рәкәгатьне башлап, кыямнан соң намазын бозса, каза таләп ителер, чөнки бер рәкәгатьтән намаз төзелми.

Ә сөннәт мөвәкдә намазлары дүрт рәкәгатьтән бер намаз җыела, шунлыктан андый намазларны боза икән, ул вакытта дүрт рәкәгать каза тиешле була, әйтик, өйләнең алдагы сөннәте, җомганың әүвәлге һәм ахыргы сөннәте. Боларның кайсы рәкәгатендә намазын бозса да, каза тиешле.

# Ислам диненең нигезләреннән өченчесе — рузә (ураза)

Ислам диненең нигезләреннән өченчесе — рамазан аенда *ураза тоту,* бу гамәл һәрбер балигъ кешегә һәм үз акылындагылар өчен фарыз санала. Кемнәр уразаны инкарь итәләр, алар кяферлеккә чыгалар, кяфер булалар.

Ураза, ягъни тыелу, ул таң атканнан кояш баеганчыга кадәрле, ният итеп, ашауны, эчүне һәм хатыннар белән якынлыкны калдырып тору дигән сүз.

Уразаның фарызы — *өч. Беренчесе:* ният итү; *икенчесе:* уразага ният итүнең дөрес вакытын белеп башкару; *өченчесе:* таң атканнан кояш баеганчыга кадәр ашауны, эчүне, якынлыкны тыю, аларны кую-калдыру.

*Ният ул шул* — күңелең белән теләп бу эшне кылуны үз өстеңә бар җаваплылыгы белән алу. Тел белән ниятләмәсәң дә ярый, моның белән бурыч артмый һәм кимеми. Әмма тел белән ниятләү мөстәхәб күрелә. Ул болай ниятләнелә:

نَوَيْتُ اَنْ اَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ اِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى ❀

*Нәвәйтү ән асумә саумә шәһри рамаданә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби халисан лилләһи тәгалә*

Т а т а р ч а ниятләү рәвеше: «Ният кылдым Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен рамазан аеның уразасын тотуга, таң вакытыннан башлап, кояш баеганчыга кадәр!»

*Ураза өчен ниятнең дөрес булган вакыты* — кояш баеганнан алып, өйлә вакытына бер сәгать чамасы калганчыга кадәр. Әгәр дә бер кеше иртәгәге уразасы өчен кояш баемас борын ният кылса, дөрес булмый. Шулай ук шушы ук көннең уразасына өйләгә бер сәгать чамасы гына калгач ният итсә, дөрес булмый. Әгәр дә инде уразасы каза яки билгесез икән, кояш баеганнан алып таң атканчыга кадәр булырга тиеш, таң атканнан соң нияте бу очракта ялгыш саналыр.

Уразалар *өч* төрле була: беренчесе, фарыз — рамазан аеның уразасы; икенчесе, важиб, ягъни нәзер ителгән ураза; өченчесе, нәфел, ягъни фарыз һәм важиб саналмаган, әмма саваплы күрелгән уразалар.

Әгәр дә бер кеше рамазан аенда уразасын сәбәпсез калдырса, ашап-эчеп йөрсә, зур гөнаһ иясе булыр.

Әгәр дә бер кеше үзенең хатынын үз анасына охшатса, яки апасы белән бутаса, яисә ботын, чәчен, бүтән бер җирен әнкәсенеке яки апасыныкы белән чагыштырып, охшашлык тапса, ул вакытта аңа хатыны хәрәм булыр. Моның өчен ике ай тоташтан ураза тоту таләп ителер. Шуннан соң гына хатыны хәләл саналыр. Әгәр дә ике ай тоташтан ураза тота алмый икән, ул чагында алтмыш фәкыйрьне иртән һәм кич белән сыйлар, аш ясап чакырыр, туклandырыр яисә һәр фәкыйрьгә атап сигез кадак хөрмә бәһасеннән аерым-аерым хәер өләшер.

Ураза бозылса, көне өчен көн бәрабәрендә соңыннан ураза тотар, әгәр дә күңеле белән инанмыйча, уразаны инкарь итсә, ул кеше Ислам диненнән чыгар.

Бер кеше рамазан аенда ялгышлык белән, әйтик, тәһарәт алганда бер тамчы су эчсә яисә кояш баеды, дип авыз ачса һәм шуныңише бер-бер хата белән, уразасы исендә булып та аны бозса, моның өчен каза тиешле булыр, шул көне өчен уразадан соң бер көн атап ураза тотар.

Әгәр дә ураза икәнлеген онытып якынлык кылсаң, каза таләп ителмәс.

Бер кеше рамазан аенда көндез хатыны белән якынлык кылса яки йокыда адашса, кичектермәс-

тән госел коенсын. Госел коенганда авыз-борынга су алып, аларны чайкау шарт. Шунлыктан ураза вакытында госел коенганда шулай ук авыз-борынына су алыр һәм чайкар, моны калдырса, госеле дөрес булмас. Әмма суны тамак төбенә үк китереп гыргырламас.

Бер кеше уразада үзенең уразада икәнлеген онытып ашаса һәм эчсә, уразасы бозылмас. Мәгәр дә ашаган вакытында кинәт хәтеренә килсә, тиз генә төкерер. Бугазына азыктан вак төерләр китсә, алар уразасын бозмас.

*Ураза вакытында бу эшләр мәкруһ:* файдасыз сүзләр сөйләшү, әдәпсез сүзләр әйтү, кеше белән кычкырышу, суга чумып коену, сагыз чәйнәү, берәр нәрсәгә тел тидерү, тәмен карау (әмма хатыннарның ирләре усал булып, ризык тәменә таләпчән икән, ул вакытта бу хатынның аш тәмен каравыннан уразасына зыян килмәс), хатыннар белән үбешү, ашамыйча берьюлы ике көн ураза тоту, бербер гөнаһлы гамәлне башкару.

Бер кеше әгәр дә госел коенырга тиеш булып та, таң атарлык икән һәм аның соңга калып сәхәр ашаячагында шиге туса, иң әүвәл авызын яхшылап чайкар, сәхәр ашар, аннан соң гына госел коеныр.

Аш пешергән вакытта тамакка төтен китсә, ураза бозылмас.

Уразада берәү тәмәке тартса, уразасы бозылыр. Уразасын кабат тәртип итәр өчен алтмыш фәкыйрьгә садака бирергә тиешле булыр.

Әгәр дә бер кеше каты авырый икән яки ачлыктан авыру сәбәбе бар икән, аларга ураза тоту ярамас. Әмма соңыннан, сихәтләнгәч, көнгә-көн бәрабәренә ураза итәр.

Мөсафирлар йортларыннан чыккан көнне ураза тотарлар, әмма икенче көннән уразаларын бозарлар, соңыннан каза кайтарырлар. Мәгәр юлда ураза тотуның мәшәкате юк икән, ул вакытта уразаларын бозмасалар да дөрес булыр.

Хәйз күргән хатыннарга ураза тоту ярамас, соңыннан көнен көнгә каза итеп кайтарырлар.

Әгәр дә бер хатын көне буе ураза тотып та, кичен, кояш баер алдыннан кан күрә икән, тиз ара

авыз ачарга тиеш. Әгәр дә болай эшләмәсә, кяфирә аталыр. Шулай ук, әгәр дә бер хатын намаз укыган вакытында кан күреме башлануын сизенеп, намазын ахырына кадәр җиткерсә, намазын бозмаса, шулай ук бу гамәле хәрәм булыр, үзе кяфирәгә чыгар. Кемнәр хәйз һәм кан күреме вакытында уразаларын бозарлар, соңыннан, савыккач, кайтарырлар, каза итәрләр.

Йөкле хатыннар, әгәр дә үзләренә яки балаларына ач торудан зыян килер дип белсәләр, ураза тотарга ярамас. Гомумән, йөкле хатыннарга ураза тотарга ярамый, соңыннан көнгә-көн кайтару гына тиешле күрелер.

Бала имезүче хатыннарга ураза тоту ярамас.

Әгәр дә бик зәгыйфь кеше икән, уразага көче җитмәсә, ураза тотарга ярамас, һәр көненә бер фитра садакасы бирсә, яхшыдыр.

Ураза вакыты үткәч, рамазан аенда, кояш баю белән үк, кичектермәстән авыз ачу сөннәт санала. Намаз алдыннан, ягъни ахшам намазы алдыннан, Мөхәммәд пәйгамбәребез кебек бер эчем су кабып кына авыз итеп булса да, авыз ачып, аннан соң гына ахшам намазына керешү сөннәт санала.

## ФИТРА САДАКАСЫ ХАКЫНДА

Рамазан аенда фитра//фитыр садакасы бирү ваҗиб гамәлләрдән санала. Әмма фитра бирү өчен малың үзеңә кирәктән һәм бурычыңнан артык булырга тиеш, ким икән, садака бирмисең. Боларны онытмаска тиешле.

Фитра садакасын үзең өчен һәм сабый балаларың өчен бирү ваҗиб санала. Балигъ балалар һәм хатының үзләре өчен үз малларыннан чыгып бирерләр. Фитра садакасы сигез кадак җимеш, ягъни өч кило да ике йөз граммнан артык микъдарда яки шуның акчасы күләмендә бирелгәндә дөрес булыр.

Фитра садакасын фәкыйрь кешеләргә, авыр тормышлы гаиләләргә Рамазан бәйрәме көнне таң аткач бирү дөрес. Рамазан ае керүгә үк биреп куйса

да ялгыш түгел, соңга калу белән барыбер өстеңнән төшми. Иң яхшысы, Рамазан бәйрәмендә таң белән бирелгән фитра садакасыдыр. Фитра садакасын байларга һәм мәсҗидләргә атап бирергә ярамый, дөрес түгел, әмма шәкертләргә тәгаен кылсаң, хата булмас, шулай ук яхшыдыр.

# Ислам диненең дүртенче нигезе — зәкәт

Ислам диненең нигезләреннән дүртенчесе — байлар елга бер мәртәбә байлыкларына карап зәкәт бирергә тиешләр. *Зәкәт бирү* — фарыз гамәл, аны ташлаган кеше кяфер булыр.

Зәкәтнең фарызы — малдан зәкәт аерылыр һәм фәкыйрь кешегә ният итеп бирелер. Әүвәле малны биреп, аннан соң аны ният итү дөрес түгел. Әгәр дә бер кешегә бурычка мал яки акча биреп, соңыннан: «Түли алмадым инде, бу малым зәкәттән китсен!» — дип әйтү шулай ук соңыннан ниятләү була, дөрес түгел.

Зәкәтне малы бар кешеләр бирерләр, ярлылар зәкәт бирмәс. Шулай ук диваналар һәм сабыйлар зәкәт бирергә тиеш түгел. Зәкәтне фәкыйрьгә тапшырмасаң, соңыннан каза итү дә дөрес, әмма гафу сорап, Аллаһы тәгаләдән вакытында бирә алмавың өчен тәүбә итеп, ниятләп тапшыру тиешле. Зәкәтне бирми калдырсаң, соңыннан бәлагә таруың, зәхмәткә ирешүең көтелер. Сәламәтлеге юк кеше дә, әгәр ул бай икән, зәкәт бирергә тиеш. Кешене әүвәл эшләтеп, хезмәтенә тиешле хакын түләмичә, зәкәт итеп бирү тыела. Хезмәтеңә күрә алынган хезмәт хакың мохтаҗлыгыңа күрә генә икән яки байлык һәм мал ишәйтер өчен китмәсә, аннан зәкәт бирү тиешле түгел.

Кешеләрнең тора торган йорты, йорт эчендә җиһазлары, түшәк-ястыгы, кияргә киеме, кышлык һәм җәйлек өс-башы, җигәр аты, машинасы, тракторы (шуларның берсе), саварлык сыеры яки көн дә сөт алырлык акчасы булса, һөнәр иясе икән, әйтик, укучы яки укытучының китап-дәфтәрләре, балта остасының балтасы һәм эш кораллары кебек әйберләре бар икән, бурычы булса, аны түләрлек

малы бар икән, әгәр дә шулардан арткан малы булса, менә шул малдан зәкәт бирүе фарыз.

Әгәр дә берәүнең тормыш кирәгеннән артык акчасы бар икән, аннан елга бер тапкыр зәкәт бирелергә тиешле. Мәгәр асрар өчен алынган мал икән, ул вакытта аннан зәкәт бирелмәс. Әгәр дә сату итү өчен малы бар икән, аннан шулай ук елга бер тапкыр зәкәт бирелер. Хатын-кызларның алтын-көмеш бизәнү әйберләреннән шулай ук зәкәт бирелер.

Әгәр дә асрау өчен тоткан маллары булып, алар елның яртысыннан артыгын өйдә тәрбияләнеләләр икән, абзар-курада асрала икән, ул вакытта алардан зәкәт бирелмәс. Инде дә елның яртысыннан күп өлешен кырда, җәйләүдә йөртелсәләр, алардан зәкәт бирү тиешле.

Җәйләүдә ел әйләнәсенең яртысыннан артыгын йөргән маллардан зәкәт баш исәбеннән чыгып бирелер.

Сарык һәм кәҗә көтүе кырык баштан гыйбарәт икән һәм ул бер кешенең хайваннары исәпләнсә, шул вакытта гына зәкәт тиешле була. Әгәр дә кырыктан ким икән, ул вакытта зәкәт фарыз түгел. Әгәр дә зәкәт ике сарык икән, ул чагында сарыклар йөз дә егерме бер баш булырга тиеш, йөз дә егерме һәм аннан ким икән, бары тик бер генә сарык яки кәҗә зәкәт кылына. Ике йөз дә бер баш сарык яки кәҗә икән, ул вакытта өч сарык яки кәҗә зәкәт ителә, ике йөз баш яки кимрәк икән, бары тик ике кәҗә яки сарык зәкәткә тапшырыла. Әгәр дә дүрт йөз сарык һәм кәҗәсе бар икән, дүрт баш сарык яки кәҗә зәкәт кылыныр. Биш йөздән — биш, алты йөздән — алты... Дүрт йөздән соң һәр йөз сарык өчен берсе зәкәт итеп тапшырылыр.

Сыерлардан, әгәр дә утызга җитмәсә, сыердан зәкәт дөрес түгел. Утыз сыеры бар икән, бер яшьлек тана бозавын зәкәт итү ваҗиб. Үгез бозау да дөрес. Әгәр дә кырык баш сыеры бар икән, ике яше тулып, өченчегә чыккан сыер зәкәт кылыныр. Үгез дә дөрес.

Кырыктан алтмышка кадәр баш сыеры бар икән, бу өлешенә бер бозауның бәясеннән утыз

өлешенең берсен хисап кылып, акчалата зәкәт кылыр. Әйтик, берәүнең кырык бер сыеры бар икән, кырыгы өчен ике яше тулып узган бер сыерны зәкәт итәр, берсе өчен бер яшьлек бозавының утыздан бер өлеш бәясен бирер. Әгәр дә илле сыеры булса, кырыгы өчен ике яше узган сыер бирсә, унысына исә ике яше тулган сыерның кырыктан ун өлеш бәясен тапшырыр. Алтмыш сыеры бар икән, ике бозавын зәкәт кылыр. Җитмеш сыерына — бер бозау, ике яшьтән узган бер сыер бирер. Әгәр сиксән сыеры бар икән, ике яше тулган ике сыер бирер һәм алар үрчегән саен шулай арттырылып барылыр.

Бер кешенең биш дөясе бар икән, зәкәт тиешле булыр. Аннан ким исә, зәкәт фарыз түгел. Һәр биш дөя өчен куй зәкәт ителер. Егерме биш дөягә, ике яшькә чыккан дөя баласы, алтмыш дөягә бер дөя бирер.

Әгәр дә мал махсус, сату өчен алынса, зәкәтне сатудан кергән керемнең кырыктан бер өлеше итеп бирү фарыз. Әйтик, ун сарыкны сатып, кырык мең акча алса, бер мең зәкәт кылыр. Әгәр табышы кырыкка бүленми, аннан ким икән, ул вакытта зәкәт тиеш түгел. Әйтик, утыз тугыз тиен кырык тиенгә бүленми, шунлыктан бу очракта зәкәт таләп ителми.

*Зәкәт, фитра, нәзер һәм башка төрле садакаларны* Аллаһы тәгалә ризалыгы өчен, һәм Аллаһы тәгалә кабул итеп алсын дип *җиде төрле кешеләргә бирергә мөмкин.* Аларга тапшырганда гына садакалар дөрес була:

1. **Фәкыйрьләргә бирсәң. Фәкыйрьләр** шул — аларның мал-мөлкәтләре бары тик үз тормышларына гына җитеп бара, хәтта үзе кәсепче булса да.

2. Месکеннәргә бирсәң. Мескеннәр шулар ки, аларның бер күнлек азыклары булып, бүтән юк исә.

3. Бурычлы кешеләргә бирсәң. Бурычлы кеше дигәндә кулындагы малы бурычын түләргә генә җиткән кеше күздә тотыла. Әмма исраф итүче, начар гадәтләргә малын тотучы икән, ул кешене бурычлы дип түгел, бозык буларак атыйлар.

4. Ил башлыгының әмере белән зәкәт җыярга куелган кешегә зәкәт бирү дөрес.

5. Колларга, әгәр дә аның хуҗасы: «Син миңа фәлән кадәр мал китерсәң, азат итәрмен!» — дисә, шул колга, аны азат кылу өчен, зәкәт бирү дөрес.

6. Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен дип сугышка барган газыйларга зәкәт тапшыру дөрес.

7. Сәфәргә чыгып, кулындагы малын югалткан һәм иленә кайту мәсьәләсен хәл итә алмый мохтаҗланган кешегә зәкәт бирү, садака китерү дөрес. Хәтта үз йортында гаиләсенә җитәрлек һәм артык малы булса да, ә хәзерге хәлендәге мохтаҗлыгы сәбәпле аңа атап садака, зәкәт бирү дөрес.

*Зәкәтне алты кешегә бирүең ярамый:*

1. Әти-әниеңә, әби-бабаңа, алардан югары нәсел башларына.

2. Үз балаларыңа, оныкларыңа, ягъни үз нәселеңнән булганнарга. Әмма шунсын онытырга ярамый, әгәр дә балалары үги икән, үги ата яки үги анасы икән, аларга зәкәт бирү дөрес була.

3. Бай кешегә, байларның балаларына садака, зәкәт дөрес түгел.

4. Диваналарга зәкәт мал бирү дөрес түгел.

5. Кяферләргә бирергә ярамый.

6. Хатын үз иренә, ире үз хатынына зәкәт бирү дөрес түгел.

Зәкәт малыннан мәсҗидләр төзетү, мәдрәсәләр салдыру, күперләр ясату дөрес түгел. Шулай ук зәкәт малыннан үлек кәфенләтү ярамый. Коръәнне һәм бүтән төрле китапларны вәкыф малы итеп зәкәттән алу дөрес түгел.

Бер кеше әгәр фәкыйрьгә зәкәт бирә икән, моның зәкәт малы икәнлеген ачык итеп әйтеп, кулына тапшырырга тиеш. Әгәр дә алучының кулына биреп, аңа аңлатып әйтелмәгән зәкәт икән, билгесезлеге сәбәпле ул шулай ук зәкәттән саналмый. Зәкәт әгәр алучының кулына кермәгән икән, шулай ук зәкәт түгел.

Зәкәт, фитра, бүтән төрле тиешле саналган садакаларны үзенең якын кардәшләренә, күршеләренә бирү дөрес. Әгәр дә алар бай икән, мохтаҗлыклары күрелмәсә, ул вакытта фәкыйрьләргә атап

бирергә кирәк. Әмма зәкәтне надан фәкыйрьгә бирүгә караганда, галим фәкыйрьгә тапшыру саваплырак санала.

Кешеләрнең мохтаҗлыкларын күреп, аларга ярдәм кулын сузудан да яхшырак гамәл бармы? Менә шуңа күрә дә Аллаһы тәгалә садака, фитра, зәкәт кебек ярдәмчеллекне фарыз итеп мөэминнәргә йөкләде дә!

# Ислам дīненең нигезләреннән бишенчесе — хаҗ

Күче житкән кешеләргә гомерләрендә бер генә мәртәбә булса да *хаҗ кылу* фарыз гамәлләрдән санала, Ислам диненең төп нигезләреннән берсе булып тора.

Хаҗ шул кешеләргә фарыз: кемнәрнең акылы камил, яшьләре балигълыкка ирешкән, сау-сәламәт, йөрер юллары имин, Мәккәгә һәм Мәдинәгә барып һәм кайтып җитәрлек акчасы, үзе киткәч, өендә калган гаиләсенә ач тормаслык маллары булса. Әгәр дә боларның берсендә генә кимлек күрелсә дә, ул кешенең өстеннән хаҗның фарызлыгы төшәр. Ире яки карендәше белән барырлык булсалар, хаҗ шулай ук бай һәм сәламәт хатыннарга да фарыз. Бу таләпләр үтәлгәндә, хаҗның фарызлыгы билгеле булыр, аны кичектерү ярамас.

Хаҗның фарызлары *өч:*

*Беренчесе:* Ихрам, ягъни Мәккәгә барып кергәнче, «микат» (билгеләнгән урын) дип аталган җирләрнең берсендә хаҗ нияте белән тәлбия итү, шәригатьне боза торган гамәлләрдән тыелып, хаҗ киемен киенү.

*Икенчесе:* Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында тору.

*Өченчесе:* Тәуваф зиярәт итү, ягъни Гарәфәт тавыннан төшкәч, Мина дигән урында куныпт, бәйрәм көнендә Кәгъбәтуллаһны җиде мәртәбә әйләнү.

Хаҗга бу рәвешле ният итәрләр:

اَللّٰهُمَّ اِنِّى اُرِيدُ الْحَجَّ فَيَسِّرْهُ لِى وَ تَقَبَّلْهُ مِنِّى ❀

*Аллаһүммә инни уридүл-хаҗҗә фә-йәссирһү ли вә тәкаббәлһү минни*

Һич булмаса, т а т а р ч а ният итсә дә ярый. Ул болай әйтелер: «И Аллаһы тәгалә, чыннан да мин хаҗ кылуны ният итәмен, аны миңа җиңел кылсаң иде! Һәм аны миннән кабул кылсаң иде!» Шушылай ният иткәч, кычкырып тәлбия әйтү тиешле.

Тәлбия болай әйтелер:

لَبَّيْكَ اللّٰهُمَّ لَبَّيْكَ❀لَبَّيْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ اِنَّ الْحَمْدَ
وَ النِّعْمَةَ لَكَ وَ الْمُلْكَ لَا شَرِيكَ لَكَ❀

*Ләббәйкәл-лаһүммә ләббәйкә, ләббәйкә лә шәрикә ләкә ләббәйкә иннәл-хәмдә вән-нигъмәтә ләкә вәл-мүлкә лә шәрикә ләк*

Т а т а р ч а с ы бу рәвешле булыр: «И Аллаһы тәгалә, Синең гыйбадәтеңне камил итагать белән башкарам, Синең һич тиңдәшең юктыр, чыннан да барча мактаулар һәм барча нигъмәтләр Сиңа хастыр, һәм хуҗа булу да Сиңа хастыр, Синең һич тә тиңдәшең юктыр!» Шушы рәвешле тәлбияне ихрамнан чыкканчыга кадәр һәрбер намазның артыннан, юлларда йөргән вакытта, тауларга-калкулыкларга менгәч, түбәнлекләргә төшкәч, артык һәм киметмичә, яхшы тавыш белән әйтү тиешле.

*Хаҗның унҗиде төрле важҗибләре бар:*

1. Микат урыныннан ихрамга керү.
2. Саффа һәм Мәрвә таулары арасында йөреп, җиде тапкыр хезмәт кылу, тырышлык күрсәтү.
3. Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында кояш баеганчы тору.
4. Мөздәлифәдә тору.
5. Таш ату.
6. Таш атканнан соң чәчен алдыру, хатыннарга — чәчен кыскарту.
7. Мәккәдән чыгар алдыннан, өйгә кайту ниятендә булганда, Кәгъбәтуллаһны тагын да бер кат тәуваф (яки «туваф» — әйләнеп чыгу, әйләнеп йөрү) кылу, шул рәвешле хушлашу.
8. Тәуваftан соң ике рәкәгать намаз уку.
9. Көче җитсә, тәуваfны җәяү кылу.

10. Саффа һәм Мәрвә таулары арасында тырышлык иткәндә, ягъни сәгый кылганда җәяү йөрү.

11. Тәуафны тәһарәт алгач кылу, тәһарәтне саклау.

12. Тәуваф кылуны уң яктан башлау.

13. Гаурәт урыннарның каплануын тәэмин итү.

14. Киемнең чисталыгын тәэмин итү.

15. Тәуваф зиярәтен вакытында үтәү.

16. Тәувафны хөҗрәдән читтә, хөҗрәдән ерактарак башлау.

17. Тәуваф зиярәтен Корбан бәйрәме көннәрендә, корбан чалу көннәрендә башкару.

Әгәр дә хаҗ кылучы кеше өч фарызның берсен үтәмәсә, хаҗы дөрес булмас, бозылыр. Важибләреннән берсен калдырса, онытып яки махсус рәвештә, белмичә үтәмәвенә карамастан, бер корбан чалдыру тиешле булыр. Корбан белән хаҗы тәмамланыр. Әгәр дә хаҗның сөннәтләреннән берсен калдырса, хаҗы бозылмас, әмма соңыннан моның өчен садака бирергә тиеш булыр.

Хаҗны *өч* нәрсә бозар:

*Беренчесе:* Өч фарызның берсен үтәмәү.

*Икенчесе:* Гарәфәттә тукталышка торудан әүвәл якынлык кылу. Ирме, хатынмы, онытылыпмы, белмичәме якынлык итсә, хаҗы бозылыр, бу кешегә бер корбан чалдыру тиешле күрелер, киләсе елга хаҗ кылуы соралыр.

*Өченчесе:* Хаҗ кылырга көче җитмәү. Бу көче җитмәү дүрт төрле:

1. Авырып китүдән соң хаҗдан тукталу.
2. Дошманга очрау, сугыш башлану.
3. Малы һәм акчасы бетү.
4. Бер җирдә тоткын ителү.

Хаҗга ният итеп чыккан кеше шушы дүрт сәбәп аркасында тукталырга мәҗбүр булган икән, Мәккәгә бер корбан җибәрер яки корбан бәясен озатыр. Бу корбанын яки акчасына корбан алып, аны бугазларлар, соңыннан бу кеше хаҗилыктан чыгар, киләсе елда хаҗ кылыр.

*Хаҗга чыккан кеше ихрамда вакытында егерме сигез төрле эшнең берсен генә башкарса да, корбан чалдыру тиешле булыр. Алар:*

1. Әгәр дә берәр әгъзасына ислемай сөртсә.

2. Бер әгъзасы зурлыгында тәненә ислемай сөртсә.

3. Тәненең бер урынына бөтен бер әгъзасына җитәрлек ислемай тамызса.

4. Берәр әгъзасына сыек май ише нәрсә сөртсә. Әмма сыек булмаган май яки ит мае сөртсә, ярый.

5. Зарур булмаганда өстенә тегелгән күлмәк кисә, аякларына итек яки читек кисә, бу киемнәре көне буе яки төн чыкканчы өстендә калса, корбан чалдыру таләп ителер.

6. Әгәр дә бер көн яки төн буена башына яисә йөзенә берәр нәрсә япса, хәтта башының дүрттән бер өлешенә япса да.

7. Чәченең дүрттән бер өлешен алдырса яки дүрттән бер өлешен киссә.

8. Култыгын, касыгын, кан алдыра торган җирләреннән чәч төкләрен кырдырса.

9. Кул-аякларының, яки бер кулы, яисә бер аягының тырнакларын киссә.

10. Әгәр дә Гарәфә тукталышында торганнан соң якынлык итсә, моның өчен бер дөяне корбан китерү таләп ителә.

11. Хатыннарны үпсә, кызыгып кул тидерсә.

12. Тәһарәтсез хәлендә тәуваф кылса.

13. Якынлык кылып, госелсез хәлендә тәуваф кылса.

14. Тәуваф кылуның өч шартын үтәмәсә.

15. Тәувафны корбан чалу көннәреннән соң үтәсә.

16. Саффа белән Мәрвә таулары арасында сәгый хөкемен калдырса.

17. Гарәфәт тавыннан имамнан алда кайтса.

18. Гарәфәттән кояш баеганчы кайтса.

19. Таш атуны өч көнендә дә үтәмичә, бер көнендә генә калдырса да.

20. Корбан чалу көннәрендә таш атуны үтәмичә, соңыннан башкарса.

21. Корбан бәйрәме көннәре чыкканчы кичектереп, чәчен алдырмаса яки кыскартмаса.

22. Ау аулап, кыргый хайванны үтерсә.

23. Аучыга ауланган хайванын күрсәтеп дәлилләсә.

24. Ауланган хайванның итен ашаса.

25. Ите хәләл саналмаган ерткыч хайванны үтерсә.

26. Аякларында канат кебек йоннары булган күгәрченне үтерсә.

27. Йортка-кулга иялəштерелгән кыргый хайванны үтерсә.

28. Микат урынын ихрамсыз узса.

Боларның кайсын гына эшләсә дә, ул кешегә корбан бугазлату тиеш булыр. Әгәр дә корбан чалдыруны калдырса, хаҗы ким саналыр. Тәувафны сафланган хәлендә үтәмәсә, Гарәфәттә торганнан соң, тәуваф кылганчыга кадәр якынлык белән шөгыле булса, дөя корбан итү тиешле, ваҗиб күрелә. Калганнарында исә, онытып яки үз теләге белән кылуына карамастан, сарык корбан китерү дөрес санала.

*Хаҗилар егерме төрле эшнең берсен генә кылса да, аны төзәтү өчен садака бирергә тиешләр. Алар:*

1. Бер әгъзасының аз гына җиренә булса да исламай сөртсәләр.

2. Бер көннән ким яки бер кичәдән ким вакытка өсләренә тегелгән кием кисәләр.

3. Башның дүрттән бер өлешеннән кимрәк җирен һәм мыекны кыру.

4. Үзе хаҗи икән, икенче хаҗ кылучының чәчен алу.

5. Берәр сәбәп белән табибка күренеп, дару ашау яки берәр сәбәп аркасында тегелгән кием кию. Әгәр дә боларны эшләсә, йә корбан бугазлар, яисә алты мескенгә садака бирер, яки алты көн ураза тотар.

6. Тәувафны тәһарәтсез кылу.

7. Тәувафны үз аягы белән йөрүне калдыру, тәувафны башкармау.

8. Тәувафның өч шартын калдыру.

9. Тәувафның өч шартын кичектерү, әгәр берсен генә кичектерсә дә ярамас, һәр шарты өчен, кичектерсә, бер мескенне туйдыру таләп ителер.

10. Таш атуда берсен калдыру.

11. Бет яки чикерткә үтерү, әгәр дә бет яки чикерткәне үтерсә, алар өчен күпме тели, шулкадәр садака бирер.

12. Зәгъфран ашап, авызының һәрбер җиренә тәме ирешсә.

13. Әгъзасыннан кимрәк өлешенә кайнап чыккан май сөртсә.

14. Хуш исле сөрмә тартса.

15. Аякларында һәм кулларында биштән ким тырнакны киссә, һәр тырнак өчен бер мескенне туйдырыр.

16. Кош йомыркасын ватса, бәясен бирергә тиешле.

17. Бер хайванның аякларын сындырса, йөрерлек булмаса,ул хайванның бәясен хуҗасына бирү тиешле.

18. Хәрәм шәриф агачларыннан берсен киссә яки сындырса, садака бирергә тиеш.

19. Берәр ауланган кыргый җәнлекне җәрәхәтләсә яки йонын йолкыса, садака бирергә тиеш.

20. Ауланган җәнлекнең әгъзасын сындырса, хакын бирер.

Әмма хаҗиларга котырган этне, ала карганы, тилгәнне, еланны, чаянны, тычканны, бал кортын, кырмысканы, кыскычны, кара чебенне, озынборынны-черкине, вак чебенне, борчаны, ташбаканы һәм керпене үтерергә ярый, шушы аталган җан ияләрен хаҗ вакытында үтерсә, алар өчен садака һәм корбан бирүе таләп ителмәс. Әгәр дә төлке, бүре, юлбарыс хаҗига һөҗүм иткәндә, шулвакыт аларны үтерсә, һичбер корбан таләп ителмәс. Алар өчен ни дә булса түләү соралмый. Әгәр дә алар аңа һөҗүм итмәсә дә үтерә икән, ул вакытта алар өчен корбан бугазлатуы таләп ителә.

Хаҗиларга кыр үрдәге, кыр казы һәм шундый кыргый хайваннарны бугазлау дөрес түгел, әмма сыер, сарык, тавык, каз, үрдәк кебек йорт хайваннарын бугазлый-чала икән, болар рөхсәт ителә. Хаҗга чыккан кешеләрдән менә шушыларны катгый рәвештә үтәү таләп ителә.

## ХАТЫННАРНЫҢ ХАҖЫ ҺӘМ ИРЛӘРНЕҢ ХАҖЫ АРАСЫНДА АЕРМАЛАР

Хатыннар хаҗы белән ирләрнең хаҗы арасында унбер нәрсәдә аерма бар.

*Ваҗибләрдәге аермалар:*

1. Хаҗга ире яки туганы белән бару хатыннарга тиешле.

2. Хаҗга барыр өчен үзенә һәм иренә яки үзенә һәм үзе белән баручы туганына, улына җитәрлек акчасы булуы шарт.

Әгәр болар үтәлмәсә, ул хатыннарга хаҗга бару фарыз түгел.

*Хаҗ кылуда аермалар:*

1. Хатыннар тәлбияне яшерен әйтерләр.

2. Хатыннарга өсләренә тегелгән кием кию дөрес.

3. Хатыннар Караташны үбәргә һәм кулларын аңа тидерергә тиеш түгелләр, әгәр дә Караташ янында ирләр юк икән, ул вакытта аны үбәргә рөхсәт бар.

4. Хатыннар өчен тәуафта җилкәләрен сикертеп, ашыгып йөрү юк, аларның барчасына тыныч кына йөрү сөннәт санала.

5. Хатыннар Саффа һәм Мәрвә таулары арасында сәгый иткәндә таулар башына чыкмаслар, әгәр дә ирләрдән тау башлары буш булса, ул вакытта аларга анда чыгарга рөхсәттер.

6. Башларын ачык йөртергә ярамас, әмма йөзләрен ябарга ярамас.

7. Хатыннар ихрамнан чыкканда чәчләрен кырдырмаслар, бик күп тә кыскартмаслар, бәлки чәчләренең очын бармак башы кадәрле генә кисеп алырлар.

8. Ике миль, ягъни дүрт чакрым саен сәгый итмәсләр.

9. Хатыннар тәуафта хушлашу-видагъны калдырсалар, алардан корбан тиешле булмас.

## ЗӘМЗӘМ СУЫН ЭЧҮ

Зәмзәм суын кыйблага каршы басып, аяк өсте өч йотым кадәрле генә эчү дөрес. Аны эчкәндә шушы доганы укырлар:

اللّٰهُمَّ اِنّى اَسْئَلُكَ رِزْقًا وَاسِعًا وَ عِلْمًا نَافِعًا وَ شِفَاءً مِنْ كُلِّ دَاءٍ ❀

*Аллаһүммә инни әс-әлүкә ризкан вә сиган вә гыйльман нәфиган вә шифаган мин күлли да-ин*

Т а т а р ч а с ы: «И Аллаһы тәгалә, чыннан да мин Синнән сорыймын киң ризыкны һәм файдалы гыйлемлекне һәм һәртөрле авырудан шифаны!»

Хаҗларыгыз милләткә файдалы булсын!

الحمد لله **Әлхәмдүлиллаһ**

# Ислам динендә йола вә әдәп



● Дөньяга килү ● Бәби туе ● Исем сайлау ● Йорт салу ● Урамда йөрү ● Юлга чыгу вә сәфәр ● Никах ● Күршелек һәм күршеләр белән тору хакында ● Тәүбә ● Бәлаләрдән саклану вә авырулардан дәва ● Авыруларның вә түшәккә яткан кешеләрнең хәлен белешү ● Дөнья белән саубуллашу, үлем, җеназа ● Үлгәннәрне искә алу, каберләрен зиярәт кылу ●

# *Кереш*

*Без бу белешмәләрне «Йола вә әдәп» дип атадык. Чөнки Ислам дине буенча, нинди генә булмасын, йола һәрвакыт, иң әүвәл, әдәп тойгысы белән бергә өртелеп, шуның аша мәйданга килгән, икенчедән, кешенең тормышын вә яшәү рәвешен тәртипкә салган. Ислам дине йолалары чын мәгънәсендә әдәп бакчасы. Бу бакчада төрле җимеш агачлары үсәләр, сихри җимешләр бирәләр. Бары тик алар янына килергә, аларны таныргa өйрәнергә вә тормышта файдалана белергә генә кирәк. Шул вакытта бу җимешләрнең чиксез татлы булуын аңларсың, гөнаһлардан арынырсың, бәхеткә вә камиллеккә ирешерсең.*

*Без монда дин белән бәйләнешле булган барлык йолаларны да кертә алмадык. Барыбызга да көндәлек тормышта кирәк саналган вә күпмедер күләмдә яшәү рәвешебезнең нигезен тәшкил иткән йолалар хакында гына сөйләнелде. Кешенең туганнан алып үлгәнчегә кадәр тормышы, Ислам өйрәтмәләре нигезендә, ничек булырга тиешлеген ачык бәян итү таләп ителде. Шактый күп борынгы китапларга ияреп бу хезмәт мәйданга килде.*

*Тагын да тулырак мәгълүмат алырга теләүчеләр «Дөррел-мәсаил вә күшкед-дәлаил» («Мәсьәләләрнең энҗеләре вә дәлилләр савыты») — Казан, 1902; «Хәләби тәрҗемәсе: Бабатагый» — Казан, 1891; «Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе» («Гыйлем чишмәсе») — Казан, 1902; «Тәзкийрен-насин, фазаил йасин» («Ир булу, йасинның гыйлемнәре») — Казан, 1894 һәм башка шәригать китапларына мөрәҗәгать итсеннәр, шуннан канәгатьлек табарлар. Асылда бу язма да шуларны өйрәнү нигезендә төзелде, алар «буена» үлчәнеп язылды.*

*Монда язылган йола һәм әдәп кагыйдәләре һәммәбезгә дөрес яшәү юлында ярдәмчеллек итсен. Дөньяларны бар кылган һәм безгә бөек Коръәнне бүләк иткән Аллаһы тәгаләгә мактау догаларыбыз ирешсен!*

## ДӨНЬЯГА КИЛҮ

*Хәбәр.* Барлык мөселман кардәшләр белсен ки, адәм балалары дөньяга җәбер-золым вә кимсенүләр күрү өчен түгел, бәлки җаннарын тән калыбында тәрбия кылырга һәм дә, Ахирәт тормышына ирешеп, Кыямәт көнен күреп, җәннәткә лаеклы булу өчен туалар. Яман кемсәнәләрнең тәмуг чокырына иңдерелеп, Сират күперен кичә алмыйча, гөнаһлары авырлыгыннан янар диңгезләргә егылып төшүе — үзләре сайлаган юл булганлыктан, бары тик кызгануга гына мохтаҗлар. Яшәеш аша начарлык белән үтүдән булдыра алган кадәрле һәркем сакланырга бурычлы. Моның өчен сөннәттән, ягъни шәригать өйрәткән гореф-гадәтләрдән тайпылмаска тырышу гына кирәк.

*Кагыйдә.* Бала — хөрмәт җимеше. Ир белән хатын никахлы булганда гына үзара җенси якынлык сөннәт санала. Башкалар өчен мондый эш — хәрәм вә зина. Әмма ир белән хатын арасында бер-берсен куркыту белән якынлык кылышу дөрес эшләрдән түгел. Чөнки, әгәр дә ир үз хатынын куркыту белән ала, ягъни аңа якынлык кыла икән, хатынына хәвеф төшә. Мондый хәвеф вә куркулык белән ана корсагына ирешкән ата орлыгыннан яралган бала, ни хикмәт, дивана вә акыл ягыннан зәгыйфьлек дәрәҗәсендә дөньяга киләчәк. Шуңа күрә үзен мөселман дип санаган ир бервакытта да, хәтта, ни гөнаһ, зина кыла калса да, хатын-кызны куркыту белән яулап алмаска тиеш.

*Мөгамәлә.* Яхшы ир үзенең буйга узган хатынын ялгыз калдырмас, аны борчырга тырышмас вә хурлыктан, вә авырлыктан, вә ачлыктан, һәм дә явызлыктан саклар. Карындагы баланың кызмы-малаймы булуына да фараз кылу килешә торган эш түгел. Аллаһы тәгалә аның җенесен үзе генә белер, кирәксә, үзе белдертер. Гавам арасында шундый иркә бәндәләр бар ки, Хак тәгалә әмере белән алар күз карашы аша вә хатынның буй-сыныннан корсактагы баланың җенесен билгеләрләр.

Үзен мөселман дип санаган һәрбер ир бәгырь кисәге баласын хатыны эчендә ядкарь булып сак-

ланган вакытында ук иркәләргә уйласа, сак кылансын һәм: «Мөхәммәтем» — дип әйтсен. Бу сүзенең хикмәте зур булыр. Бу исемгә бары тик өммәтләр генә лаек. Кяферләр аннан мәхрүм. «Мөхәммәт» дип эндәшүе баланың пакь мөселман өммәтеннән булуына сөенеч сүзе булыр.

Китапларда әйтер ки, мәсәлән Кудури вә Хәләби кебек шәригать белгечләреннән калган нөсхәләрдә, «Мөхәммәтем» дип иркәләнгән бала ир җенесеннән булыр.

Әмма Хак тәгалә үзенең сөекле бәндәләренә кыз баланы бирүне өстенрәк күрә һәм шул рәвешле күркәм ир вә күркәм хатынның беренче ядкаре дә кыз бала, диләр. Шунлыктан, кыз баланы тапкан хатын — бәхетле, ире — сөекле ир.

*Нәсыйхәт булып килгән сүзләр.* Үзен мөселман дип йөргән иргә, хатынының «буе» калыная-кабара барган саен, аңа карата саграк вә игътибарлырак булу тиешле эш. Инде якынлыктан саклан. Баланы карында чагында ук кимсетмә. Юкса, хәтере калыр, тыңлаусыз булып үсәр, картлыгыңда үзеңне кимсетер.

*Урын-җир кагыйдәсе.* Буйга узган вә көне якынлашып килгән хатын өчен ятак урыны чиста вә пакь, һавасы — саф, түшәге — йомшак кирәк. Ефәк, атлас кебек тукымаларны файдалану ярый торган вә хөрмәтле эш түгел.

Бала тудыручы хатынның урыны ак җәймә белән яман күздән әйләндереп алыныр. Әйтерләр ки, ул җәймәнең югары башыннан ак күгәрчен кыяфәтендәге ике фәрештә тотып торырлар, күзгә күренмәсләр, шайтан вә җен кебек затларны кертмәсләр. Кендекче әби (ягъни акушерка) баланы кабул итү хәстәрен күрер һәм үз эшен башкарыр.

*Мөнәсәбәт.* Яңа туган баласына мөселман ирнең игътибары, яхшы мөнәсәбәте булырга тиеш. Хәдистән беленгәнчә, яңа туган балада җәннәт исе бар, ул — дөньяда нур, Ахирәттә — шатлык! Шуңа күрә ата кеше, үзенең шатлыгын күрсәтеп, ана вә бала янына керер, җәннәт исеннән җанын камиллеккә ирештерер, Ахирәт шатлыгыннан өлеш алыр. Бу — аның хакы, хактан баш чөерү кирәкмәс.

Бала янына килеп кергән ир кеше яңа туган ядкаренә сөенеп карарга тиеш. Ул кызмы, малаймы, икесе дә бәхет. Әмма ир кемсәнә һич тә: «Бу минем балам булмаска кирәк»,—дип яки:—«Миңа бер дә охшамаган»,—дигән килешсез сүзләрне әйтмәсен. Өендә хатыны бала тапкан икән, ул—аның ядкаре.

Ир кеше баладан исән-имин котылган хатынын Аллаһы тәгаләне телгә алып тәбрик итәр һәм аңа пешкән өрек җимешеннән, йә булмаса, кипкән өректән дә ярый, ризык бирер, авызына каптырыр һәм дә баласы янына килеп, уң колагына азан, сул колагына камәт әйтер, җитешкән хөрмә итен саклык белән генә иренenә каптырыр, ризыкландырыр.

Яңа туган бала ак яки сары чүпрәккә—биләүгә төрелер, анасы янына китерелер.

Баласы туганда Мөхәммәд пәйгамбәр:

*Аллаһүммә-әҗгальһү бәрран тәкыййан вә әнбитһү фил-ислами нәбәтан хәсәнан*

Я г ъ н и «И Аллаһы тәгалә, Син аны ата-анасына изгелекле, изге гамәлле, Исламда күркәм сыйфатлы итеп үстер»,—дип әйтә торган булган. Шушындый ук сүзләрне вә теләкләрне баланың ата-анасы вә туу хәбәрен ишеткән барлык мөселманнар да әйтергә бурычлылар.

*Игътибар.* Кайберәүләр сорарлар: «Баланы бишектә үстерергәме, әллә инде арбадамы?»—диярләр. Җавап шул булыр: «Бишектә үскән атаның баласы да бишеккә мохтаҗ!». Әмма дә ләкин бала катылыкка мохтаҗ түгел.

*Баланы имезү.* Баланы туганнан соң иң әүвәл анасы имезер. Әйтерләр ки, балага изгелек сөт имезгән анасыннан керә. Шуңа күрә сөт имезү ана кеше өчен сөннәт санала. Әнкәсе сөтеннән мәхрүм калган баланың тәне-бәдәне дә төрле авыруларга дучар була.

Әгәр әнисенең сөте булмый икән, баланы бербер сөт анасына имчәкләндерү дә дөрес, анысы да сөннәт. Бары тик дивана яки сәер хатынга гына бирергә ярамый. Ул күркәм холык вә асыл акыл иясе булганда бик яхшы. Чөнки сөт белән балага

ул хатынның сыйфатлары ияргә мөмкин. Шуңа күрә дә шәригать буенча сөт карендәшләр вә сөт анасы туганнар дәрәҗәсендә күреләләр. Туганнарга өйләнергә ярамаган кебек, сөт карендәшләргә дә өйләнешү тыела. Хәтта сөт анасының ире дә балага ата санала.

«Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс!» — дигән әйтем дә шуннан калган, ягъни ана сөте туклану ризыгы гына түгел, ул нәсел төшенчәсенә дә килеп тоташа. Кан кебек үк, сөт тә баланың киләчәгендә әһәмиятле урын тота, чөнки сөт ул — ана имчәгендә ризыкка әверелгән кан да, ягъни канның ризык рәвеше дә әле. Шуның өчен баланы чит кулга бирүдән, имчәктән аерудан бик сакланырга кирәк.

*Ир өчен хәбәр.* Бала имезүче хатынга якынлык кылырга ярамый. Баланың сау-сәламәт булу өчен ризыгыннан киселмәве шарт. Әгәр дә ир үзенең хатынына якынлык кыла икән, димәк балага узуы мөмкин. Ә ул очракта ананың сөте үзгәрә һәм сабыена зыян китерә. Әмма буйдан котылган хатыннарда билгеле бер көннәр дәвамында балага узмаучылык галәмәте күренә. Ул вакытта якынлык рөхсәт ителә. Шулай ук, әгәр дә хатыны яңадан корсаклы булмаслык рәвештә якынлык мөмкин икән, якынлыкка тыелу таләп ителми.

*Игътибар*. Хатыннары һәм ирләре киңәш сорарлар: «Балабыз кычкырып елый, бу бер тыелган вә сөннәткә каршылыклы эш түгелме?» — дип. Тынычлансыннар. Еламыйча гына бала үсмәс. Чөнки сабыйның елавы — Алланы искә төшерүе һәм дә: *Лә иләһә иллал-лаһ* ягъни «Алладан башка илаһи зат юк!» — дип тәһлил әйтүе, Хак тәгаләне мактавы вә аңа багышлап дога чыгуы, ата-анасы өчен ярлыкау үтенүе генә. Шулай да баланы юатусыз калдыру килешми. Чиксез доганың артык булуы кебек, туктаусыз елауның да рәхәте юк.

*Хәбәр*. Әйтерләр, мөселманнарның балалары, тугач, дүрт ай буе: «Лә иләһә иллал-лаһ» — дип, аннан соң дүрт ай буе: «Мөхәммәдәр-рәсүлүллаһ» — дип, тагын дүрт ай: «И Аллаһы тәгалә, мине һәм ата-анамны ярлыка!» — дип елар.

## БӘБИ ТУЕ

*Кагыйдә*. Бәби туе бала туганнан соң җиденче көн җиткәч, кай очракта (мәсәлән, анадан ятим калганда) ундүртенче көнне үткәрелә. Моның өчен, хәдисләрдән күренгәнчә, гакыйка корбаны, ягъни бала туганнан соң бугазланыла торган куй-сарык тиешле вә сөннәт санала.

*Хәбәр*. Сабыйның тууы шатлыгыннан чалына торган сарык, әгәр дә ир бала дөньяга килгән булса, икене, әгәр дә кыз бала икән, берне ниятләү дөрес. Атаның хәленчә, алар симез һәм яхшы ризыкланган булсалар, корбан күркәм исәпләнә.

Гакыйка корбаны бала туганнан соң җиденче көн алдыннан, исем кушканга кадәр җирегә җиткерелергә тиешле. Куй-сарыкны чалганда яки, аңа оста кеше булмаса, соңыннан мулла шушы хөтбәне укыр:

*Аллаһүммә һәзиһи гакыйкату фүлән дәмүһә бидәмиһи вә ләхмүһә биләхмиһи вә газмүһә бигазмиһи вә җәлдүһә биҗәлдиһи вә шагруһә бишагриһ. Аллаһүммә-әҗгальһә фәдан ли-ибн фүлан минән-нар*

Мәгънәсе: «И Илаһи, бу фәләннең гакыйка корбаны, аның каны бу фәләннең каны бәрабәренә, вә ите фәләннең ите бәрабәренә, вә сөяге фәләннең сөяге бәрабәренә, вә тиресе фәләннең тиресе бәрабәренә, вә төге-йоны фәләннең төге-чәче бәрабәренә, и Илаһи, бу гакыйканы фәләннең улы хисабына уттан йолып алмашу кыл!»

Бу хөтбәне, һич булмаса, татар телендә башкарырга да ярый, баланың исеме кушылмаганлыктан, аның кем булуын һәм атасын күзаллап вә ниятләп әйтү урынлы була. Димәк, хөтбәдә мулла сүзнең кем хакында барганын туры вә хак рәвештә инанып-белеп тора, шушы чын күңелдән әйтелгән сүзе белән гакыйканы Хак тәгалә хозурына ирештерә.

Корбан кылынган малның әгъзалары бер-берсенә катыштырып куелмый, һәр өлеше, ягъни сөягеннән боты, кабыргасы һәм башка өлешләре буыннардан гына аерыла, балта яки пычак чабылып туралмый, бары тик киселеп кенә бүлгәләнелә. Гакыйканың боты бала тудыруда ярдәм иткән әби

(әбиләк) өлеше булып, пешермичә, аңа тапшырыла. Калган өлешләре әгъза-әгъза итеп, аерым-аерым пешерелер һәм дә шулай ук сындырылмас. Аш әзер булуга, йортка кунаклар чакырылыр. Ике күршене ике яктан да һәм туган-тумачаны бер-берсеннән аермыйча дәшәргә кирәк, ашның савабы алар кулында булыр. Сөенечле ата сөенче итеп хәер-садака өләшер, гидай-ярлы вә мескеннәргә гакыйка итеннән һәм ашыннан өлешләрен бирер, әмма, чакырылган кунаклары янына, йортның түренә үк кертү кирәкмәс. Шулай итеп, бәби туена аш мәҗлесе әзер.

*Кагыйдә*. Сабыйның туганнан соң җиденче көнендә чәчен китәрерләр, ягъни алырлар, әмма пәке белән китәрү дөрес түгел, чөнки баланың чәч төкләренә зыян килергә һәм башы таз калырга мөмкин, шунлыктан кайчы белән алу яхшы вә сөннәт санала. Сабыйның чәче теләсә кайсы җиргә ташланылмый, җыеп алына һәм үлчәнелә. Шушы чәч авырлыгы кадәр көмеш акчадан садака бирү дөрес. Артыгы да ярый, киме киңәш ителми. Ә баланың кисеп алынган чәчен, сихердән саклану вә таралып ятуын теләмәү җәһәтеннән чыгып, утка салып яндыру яки җиргә чокыр казып күмү мәслихәт.

*Игътибар*. Җиденче көнендә чәч китәрү — сөннәткә кертү һәм пакьләндерү булып тора, шунлыктан йоланы үтәү мөселман бәндәләргә лаеклы вә хөрмәтле эштән санала. Сабый бала, кыз яки ир булуына карамастан, шул рәвешле беренче тапкыр сөннәтләнер һәм мөселманлыкка лаеклы булыр.

*Пәйгамбәрләрнең сөннәте хакында хәбәр*. Билгеле булсын ки, пәйгамбәрләр ана карынынннан туганда ук кендекләре киселгән һәм җенес тышындагы итләре киселгән, ягъни сөннәтләнгән хәлләрендә дөньяга килделәр. Моның сәбәбен хәдисләрдә гаурәтләрнең күз текәп пәйгамбәрләр җенесенә карамавы өчен Аллаһы тәгалә хикмәте белән шулай эшләнелде дип күрсәтелә.

Адәм балалары арасында җенес әгъзасын сөннәтләү Ибраһим галәйһис-сәламнән үк калган. Сөннәт пакьлек вә сафлык билгесе булганлыктан, мөселманнар өчен тиеш, әмма катгый мәҗбүри түгел.

*Сөннәтче бабайлар хакында.* Халык арасында мондый сүз йөрер, имеш, сөннәтче бабайлар, кул артлары китмәсен өчен, йөзенче сөннәтне үтерерләр, дип. Әмма бу сүз ялган. Билгеле ки, җир йөзенә килгән һәр сабыйга Аллаһы тәгалә тарафыннан тәкъдир вә гомер бирелер. Сабыйның шушы бәхетенә кул сузу — Хак тәгаләгә шәриклек кылу, аның тәкъдирен вә бирмешен бозу була. Әгәр дә сөннәтчеләр бер-бер баланың башына җитә икән, андый картларга Кыямәт көнендә вә Ахирәт дөньясында Аллаһы тәгалә ачулы була һәм аларны һәр сабый исәбеннән меңәр елга тәмуг эчендә калдыра. Ул сөннәт пәкесен йөртүчеләр боларны белә торып, бозу юлына басалар икән, хәрәмгә керәләр һәм кяферлеккә басалар дигән сүз. Әгәр дә инде кулларыннан килми торган эш икән, белдекле булып, аңа тотынмасыннар.

Хәзерге көндә сөннәткә утырту эшен шифаханәләр башкара, шунлыктан, йоланы алар аша үтәү-үтәтү дөресрәк булыр.

## ИСЕМ САЙЛАУ

*Хәбәр.* Ата-ана һәрвакыт үз баласына матур исем кушарга тели, әмма аның четерекле мәсьәлә булуын аңлап җиткерми. Исем сайлауның да үз кагыйдәләре бар.

Татарлар арасында электән ике тармаклы исемнәр кушу гадәте бар, ягъни Әхмәтлатыйп (Әхмәтлатыйф), Зәкиҗан яки Айбулат, Алмагөл һәм башкалар. Әмма шәригать китаплары бу рәвешле атауларны өнәп бетерми һәм, балаларга исем кушканда, мөмкин кадәр бер тармаклы гына итеп куярга өнди, ягъни Әхмәт, Латыйп (Латыйф), Зәки, Җан яки Булат, Алма, Гөл, дип. Боларның беренчеләре — гарәп вә фарсыдан алынганнар, икенчеләре исә — төрки-татардан. Мөселман кешеләргә саф гарәп исемнәрен бирү шәригать буенча дөресрәк санала. Китапларда пәйгамбәрләрнең, сәхабәләрнең исемнәренә багышлап атауны күркәм табалар. Әмма, мәсәлән, Әбу-Бәкер дип кую өнәлми. Чөнки

бу исем ике тармактан тора. Беренчесе — Әбу, икенчесе — Бәкер, ягъни гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «Бәкернең атасы» дигән кушамат килеп чыга. Чынлыкта, туган вакытында гарәпләрдә балага бер исем бирелеп тә, алар үсеп, өйләнгәч, ата кеше булгач, аңа үз исеме белән түгел, бәлки малае исеменә карап, Әбу-Бәкер кебек, ягъни «фәләннең атасы» дигән кушамат тагалар да шулай йөртә бирәләр. Әбу-Бәкернең дә асыл исеме башкача яңгырый — «Габдулла». Ә малае исә, Габдулла улы Бәкер диелә, ягъни, әгәр гарәп рәвешендә әйтсәк, Бәкер бине Габдулла килеп чыга. Әмма, һәр халык кебек үк, гарәпләр дә сөйләшкәндә исемне алай өч өлешкә бүлүне яратып бетермиләр һәм «Бәкергабдулла» дип кенә кушып җибәрәләр. Шулай итеп, ике сүз кушылып, бер исем барлыкка килә. Гарәпләр үзара сөйләшкәндә Бәкергабдулла диләр икән, димәк алар Габдулла малае Бәкер дигән төшенчәне бу исемдә күз алларында тоталар. Шулай булгач, безнең татарлар арасындагы Әхмәтлатыйф кебек исемнәр дә гарәп колагына Латыйф улы Әхмәт булып ишетелә һәм бу төрле исемнәрне йөртүче кешеләр дә, асылда, үзләренә-үзләре ата вә үзләренә-үзләре бала мәгънәсендә килеп чыгалар. Ә бу исә бернинди кыйблага сыймый һәм дә көлке генә тудыра.

Кыз балаларга исем эзләгәндә дә ата-аналар артыграк кыланып куялар һәм Бибихафизелҗәннәт, Бибигөлҗамал кебек атап куялар. Сүз юк, матур. Әмма, асылына төшенеп карасаң, «Биби» сүзе — фарсыдан кергән һәм «әби» мәгънәсенә туры килә. «Хафиз»да аерым сүз, «сакчы» дигән мәгънәгә ия, «Җәннәт» исә һәркемгә аңлашыла торгандыр. «Җамал» — «чибәр, матур» мәгънәсенә ия. Шулай итеп, «Бибихафизелҗәннәт» исемен әгәр үз телебезгә аударсак, «әби җәннәт сакчысы», ягъни «җәннәт сакчысы әби», «Бибигөлҗамал» — «матур гөл әби» булып чыга һәм без яңа туган кызларыбызга шундый арбалы исемнәр кушып, яшәмәс борын диярлек, аларны «әби»гә чыгарабыз.

Шуңа күрә, исем сайлаучы ата-аналар балаларына катлы-катлы, буынлы-буынлы озын исемнәр-



7 н 330

не бирүдән саклансыннар иде. Бу — беренче кагыйдә. Икенчедән, мөселман динендәге халыкка Аурупа телләреннән алынган сүзләрне атама итеп файдалану да мактанырлык нәрсә түгел. Бу да көферлек хисабында йөртелә.

Гарәп телендә «кол» мәгънәсендә йөргән «габд» (габид) сүзе бар. Моны исә Аллаһы тәгаләнең атамалары алдыннан файдалану гына мәслихәт күрелә, Габдулла (язылышта: Габд-әл-Алла), ягъни «Алла колы» кебек. Аллаһы тәгаләнең барсы бер йөз дә өч төрле атамасы бар, шуларның берсесе сайланса, китапча була дигән сүз.

Шулай ук пәйгамбәрләрнең исемнәрен кушу да баланы изге кешеләр арасында күрүгә ниятләү кебек аңлашыла, әмма алар янына «габд» кебек сүзне ялгап кую дөрес түгел.

Балаларына исем кушканда ата-аналар шушы кагыйдәләрне исләрендә тотсалар, шәт, бер ялгышусыз матур-матур атамалар белән сабыйларын сөендерерләр, аларны гомер буе үзләреннән-үзләре оялып йөрергә мәҗбүр итмәсләр.

Исемнәр арасында изгерәге — «Мөхәммәт», шулай ук пәйгамбәрләр вә фәрештәләрнең атамалары. Әмма аларны үз балаларыңа кушарга җыенганда, онытмаска кирәк ки, бу исемнәрне йөрткән сабыйларны үскәндә һәм үскәч яман сүз әйтеп ачуланырга, кимсетергә, кыйнарга, башка төрле явызлыкларга дучар итәргә ярамый. Бигрәк тә «Мөхәммәт» исеме мөселманнар өчен бик изге булып тора, шунлыктан, болай аталып йөргән бала аңа лаек булырга тиеш, исемне аклый алмаса, аның өстенә авырлыклар иңәр һәм юлында каршылыклар очрар. «Мөхәммәт» кебек изге исем белән аталып йөргән кеше үзен начар ягы белән күрсәтә икән, аның ояты да чиксез зур була. Шунлыктан, кайбер шәригать китаплары, мәсәлән, «Шәригател-исламия» фәрештәләрнең, пәйгамбәрләрнең, әүлияларның исемнәре белән балаларын атаган кемсәнәләрне бик каты ачулана һәм дөрес эшләмәүләрен хәбәр итә.

Тормышта барлык хәлләрне дә алдан күз алдына китереп бетерү вә күрәзә кылу мөмкин түгел.

Шунлыктан, иң яхшысы, балага тыйнак вә күркәм исем кушу.

*Кагыйдә.* Исем кушканда азан әйтеп, азан догасы укыла. Аннары камәт төшерәсең дә баланың ике як колагына фәлән углы яки фәлән кызы дип исем кушасың.

Аннан соң бу дога укыла:

*Аллаһүммә-әжгальһү фил-ислами нәбәтан хәсәнан вәжгальһү мәсгүдән фид-дөньйа вәл-әхираһ*

Мәгънәсе: «И Раббым! Бу бала Ислам динен куәтләүче, ата-анасына игелекле, миһербан-шәфкатьле, тәүфыйклы зөррият (бала) булсын иде, ата-аналарына тигезлек, саулык, сәламәтлек белән үстерергә насыйп итсәң иде».

## ЙОРТ САЛУ

*Хәбәр.* Әгәр дә берәр кеше гаиләсе өчен йорт салырга уйлаган икән, бу вакытта ул, иң элек, ниятләп эшкә керешергә тиеш, ягъни Аллаһы тәгаләнең исемен телгә алып, йорт төзүенең салкыннан вә эсселектән саклану өчен икәнлеген белдереп куяр. Кеше башына алты аршыннан исәпләп салынган яки аннан кимрәк булган бина, шәригать буенча, сөннәт санала. Артыкка өмет тоту бер дә килешә торган эшләрдән түгел. Шулай сөйләнелә ки, әгәр берәү шушы алты аршыннан күпкә арттырып йортын төзесә һәм амбар кебек киң вә зур өйдә ялгызы гына гомер кичерсә, Кыямәт көнендә ул бәндәгә авырлык килер.

Ибраһим һәм аның улы Исмәгыйль пәйгамбәрләр Кәгъбәне бина кылып күтәргәндә көн саен бер рәт таш сала торган булганнар, шулай итеп, акрынлык белән бөек мәсҗид хасил булган. Шуннан чыгып, шәригать китаплары да йорт салырга керешкән кешегә, әгәр дә ул таштан яки кирпечтән кора икән, көнгә бер рәттән артыгын салырга киңәш итмиләр һәм, шулай ук, агач белән эш иткәндә дә дүрт якка бер бүрәнә салуны мәслихәт дип күрсәтәләр. Әмма болай эшләү вакытны сузу өчен

булмыйча, киресенчә, яхшылап җиткерү бәрабәренә булырга тиешле. Бураны бурау, аны киптерү, йортны җиткерү шактый олы вә мәшәкатьле эш булганлыктан, аларның барчасы бергә күп вакыт сарыф итүне сорыйлар. Шулай булгач, әзер бураны бер көндә мүкләп күтәреп кую, татар вә өммәт йоласына туры килә һәм бу очракта пәйгамбәрләрдән калган йола бозыла дип әйтергә һичбер урын калдырылмый.

*Беренче кагыйдә.* Йортны эшләгәндә, алдан ук таза вә чиста урынны хәзерләп куярга вә ниятләргә кирәк.

*Икенче кагыйдә.* Йортны төзеп бетергәч, күп кешеләр аның диварларын һәм кыекларын бизәргә тотыналар. Бизәк төшерү — йортка күркәм күлмәк кидерү белән бер. Кайбер шәригать китаплары йорт диварында һичбер сурәт булмаска тиеш дип белдерәләр. Сурәт вә җан иясенең рәсемнәре дә диварда вә кыекта, вә башка бизәлмеш урыннарда булырга мөмкин. Әмма алар табигый хайваннарның вә башкаларның үз зурлыкларында гына булмасыннар. Иң яхшысы, йортның кыекларын вә диварларын матур итәсегез килсә, җан иясе булмаган әйберләрнең рәсемнәрен төшерү дә җитәр. Тагын да яхшырагы — төрле ысуллар белән сырлап һәм төрле төсләр белән буяп бизәкләсәң. Чөнки, әйтерләр ки, сурәт төшерелгән йорт эченә фәрештәләр кермәсләр вә, аларга сыенып, күңелләренә ял ала алмаслар. Чөнки сурәт, беренчедән, җан сораса, икенчедән, фәрештәләрнең канатларын кисә, аларны тарлый.

*Өченче кагыйдә.* Мөселман бәндәсе, әгәр үзен сөннәт дип саный икән, йорт тирәсен һәрвакыт шакшылыктан вә чүпләрдән җыештырып, сафландырып торсын. Кешенең чисталыгы намусында, тәнендә вә йортында икәнен онытмасын.

*Дүртенче кагыйдә.* Хак мөселман йорт эчендә, ягъни өендә эт тотмас. Мал карый торган, ау аулый торган, каравыл этләрен өй эченә кертә ала. Әмма алар белән бик сак булырга һәм, иң яхшысы, бу хайваннарны ишек төбендә торырга ияләндерергә кирәк. Башка йорт хайваннарын өй эчен-

дә тотарга рөхсәт ителә, ләкин алар өчен ихата ясалып, үз сарайларында вә лапас кебек бина кылынган махсус урында яшәтүләре һәм туклandырулары сөннәт санала.

*Бишенче кагыйдә.* Йорт белән торган һәр гаиләдә тәһарәт вә йомыш өчен дип төзелгән урын булуы да шарт. Бу җир һәрвакыт чиста вә җилләтелгән хәлдә торганда әйбәт.

*Йола буенча йорт эчен тоту.* Билгеле булсын, өй эчендә суык көннәрне җылы торырга, җылы көннәрне җиңелчә һава сакланырга тиешле. Моның өчен кыш көннәре ягып җылыту, җәй көннәре идәннәрен юып чыгару мәслихәт. Шулай итеп, йортның бүлмәләре бердәй чиста вә җыештырылган, кирәктә җылытылган булуы шарт. Татар авылларында диварларга зур келәмнәр вә бизәкле чүпрәкләр эләргә яраталар. Бары тик хайван сурәтләрен генә эләргә киңәш ителми. Шулай ук кеше сурәтләренә дә бик сак булырга кирәк. Дивардагы рәсемнәргә озак карап тору яки тел белән сүз әйтеп, үтенеч кылып, алар белән сөйләшеп алу да гөнаһ санала. Шуның өчен, иң дөресе, диварда шәмаил, чәчәкле чигеш, аккош кебек күркәм кошлар төшерелгән келәм кебек әйберләрне генә эләргә кирәк. Чөнки алар өйне тиз суынудан яки кискен эсселәнүдән саклыйлар һәм диварларны бизиләр. Әмма, һава сафлыгы өчен, ул әсбабларны вакыт-вакыт тузаннан арындырып яки юып торырга кирәк.

*Йортка ишектән керү тәртибе.* Иң беренче, һич вакытта да тупсага басып үтәргә ярамый, атлап керергә кирәк. Уң аякны алдан йөртү күркәм санала.

Икенчедән, өйгә керүгә, әгәр дә анда гаилә таифәсе һәм башкалар булса, сәлам биреп исәнләшергә кирәк. Сәламләп, Аллаһы тәгаләне телгә алып тупса аша үтү йортка бәрәкәт вә сөенеч китерә вә байлыкларын арттыра. Моны ташлаган кешегә гөнаһ вә авырлык төшә. Инде дә өй эчендә бер генә кеше дә юк икән, ул вакытта «Колһуаллаһ» сүрәсен бер яки өч мәртәбә уку мәслихәт вә сөннәт күрелә.

*Кунак йорты яки кунак бүлмәсе.* Шәригать буенча, һәрбер өйдә кунак бүлмәсе, йә булмаса, баерак кемсәнә икән, кунак йорты булдыру сөннәт санала.

Йортның зәкәте — кунак бүлмәсе, диләр. Ул чиста вә пөхтәлектә булсын.

*Өйдә йоклау*. Өй эчендә төнлә ялгызың гына калсаң, иптәшсез йокларга яту киңәш ителми. Шулай ук түбәсе булмаган, ишеге куелмаган һәм бигенә эленмәгән өйдә дә кич уздыру дөрес эшләрдән түгел.

Кичкә кергәч тә, өйнең тәрәзәләренә эленгән пәрдәләрне төшерергә кирәк. Ул пәрдәләрдә хайван рәсемнәре булмавы шарт. Шулай ук ишек өстенә куелган япма киезне дә каплау сорала. Ятар алдыннан ишек келәгә эленә, утлар сүндерелә. Төнлә ут һәм майлы чүпрәк калдыру мөселман кешеләр өчен киңәш ителми. Шулай ук, әгәр дә ул вакытта урамда авазлар һәм тавыш ишетелсә, өммәтләргә ул өнгә алданып чыгарга киңәш ителми.

*Яшәү*. Мөселманнар кяфер кемсәнәләр вә мәҗүсиләр белән бер йортта яшәүдән саклансыннар. Чөнки андый өммәтләрдән якыннары вә кардәшләре саналган Ислам динле иманлы бәндәләр бизәчәкләр. Шуңа күрә элекке вакытларда мөселманнар мәҗүсиләрнең йортын вә кяферләрнең өен ташлап чыга торган булганнар. Бу очракта алар хакында «азат ителделәр» яки «азат булдылар» дип әйтәләр. Шулай итеп, йорт эчендә мөселманнар белән кяферләргә йә мәҗүсиләргә катнашып яшәргә киңәш ителми.

Сөннәт буенча йорт салу вә өй белән тору кагыйдәләре менә шушылардан гыйбарәт. Болардан тыш, өйдә Коръән укыту, аш уздыру, ятимә әбиләрне кунак итү, мөнәҗәтләр вә бәетләр әйттереп хозурлану кебек күркәм гадәтләр дә бар. Боларны уздыруда китап буенча аерым күрсәтелгән тәртипләр булмаса да, әмма мондый зур эшләрнең күп саваплы икәнлеген генә күрсәтеп үтәргә мөмкин.

## УРАМДА ЙӨРҮ

*Кагыйдә*. Йортыннан урамга чыккан вакытта өммәтел-мөслим Аллаһы тәгалә исемен теленә алсын һәм:

*Бисмилләһи вә тәвәккәлтү галәллаһ вә лә хәүлә вә лә кувәтә иллә билләһил-галиил-газыйм*

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгаләнең исеме белән чыктым һәм тапшырдым Аллаһы тәгаләгә, аннан башка куәт иясе юк, барлык кимчелекләрдән азат булган бөек Аллаһы тәгаләнең ярдәме белән генә»,— дип чын күңелдән ышану белән әйтсен, тагын да «Аятел-көрси»не укысын.

Боларны эшләү ул кешене ялгыш юлдан коткарыр, адашкан вә адаштыручы сукмакка кертмәс, ялгышлардан, гөнаһтан саклар, уңышлар китерер.

Өммәт бәндәсе урамда йөргән вакытында тиз атлап, уртача ашыгулык белән барса, дөрес була. Әмма башны текә итеп кую, муенга утырту, акрын гына кыймылдау — болар барысы да һавалык галәмәте булганлыктан, бераз гына алга таба авышып атлау мәслихәт күрелә. Өлкәннәргә кулга таяк тотып йөрү яхшы.

Мөселман бәндәсе хатын-кызларның юлын бүлмәскә, аларга аркылыдан атламаска, ике хатын уртасыннан үтмәскә тиеш. Сәлам биргәндә, аны кайтару шарт. Әмма мәчеткә барган җирендә дензез адәмгә сәлам бирмәсен. Чөнки бу сәламе өммәтнең тәһарәтен сындырыр.

Урамда тукталып сүз сөйләшү — бу да, әгәр озакка сузылырдай икән, мактаулы эш түгел. Шуңа күрә мөселман бәндәсе үз эшен вә максатын күз алдыннан чыгармаска тиеш.

Урамда йөргән вакытта какырудан вә төкерүдән бик сак булырга кирәк. Мөмкин кадәр андый начар гадәтеңне башкаларга күрсәтмәскә тырышылсын. Әгәр дә инде тыелу мөмкин түгел икән, ул вакытта башкалар каршына, шулай ук артыңа, уң ягыңа төкерүдән тыелырга кирәк. Әмма сул тарафыңа, ике аяк арасына төкерү һәм аны аяк очы белән генә туфракка сеңдерү мәслихәт.

Әгәр дә юлыңа адашкан вә гаҗизлеккә төшкән бәндә очрый икән, аны дөрес юлга чыгару, өйрәтеп җибәрү, ярдәм итү — бу хак мөселманлыкның күркәм гадәтләреннән санала. Кешегә, кем булуына карамастан, караңгы чырай күрсәтү, ярдәменнән мәхрүм итү — гөнаһ эш.

Мөселманның каршысына әгәр дә сукыр берәү очрый икән, аны калдырып китү оятка тиң. Шуңа күрә уң кулың белән аның сул кулыннан тотарга, үз юлына илтергә кирәк. Әйтерләр, сукырны җитәкләгән мөселманның һәр адымы саен бер теләк кабул булыр. Әмма максатың теләккә ирешү генә булса, үтенечеңнең юлы киселер һәм дә тыелу яхшырак булыр.

Иманлы кешегә, әгәр дә аның эше сәүдә булмаса, базарда озаклап йөрү, бушка утыру, бәхәсләшеп-кычкырышып тору бер дә килешә торган эшләрдән түгел. Шуңа күрә, әгәр дә юлы базар аша үтә икән, тиз генә йомышын башкарыр, юлын дәвам итәр яки игътибарсыз үтәр. Базар хакларына күз йому — дөрес. Ялганчының гөнаһ авырлыгы үзенә төшәр, базар шартларын шәригать юлы күрсәтер. Моны сәүдәгәрләр белә дип уйлыйм.

Мөселман кешегә авыз тутырып дин дошманын орышу яки аңа кимсетеп карау бер дә ярый торган эш түгел, киресенчә, аларның аңнары сукыр булганы өчен уфтанса һәм дә кызганса, яхшырак вә өммәтчә була.

Әгәр дә кяфер яисә мәҗүси берәү белән дөнья эшләре бар икән, ул вакытта аны күрмичә үтүе бер дә яхшы түгел. Шунлыктан, андыйлар белән сәлам алышу тәһарәтне бозмаска да мөмкин, чөнки шәригатьнең асылы — кешене урынсыз үпкәләтмәүдә, рәнҗетмәүдә, игътибарсыз калдырмауда.

Сәлам бирү — мөселманлыкны таратуга хезмәт итүче күркәм сыйфатларның берсе булуы хакында шәригать китапларында күп языла. Шунлыктан, үзен өммәт дип санаган кемсәнәләр, әгәр дә инде ул көндә хәтта берничә тапкыр күрешкән булсалар да, тагын да сәлам алышырга бурычлылар. Сәламнең бер вакытта да артыгы һәм киме юк, моны һәркем белсен.

Әгәр дә берәүләр җыелышып торалар икән, алар белән барысы да ишетерлек итеп кычкырып исәнләшергә кирәк, хәтта колакка катырак булган картрак кешеләр дә ишетсеннәр. Сәламне кире кайтарулары аларның үзләре өчен зур савап эш булганлыктан, алар кабул итми калмаслар. Әгәр дә

инде игътибарсыз калдыралар икән, саваптан мәхрүм булырлар, синең гаебең юк дип бел.

Юлдан барганда хатын-кызларга да сәлам бирергә туры килер. Алар туган-тумачаңнан, дус-карендәшеңнән дә булырга мөмкиннәр. Аларның сәламен алу һәм сәламне кайтару бу очракта сөннәт санала. Шулай итеп, олы вә кечеләргә сәламеңне бирергә һичбер вакыт онытма.

Синең юлың, и мөселман, бер йортка эш белән китерсә һәм син, анда килеп керүгә, беркемне дә күрмәсәң, барыбер сәламеңне юлларга онытма. Синең ул иминлек хәбәреңне йорттагы фәрештәләр ишетерләр вә сәламеңне кабул итеп, кире кайтарырлар. Шуңа күрә дә кешесе өендә күренми икән, болай дип әйт:

*Әс-сәламү галәйнә вә галә гыйбадил-лаһис-салихин*

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгаләнең саклавы безнең үзебезгә булсын һәм дә Аллаһы тәгаләнең изге колларына булсын!»

Әгәр дә кергән йортта күмәк берничә кеше булса, аларның барчасына бердәй сәлам җиткерү тиешле. Бу очракта ачык итеп:

*Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтул-лаһи вә бәрәкәтүһ*—дип әйтергә һич онытырга ярамый.

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгалә сезнең белән саклаучы булсын вә Аллаһы тәгаләнең рәхмәте ирешсен һәм дә сезгә бәхетләр бирсен!» Мондый да күркәм сүзләр белән хәбәрләшеп күрешү бик куанычлы вә сокландыргыч, шунлыктан иман нуры бәндәләргә иңәр, күңелләреннән кайгылары китәр, өммәтнең нигезләре тагын да төзекләнер, үз күңелең вә җаның хозурланыр.

Бил алышып күрешү, үбешү, кочаклашу, кул артын үптереп исәнләшү өммәт арасында таралган вә саваплы күрелгән эшләрдән саналмыйлар. Бигрәк тә үз хатының булмаган кыз-карендәшләрең, агай-энеләрең, балаларың белән дә болай күрешү сөннәт саналмый. Әмма дә ләкин ерак юлдан кайткан, яки озак күрешмичә торган абый, яки эне, яисә балалар вә хатының белән кочаклашып һәм үбешеп күрешү—аларны якын итүең билгесе. Бары

тик болай сәламләшү алар өчен авырлык вә җәбер булып күренмәсен. Моңа кадәр ул гадәтләрең булмаган икән, моннан соң да аларның булуы кирәк түгел. Маңгайдан үбеп алу — балаларың вә хатының яисә әниең вә әтиең өчен бик җиткән саналыр.

Әгәр дә берәү синең аша дустына, туганына яисә якынына сәлам тапшырган икән, ул вакытта кичекмәстән аны җиткерергә ашык. Чөнки тапшырылган сәлам — изге әманәт кебек. Әманәткә хыянәт — мөселман кеше өчен гөнаһ эшләрнең берсе.

Әйтерләр ки, кешеләр бер-берсенә сәламнәре аша танылырлар. Бәс, шулай булгач, сәламсез, яман кеше булып танылу бер дә мактанырлык эш түгел.

Сәлам җиткергәндә, яшь ягыннан кечерәк кеше — өлкәнгә, җәяүле бәндә — атка утырган адәмгә, басып торганы — утырганга, надан — галим кешегә башлап сәлам бирергә тиеш, бу — сөннәт санала.

## ЮЛГА ЧЫГУ ВӘ СӘФӘР

Шәригать мәгълүматларыннан күренгәнчә, сәфәргә чыгу — мактаулы эшләрнең берсе. Сәламәтлек, мал, ризык вә гыйбрәтле хәлләрдән хәбәрләр алу ягыннан, белем эзләү вә галимнәр белән очрашу өчен сәфәр һәркемгә киңәш ителә. Юлга чыккан кеше үзенең өйдә эшләгән эшләреннән, гадәтләреннән, уңайлыклардан вә тарлыклардан аерылып тора, сагыну вә искә төшерү кебек җан ризыклары белән үзен тәрбияли, күңелен баета. Аллаһы тәгаләгә сыенып, аның барлыгына вә рәхмәтләренә дәлилләр таба.

Әгәр дә бер-бер мөселманның диненә вә үзенә куркыныч яный икән, бу вакытта да аңа сәфәргә чыгу киңәш ителә. Хәтта күчеп китүе дә яхшы санала. Андый өммәтләргә Ибраһим пәйгамбәрнең рухы юлдаш була.

Сәфәргә чыгу өчен мөселманнарга дүшәмбе вә пәнҗешәмбе көннәре ихтыяр кылына. Юлга иртәнге якта кузгалу бәрәкәтле санала. Ай ахырындагы

өч көндә, шулай ук октябрьнең 24 еннән ноябрьнең 22 сенә кадәр юлга чыгу, сәфәр мөселманнар өчен киңәш ителми. Бу вакытларда кияүгә чыгу вә никах та макталмый.

Юлга чыгар алдыннан, ике рәкәгать намаз укыганнан соң, бу доганы әйтергә кирәк:

*Бисмилләһи вә әмәнтү билләһи вә игътасамтү билләһи вә тәвәккәлтү галәллаһ вә лә хәулә вә лә кувәтә иллә билләһил-галиил-газыйм...*

Мәгънәсе: «Аллаһы тәгаләнең исеме белән бу сәфәрне башлыйм, ышандым Аллаһы тәгаләгә, таяндым Аллаһы тәгаләгә, тапшырдым Аллаһы тәгаләгә, Аның әмереннән башка кич җитмәс һәм Аннан да куәтлерәк көч булмас, барлык эшләр Аллаһы тәгаләнең ярдәме белән генә ирешер, и Аллаһы тәгалә, дөреслектә, мин бары тик Сиңа гына сыенам сәфәремнең мәшәкатьләреннән, кайтуның катылыгыннан, өй җәмәгатенең явыз итеп каравыннан. И Аллаһы тәгалә, сәфәрләрнең хуҗасы — Син, хәлифәсе — Син, өй җәмәгатемне вә малымны үзем югында исән-имин кыл, и Аллаһы тәгалә, барыр җирләрне төзек кыл, юлымны җиңел кыл, безләргә динне вә тәкъвалыкны бир. И Аллаһы тәгалә, минем гөнаһларымны ярлыка, тагын да юнәлдер Син мине изгелеккә, кайда гына барсам да, эшләремне игелекле вә изге кыл, йа Ходa!»

Болардан соң, сәфәргә кузгалганчы, берничә сүрә укыр, барчасын да «Бисмилләһ» белән башлар. Туганнары белән күрешүе, юлга чыгуы хакында аларга хәбәр бирүе сөннәт буенча тиешле гадәтләрдән санала. Кардәшләрнең фатихасы вә аларның догасы сәфәрнең авырлыгын җиңеләйтер, изгелеккә китерер. Шуннан соң өй җәмәгатьләренә әманәтләрен тапшырыр, юлга тәмамән әзерләнер.

Сәфәргә чыккан кеше үзе белән энә-җепне, хәнҗәрне, таракны, май өчен шешәне, юыну әйберләрен һәм көн дә кирәк булырга мөмкин булган әсбапларны алырга онытмаска тиеш.

Сәфәргә төшкән кемсәнә атка яки башка әйбергә утырып бара икән, утырган вакытында ук Аллаһы тәгалә исемен әйтеп, «Бисмилләһ» белән менсен. Китапларның хәбәр итүе буенча, әгәр дә сә-

фәрче атка яки башка юл йөрү җайланмасына менгәндә Аллаһы тәгалә исеме белән эшләми икән, ул вакытта аның артыннан шайтан иярер, дип язалар.

Атка атланган вакытында мөсафир дүрт кешене бер атка утыртмаска тиеш, дүртенче кеше мәлгунь була. Шулай ук, ат белән килеп туктагач, ат өстендә килеш утырып торырга һәм шул рәвешендә башкалар белән сөйләшергә киңәш ителми. Туктауга ук аттан сикереп төшәргә тиешле. Ат — сәфәр чарасы, утырып торыр урын түгел. Хайванга менгәч, аны кимсетергә, йөзенә камчы белән сугарга, арган атны куаларга ярамый. Ат башын һәрвакыт аның хуҗасы тотар, хәтта туганыңның хайваны булса да, аның рөхсәтеннән башка ат башын тоту ярамый торган эш.

Юлчыга иптәш итеп изге бәндәләрне сайлау киңәш ителә. Юлга төшүгә, алар, ягъни берничә мөсафир, арадан бер кешене юл әмире итеп сайлап куялар һәм һәрбер эштә аның сүзенә колак салып, кушкан эшләрен башкаралар. Ул юл әмире галимрәк, белемлерәк, акыллырак булырга тиеш. Әгәр дә арада берәүнең аты акрын йөреш белән атлый торган хайваннан булса яки аты артка кала торган икән, ул вакытта юл әмире итеп аны сайлау дөрес санала. Бергә юлаучы кешеләргә бер-берсен ташлау, калдыру һич рөхсәт ителми.

Ризыкланган вакытларында табын ясау вә барсы да бергә утырып ашау таләп ителә. Әгәр дә берсендә ризык затлырак күренсә, аның бурычы — башка иптәшләренә дә аны бүлеп бирү, бергә-бергә туклану. Ялгызың гына качып ашау яман гадәттән санала, сөннәтләргә андый бәндәләргә карата хөрмәтсезлек хисе индерелә һәм бу берәү алардан кимсетелү күрәчәк.

Юлда барган вакытта мөсафирлар бер-берсенә шаян сүзләр сөйләргә, ачык йөз күрсәтергә, көлешергә, үз максатларыннан хәбәрләр бирергә, киңәшләр сорарга тиешлеләр. Әмма үзара ачуланышу һәм берәүне рәнҗетү яки берәүгә рәнҗү, усаллык кылу, караклык кебек эшләр аларда күрелергә тиешле түгел. Шулай ук, әгәр дә кем дә булса

ялгыш сөйли яки юк әйберне таптыра икән, юлдашлар бер-берсенә кычкырып «юк» димәскә кирәк, бәлки йомшак кына итеп җавап кайтару мәслихәт.

Хатын-кыз өчен үзләре генә ялгыз сәфәргә чыгу шәригать тарафыннан киңәш ителми, әгәр дә инде юлга төшәргә туры килә икән, өч көннән дә артыкка китмәскә тиеш. Ире белән бергә яки якын кардәше белән бару гына сөннәт санала.

Мөсафирлар максат куелган шәһәргә яки урынга барып җитсәләр, иң элек бу җирдә үскән ачы ризыктан авыз итәргә бурычлылар, ягъни суган-сарымсак кебек әйбердән ашасыннар. Мөхәммәд пәйгамбәр үз вакытларында ук мөсафирларга вә мөһаҗирләргә шулай эшләүне таләп иткән. Суган вә сарымсакларны ашау юлчыларга бу җирләрнең суын хәвефсез эчәргә һәм авырулардан сакланырга ярдәм итәр.

Мөсафирларга, эшләрен бетергәч, бу шәһәрдә яки илдә озакка калу киңәш ителми. Кире кайтыр алдыннан алар өйдә көтеп торган балаларына, гомумән өй җәмәгатенә бүләк китерсеннәр. Хәтта, әгәр бер генә истәлекле әйбер дә таба алмасалар, бу җирдәге ташны булса да алып кайтсыннар вә бүләк итеп китерсеннәр, дип киңәш итә шәригать китаплары.

Өеннән озакка вә ерак юлга киткән мөсафирга кинәт кенә, белдермичә кайтып керү сөннәт саналмый. Ул, иң элек, хатынына яки өй җәмәгатенә алдан хат беләнме, кеше ашамы үзенең кайсы көнне кайтып җитәчәген хәбәр итәргә бурычлы. Шулай ук төнгә каршы өйгә кайту да киңәш ителми. Иң яхшысы, иртәнге якта яки көннең икенче яртысында кайтып керсә, яхшы санала.

Шәригать таләпләре буенча, мөсафирларга кыңгырау тагып йөрү, ат дугасына кыңгырау элү кебек галәмәтләр киңәш ителми, хәтта мондый кыңгыраулы юлаучыларга иярмәскә, алардан аерылып йөрергә кирәк, диелә. Дини йолалар буенча, кыңгырау тагу — юл уңаен тотучы фәрештәләрне качыра икән.

Юлдан кайткан ир үзенең хатынына кичкә кадәр әзерләнергә мөмкинлек бирсен. Аның белән

якынлыкка ашыкмасын. Торган авылына яки шәһәренә килеп кергән вакытында Аллаһы тәгаләгә рәхмәтләрен ирештерсен вә, Аллаһы тәгаләдән башка илаһи зат булмавын белдереп, иман сүзләрен кабатласын. Әгәр дә каршысына сабый балалары йөгереп килә икән, мөсафир аларны күтәреп, аларга назлы вә татлы сүзләрен әйтсен. Мөхәммәд пәйгамбәр кайсы сәфәрдән генә кайтмасын, әгәр дә каршысына балалары йөгереп килә икән, аларны күтәреп ала һәм үз янында, ат өстендә алып кайта торган булган. Өйгә җитешкәч, мөсафир кеше балалары янында калыр, алар белән уйнар, хәлләреннән хәбәрләрен алыр.

Сәфәрнең хәерле төгәлләнүе өчен һәм икенче тапкыр юлга чыкканда да канәгатьлек белән кайтуына багышлап мөсафир бер олы хайваннан, сарыктан яки башка дүрт аяклы хайваннан корбан чалырга бурычлы. Мөмкин булмаганда кош-корттан корбан китерү дә дөрес. Сәфәренә күрә мөсафир аш та уздыра ала. Туганнарын, күршеләрен чакырып, аларга сәфәр вакыйгаларыннан хәбәр биреп, сөйләшеп, күчтәнәчләре белән хөрмәт күрсәтүе сөннәт санала.

## НИКАХ

*Кагыйдә.* Никах кыз вә егет, хатын һәм ир арасында була, ул аларны зинадан вә хәрәмнән саклый һәм өсләренә олы бурычлар йөкли. Сөннәтнең иң авыры булып никах санала. Тергезелгән никахны саклау, таркатмаска тырышу, үзара тугрылыклы булу—хатын вә ир өстенә бердәй бурыч йөкли.

Өйләнгән вакытында, иң элек, егетнең атасы баласына кемне алуын алдан белеп торырга бурычлы. Туганнары, агасы-энесе дә киңәшләрен бирәләр. Яучы җибәрер алдыннан соратылачак кызның нәсел-нәсәбе вә холкы, әхлаклы вә әдәпле булуы тикшерелер. Матурлык, байлык, чибәрлек кебек сыйфатларга артык әһәмият биреп, чибәр булганы өчен генә кызны алу киңәш ителми, чөнки чибәр

йөзле, яман холыклы хатын ир өчен — бәла, туганнары өчен — газап, халык өчен авырлык булып төшәчәк. Өйләнүче мөселман байлыкта кимрәк, аз сүзле, буйга үзеннән кыскарак, нәселдә түбәнрәк булган кызны алырга тырышса, дөрес санала. Кыз бала да, шулай ук, иргә чыкканда үзеннән күпкә олы булмаган, юмарт, киң күңелле, тәрбияле вә әхлаклы мөселман иргә барырга ризалык бирергә бурычлы.

Никахның асылы байлык эзләү түгел, бәлки тормыш бәхетен табу. Шунлыктан, шәригать таләбе буенча, ир дә, хатын да, үзара никах җебе белән бәйләнгәннән соң, тормышларын мөмкин кадәр бәхетле итү өчен бар тырышлыкларын куярга тиешләр.

Никахка кадәр, шәригать буенча, ир кеше кызга төбәп карамаска, аның серенә төшенмәскә бурычлы. Болар кызны кимсетерләр. Ата кеше кызын сорап килгән кешегә, әгәр дә аны лаеклы тапса, бирүдән баш тартмаска тиеш. Чөнки җитлеккән кызны кияүгә озак тотмыйча тапшыру сөннәт санала. Әгәр дә кызын кияүгә бирмичә тотса, каза төшәр. Кияүле кыз бала ата каршында башкалардан хөрмәтлерәк вә дәрәҗәдә өстенрәк саналыр, һәм ата кеше ул кызын олылар.

Әгәр дә сорап килгән егетнең нәселе яки башка сыйфаты лаеклы табылмаса, яучыны өйдән куып чыгару, кабул итмичә газаплау кебек эшләр күрелергә тиешле түгел. Яучы — илче кебек үк мөхтәрәм вә хөрмәткә лаек кеше. Аның сүзен тыңлау, мөмкин булган сыйны алдына кую шарт. Әмма ашыгулык белән җавап бирелмәс. Шулай ук яучыны кат-кат йөртү дә дөрес эш түгел.

Никахка әгәр дә биш кеше килмәсә, бу никах туе булмыйча, зина туе булыр. Ул биш кеше болардан гыйбарәт, беренчесе — никах хөтбәсен укучы, икенчесе — вәли, якын карендәше, өченче туганы яки атасы. Шаһитларның икесе дә балигъ булган ир затыннан, мөселман булулары шарт. Алар бизәнеп, ясанып килерләр. Кыз үзе дә матур киемнәре белән әзерләнеп торыр. Аларның ак төстәге кием киюләре сөннәт саналыр. Ислемайдан, ялты-

равык әйберләрдән чәчләренә вә өсләренә сибәрләр, үзләрен бик тыйнак тотарлар.

Никах мәҗлесендә кияү кеше, хөтбә укылганнан соң, Аллаһы тәгаләгә рәхмәтен җиткереп, Мөхәммәд пәйгамбәрне мактап һәм үзен шул өммәттән дип күрсәтеп сүзләр әйтүе вә Коръәннән берәр аять укуы кирәк була һәм сөннәт санала. Шулай ук, никах ныклыгы мәһәр, ягъни калым белән билгеле булыр. Мәһәрнең хакы бер сарык бәрәне бәясеннән алып бер сыер бәясенә кадәр дөрес санала яки моннан да артыгракны бирү ярый, әмма бер сарык бәрәне бәясеннән дә киме килешми. Ул-бу вә аңлашылмаучылык булмасын өчен, мәһәрне алдан ук килешеп вә сөйләшеп куялар.

Татарлар арасында мәһәр алу урынына «кыз алу» яки «кыз сату» дип йөртелә торган уен уйналына. Әмма моның асылында да нәкъ менә шушы мәһәр күздә тотылганлыгын күпләр белеп бетермиләр һәм кыз алырга килгән егет үзе дә аның асылын төшенеп җитмичә, хәтта мондый уен булырга тиешлеген дә күз алдында тотмыйча, әзерлексез килә һәм көлкегә дә калгалый. Шунлыктан, өйләнүче егетләр «кыз сатып алу» дигән уенның мәгънәсен белеп торсыннар һәм нигезендә шәригать кануны ятканлыгын төшенсеннәр. Өйләнгәндә мәһәр хакын тулысынча түләү сөннәт санала.

Никах укыр алдыннан кыздан: «Син фәлән кызы фәлән! Фәлән улы фәләнгә хәләл җефетлеккә риза булып бардыңмы?» — дип, егеттән: «Син фәлән улы фәлән! Фәлән кызы фәләнне хәләл җефетлеккә кабул итеп алдыңмы?» — дип соралыр.

Никах мәҗлесе туй белән тәмамланыр. Бу туйга уенчылар чакырту вә күңел ачу оештыру дөрес. Өйләнә торган кеше бар мөмкинлеге белән, хәтта умач пешереп кенә булса да туй үткәрсә, бу сөннәт санала. Туйсыз кыз алуны шәригать килештерми. Туйга якыннарны вә туганнарны, күршеләрне вә дусларны җыйнарга куша. Әмма бу мәҗлестә зина вә яман сүз кебек начар эшләр күрелергә тиеш түгел. Чакырылган кунаклар — тыйнаклык белән, хуҗалар — мәртәбә белән мәҗлесне алып барырга тиешләр.

Туй үткәрү буенча һәр төбәкнең үзләренә күрә күркәм йолалары бар. Хәтта янәшә генә торган авылларда да үзләренчә вә үз тәртипләре белән мәҗлес үткәрелә. Шәригать бу яктан туйларны чикләми, хәтта аш-суның да үзенчәлекләре булганлыктан, бәйрәмнәрнең дә үз төсләре бар. Әмма ярәшкән ярлар алдан ук бер-берсе белән туйның шартлары вә йолалары хакында сүз беркетеп, сөйләшеп куярга һәм тәртипләрен дөрес күзалларга тиешләр, юкса, бер-берсен аңламау вә теге яки бу уенны кабул итеп бетермәү кебек авырлыклар кунаклар вә хуҗалар өстенә төшмәсен, җайсызлыклар булыр. Туй мәҗлесе яшьләр өчен гомерләрендә бер генә үткәрелә, иң яхшысы, алдан барсын да сөйләшеп һәм белешеп куярга кирәк. Монсыз туй җыю вә үткәрү сөннәт саналмый вә мәҗлеснең савабы яшьләргә килеп ирешми.

Кыз белән егетнең беренче кичәсе кай якларда туйга кадәр, никахтан соң, икенче җирләрдә исә, туйдан соң уза. Ничек кенә булса да, бу кичә бары тик никахтан соң булырга тиеш һәм аның да шәригать таләп иткән тәртипләре бар. Аларны яхшы белергә кирәк. Вакыйга болай булсын.

Кияү керер алдыннан кыз чәчен тарар, бизәнер вә зиннәтләнер, ислемай ягыныр, сөрмә тартыр, кулларын кына белән буяр. Алар икесе дә ике кат дога чыгарлар. Аннан соң ир үзенең хатыны янына керер, аның маңгай чәченнән учы белән җылы итеп йомшак кына тотар да: «И Аллаһы тәгалә, минем әһелемне бәхетле ит, аны ризыкландыр, мине ризыкландыр, аннан үзара канәгать кыл, безнең арабыз изгелек белән берләшсен; безне бер-беребездән аер, әгәр дә без изгелектән аерылсак. Торсак та, аерылсак та изгелек белән булсын, йа Аллаһы тәгалә»,—дип тыныч тавыш белән әйтер.

Әгәр дә ир үзенең хатынына килә икән, ул: «И Аллаһы тәгалә, Синең исемең белән хәләлләндем, Синең әманәтең белән мин аны алдым. Аның аналыгында бер баланы бар кылсаң, ата-анасына итагатьле, туры юлдан йөрүче мөселман итеп кыл Син аны. Әмма бозыклыкта яшәүче итеп һәм шайтанга тыңдәш кылма!»—дип әйтер вә дога укыр. Әмма

бала сорап уку дөрес түгел, бу ярамый торган эшләрдән санала.

Сөннәт буенча якынлык кылуда чикләүләр юк, үбешү, кочаклашу, сөешү тиешле вә мәхәббәт сыйфатлары булып санала. Якынлыктан соң әгъзаларны чүпрәк белән сөртү таләп ителә. Бу вакытта: «И Аллаһы тәгалә, сакла безне шайтаннан, аның белән балабызны уртак кылма!» — дип үтенү кирәк.

Шәригать таләбе буенча, якынлык кылу алдыннан ир белән хатынга кочаклашып-үбешеп уйнау таләп ителә. Әмма бу уйнау бер-берсен кимсетү һәм бер-берсенә җәбер юллау булырга тиешле түгел. Әгәр дә хатынның күрем вакыты икән, үзара якынлашу шәригать буенча тыелыр. Күрем килү көннәре өчтән алып, биш-алты көн булырга мөмкин. Бу вакытта ирләр гөнаһтан сакланырга, башка хатыннарга игътибар итүдән тыелырга, хәләлләренә хөрмәт күрсәтергә бурычлылар.

Ир үзенең хатынына якынлык кылганда җәбердән тыелып эш итсен. Аның өстенә әтәч кебек сикермәсен. Якынлыклары урын өстендә булыр. Әгәр дә ир хатыннан алда бушана икән, моның зыяны ирнең үзенә вә хатынына килер. Ир бушанып та, хатынының бушануы җитешмәсә, аңа авырлык төшәр һәм мондый хатынга көне буе ялкаулык ирешер, сүлпән вә нурсыз булыр.

Якынлык вакытында аларга күп сөйләшергә ярамый. Юкса аларның балалары телсез булырга яки телләре озак ачылмый торырга мөмкин. Бу вакытта гыйшык вә мәхәббәт сүзләреннән артыгы кирәк булмас, бер-берсенә иркәлек күрсәтү тиешле.

Якынлык вакытында, шулай ук хатынның җенес әгъзаларына карау тыелыр. Чөнки шушыны эшләү аркасында баласы сукыр туарга мөмкин.

Якынлык вакытында ир кеше хатынын үбүдән дә тыелырга тиеш. Бу халәттә үбешү аркасында баласы саңгырау туарга мөмкин. Шулай ук үтәли тоташ карап тормас, чөнки балада акыл китү галәмәте моның аркасында булырга мөмкин.

Якынлык кылышу икесе аулак калганда гына дөрес санала. Сабый бала яки хайван каршында, тулган ай, яңа ай, ярты ай кичәләрендә, хатынның

курыккан вакытларында яки төш күргәненнән соң ир вә хатын якынлыктан сакланырлар. Шәригать буенча якынлыкны күп кылу киңәш ителми, әгәр дә икенче тапкыр ниятләсәләр, юыну соралыр.

Сөннәт әһелләре бу йолаларны үтәүгә тырышлыкларын куярга бурычлылар, зинадан вә шайтанның катышуыннан саклансыннар. Ул вакытта гаилә бәхетләре камил, үзара мөнәсәбәтләре күркәм вә файдалы булыр.

## КҮРШЕЛЕК ҺӘМ КҮРШЕЛӘР БЕЛӘН ТОРУ ХАКЫНДА

«Йорт салудан элек күршеңнең, юлга чыгудан алда юлдашыңның кем булуын кара»,—дигән хәдис бар. Шунлыктан, иң элек кайда һәм кем янына йортыңны корачагыңны белешеп, аның холкын күзәтеп эш башлавың мең өлеш мәслихәт. Кеше бервакытта да ялгызы гына яшәмәс, хәтта дәрвишләр дә башкалардан качып йөрмәсләр. Илдән аерылу—үзеңне ятимлеккә вә ялгызлыкка хөкем итү ул. Ир бәхете—ил белән, хатыннарның—ир белән. Бәс, шулай булгач, үзеңне башкалардан аерып куеп, ялгыз, күршесез генә яшәү бер дә сөннәт эш түгел. Терәлеп торган күршең юк икән, бәхетең дә ким, шатлыгың да тар кылына.

Китапларда күршеләр белән тату тору хакында бик күп хәбәрләр бар. Күрше хакы—Алла хакы булган кебек, күршенең сиңа хөрмәте һәм синең аңа карата эшләгән яхшылыкларың газиз ананың сиңа һәм синең газиз анаңа күрсәткән хөрмәтеңә тиң күрелә. Күршеңне кимсетү—газиз әнкәңне рәнҗетү белән бер дәрәҗәдә түгелме?

Хәдисләрдән күренгәнчә, ике яктан да кырык йорт дәвамында кешеләр бер-берсенә күрше булалар һәм дә хөрмәтләрен үзара тигез бүлеп бирәләр.

Хөрмәтләрнең төрлечә булуы шарт. Иң яхшы күрше бервакытта да, үзе тук булган хәлендә, яндашларын ач килеш йокларга яткырмаска, аларга ризыктан өлеш чыгарырга тиеш. Әгәр дә үзендә

зур туй, яки бәйрәм, яки корбан ашы була калса, күршеләрен читтә калдырмас, аларны чакырып китерер. Бигрәк тә пешкән аштан бүлеп өлеш чыгару — күршеләр өчен саваплы эш.

Әгәр дә берәүдә җимеш бакчасы булып, мул уңыш бирә икән, иң элек күршесенә күчтәнәч итеп кертсә, бу хөрмәтле сөннәт санала һәм Аллаһы тәгаләнең мактавына ирешәчәк. Базарга барып, беренче тапкыр җимеш алып кайта икән, ул вакытта да күршесенә авыз итәрлек кенә булса да бирү мәслихәт күрелә. Әмма аның балаларыннан качырып кертү бер дә дөрес түгел. Барсына да йорт саен таратып йөрү килешми, якыннарына гына бирсә, шул да җиткән. Бигрәк тә күрше балаларын бакчаңда үскән җимешләрдән авыз иттермәү хурлыклы эш. Хәтта балалары вә күршең кяфер булса да, күрше хакын хакларга кирәк.

Яндашың белән орышу, аңа каты итеп кычкыру, караңгы йөз күрсәтү, сәламсез калдыру — болар аеруча гөнаһ эшләрдән саналалар. Әмма аларга артыгы белән ияләшеп китеп, алар юлыннан гына йөрү дә һич мактауга лаек сыйфат түгел.

Күршең авырып китсә, хәлен белешү, вафат булса, җеназасында катнашу, кабер казышу кебек авырлыкларны күтәрешү олуг фарыз эшләрдән саналалар. Гаиләсенә ярдәм итү, садакадан өзмәү дә кирәк.

Әгәр дә күршең юлга чыгып китсә, аның үтенүе-үтенмәвенә дә карамастан, йорт-җиренә күз-колак булып торырга кирәк. Әмма өй кешеләрен кимсетеп, кыерсытып йөрү һич килешми, хәтта алар хезмәткә ялланган гына булсалар да.

Әгәр дә күршең тоз, шырпы, су кебек кирәкле әйберләр һәм ачыткы, оеткы кебек «баш» сорап керә икән, үзеңдә барыннан мөмкин кадәрлесен биреп чыгарырга кирәк. Шулай ук ярдәм үтенеп, көтәчәккә (бурычка) өмет итеп килә икән, бу вакытта да ярдәм кулын сузарга тиешле. Болар барысы да хак мөселман бәндәләре өчен мактаулы эшләр.

Бервакытта да күрше күршенең балаларын кимсетергә тиеш түгел, юкса гөнаһы авыр газаплар

булып өстенә төшәчәк. Ул балаларга киң күңелле вә мөлаем, якты йөз белән игътибар итәргә, башларыннан сыйпарга, чәчләрен алышырга, пычранган булса, битен вә кулын юындырырга кирәк. Әмма дә ләкин аларны кочакка алып иркәләү, үбү кебек галәмәтләрдән тыелу мәслихәт.

Әгәр дә күршең йорт тирәсенә агач утырта икән, моның өчен тавыш чыгарырга һәм аны ботарлауга юл куярга ярамый. Бу—хөрмәтсезлек галәмәте. Шулай ук күршеңнең ихатасына көнчелек күзе белән яки ачу белән дә карарга кирәкми, гөнаһысы була. Иң яхшысы—күршең өчен сөенү, аны мактап телгә алу.

Күршеләр бер-берсенең малларына таяк яки башка әйбер белән сугудан, аларны гарипләндерүдән саклансыннар. Хәтта этенә таш ыргыту да гөнаһ.

Әгәр дә берәү йорт-җирен сатарга җыенса, иң беренче бу хакта күршесенә әйтергә һәм аның алу-алмавы белән кызыксынырга, аңа тәкъдим ясарга тиеш. Ул баш тарткан очракта гына башкаларга сату дөрес санала.

Шулай итеп, шәригать буенча, күршеләрнең хаклары вә бурычлары бик зур. «Күршенеке—Алланыкы» булганлыктан, үзара тату яшәү, өлешләрне бутамау, ярдәмчеллек бар икән, бу ихаталар өстендә фәрештәләр йөрерләр һәм Хак тәгаләдән изгелек нуры төшеп, бәхетләре вә байлыклары камиллеккә ирешер.

## ТӘҮБӘ

Тәүбә—адәм балаларының күңелләрен гөнаһтан сафландыра һәм аларга котылу алып килә. Тәүбә иткән кешеләр Аллаһы тәгаләдән ерак будан кире кайтырлар вә җаннарын нур эченә салып, үзләрендә тынычлык табарлар. Тәүбә—Аллаһы тәгалә каршында бәндәләрнең абруен күтәрер һәм аларга ныклы терәк бирер.

Тәүбә кылучылар Коръәннән «Тәүбү иллаллаһ...» аятен ахырына кадәр укысыннар. Тәүбә ба-

ры тик ышаныч һәм акыл белән аңлап әйтелгәндә генә файдалы була. Тәүбә итү адәм балаларын һәлакәттән саклап кала. Менә шуның өчен дә Коръәндә вә хәдисләрдә һәркемгә тәүбә итәргә әмер бирелгән.

Тәүбә кылуның файдасы адәмиләр өчен шактый күп. Шулардан *иң беренчесе,* тәүбә кылган кешене Аллаһы тәгалә башкаларга караганда якынрак итә, ягъни үзенең дуслары дәрәҗәсендә йөртә. Шунлыктан, һәркем тәүбәдән качмаска, Ходай тәгаләдән ярлыкау үтенергә тиеш вә сөннәт санала. Аллаһы тәгалә күбрәк тәүбә итүчене ярата.

*Икенче файдасы,* адәм балалары тәүбә белән тәүфыйк табалар. Гөнаһ эшләгән кешеләр шакшылык базына төшеп пычранган вә сасыган кебек булалар, шуңа күрә дә алардан башка кемсенәләр читләшерләр, якын килергә теләмәсләр, кылган догаларының ләззәте ирешмәс, үзләре бер-бер богауга бәйләнгән кебек, күңелләрендә авырлык сизәрләр. Намазларының файдасы күренмәс, бәхетсезлекләренең чиге беленмәс, аларны һәрдаим һәлакәт пычагы саклап торыр.

Хәдисләрдән шундый хәбәрләр килә ки, әгәр дә адәм баласы авызыннан ялган сүз чыгарса, аның янында булган ике фәрештә яман исен сизәрләр һәм читкә тайпылырлар, шул рәвешле башка кешеләр дә читләшер. Тәүбә итмичә, алар яңадан моның янына килмәсләр вә үзләренең барлыклары белән аны сөендермәсләр.

Тәүбә — Аллаһы тәгалә тарафыннан бирелгән мөмкинлек вә аның кабул итә торган илаһи бөеклеге ул.

*Өченчедән,* тәүбә итү — гыйбадәтнең ләззәтен күңелләргә сала, гыйбадәт вакытында тәүбә итмәгән кешеләр үзләренең ни өчен Аллаһы тәгалә каршында булуларын аңламаслар вә ниятләрен ачык кыла алмаслар.

*Дүртенчедән,* тәүбәсез гыйбадәт Аллаһы тәгалә тарафыннан кабул ителмәс. Ходай тәгалә каршында адәм баласының гөнаһлары өчен тәүбә кылмыйча намазга тезләнүе — бурычын түләмичә, кичектереп торучы кеше хәле кебек. Шунлыктан бурычлары-

гызны тапшырырга ашыгыгыз, дога вә намазның тәүбәдән башка мәгънәсе күренмәс. Тәүбә иттеңме, син инде үзеңне бу эшләреңнән тый, тыела алмадың икән, икенче юлы тәүбәң кабул буламы-юкмы, билгесез калыр. Тәүбә терәген кыйшайган җаныңа куй!

Аллаһы тәгалә бары тик тәүбәдән узган вә дин хөкемнәренә буйсынмаган кешегә генә үзенең рәхмәт диңгезеннән бер тамчы да шәфкатен ирештерми. Хәдисләрдән күренгәнчә, тәмугта газапланып кычкырган кемсәнәләрнең күбесе тәүбәсез яшәп, тәүбәсез дөньялыктан киткәннәр. Хак тәгалә юлын ташлап, бозыклыкка вә хәрәмгә юл куйганнар. Бу кешеләрне гөнаһ ияләре дип атарлар.

Гөнаһ, мәгълүм ки, *ике* төрле була. Аның беренчесе: Аллаһы тәгалә кушкан вә боерган эшләрдән, ягъни бишвакыт намаздан вә уразадан баш тарту, икенчесе: башка кешеләргә зыян ясау вә аларга карата яманлыклар кылу. Мондый кемсәнәләрнең үтенечләрен вә тәүбәсен Хак тәгалә кабул итәрме-юкмы, Аның иркендә, әмма аларның тәүбә өмет итәрлек хаклары юк. Шулай да Аллаһы тәгаләнең күңеле киң вә иркен, Ул адәм балаларына карата миһербанлы һәм аларны гафу итү өчен һәрвакыт әзер. Бары тик мөселманнар Аның күрсәткән юлыннан язмасыннар гына, ялгышларын аңлап, төзәтергә ашыксыннар. Төзәлүнең иң беренче юлы вә шарты — тәүбә, тәүбәсез бәндә — шайтан ялчысы!

Тәүбә өчен шарт булган халәтләрнең берсе — кылган эш өчен үкенү. Моннан башка кеше үзенең хаталанганлыгын тәгәл вә тулысынча аңлап җиткерә алмый. Үкенү — адәм балаларының үзләреннән генә түгел, бәлки Хак тәгаләнең әмере белән булыр. Шуңа да тәүбәгә җитешкән кемсәнә зыян вә начарлыгын күрсәткән кешесенә килеп, аннан гафу үтенергә бурычлы. Аннан башка тәүбәсе камил түгел вә кабул булмас. Әмма бу кем гафу үтенгән вакытында: «Мин синең алдыңда фәлән-фәлән яманлыклар эшләдем»,— дип әйтмәс, бәлки: «Мине синең каршыңда кылган гөнаһларым өчен гафу итә күр» — дип үтенер, гөнаһ эшләрен санап

күрсәтмәс. Гаебен аңлап килгән кемсәнәне гафу итү-итмәве зыян күргән кешенең үз теләгендә булыр. Әмма мөселманнар бер-берсенә дошманлык утын кабызмаска, бәлки тизрәк сүндерергә тырышканлыктан, гафу итүе тиешле эш булыр. Ул: «Аллаһы тәгалә гафу итсен, мин гафу иттем»,— дип белдерер.

Тәүбә хакы ирешсен өчен, әгәр дә зыян вә яманлык күрсәтүче адәм нәрсәне булса да урлаган, яки алдап алган, яки үзләштергән икән, ул вакытта бу малны иясенә кайтарып бирергә бурычлы. Моның өчен ул шәһәрдән-шәһәргә йөреп аны эзләп тапсын, үзе вафат булган икән, варисларына тапшырсын. Әгәр дә инде табу мөмкин түгел икән, җәмгыять файдасына ул малны бирсен. Үзендә калдырса, тәүбәсе кабул булмас, дога вә намазлары һәм дә күз яшьләрен коюю белән генә дә гөнаһы юылмас. Әгәр дә хәмер эчеп исергән икән, ул вакытта хәләл ширбәттән садака биреп, шулай гөнаһтан котылыр.

Гөнаһтан арыну өчен туры юлга керергә кирәк. Тәүбә генә аз. Хәдисләрдән вә Коръәннән шул билгеле, гөнаһтан котылу вә аны юып ташлау өчен шушы гөнаһыңа бәрабәр яки аннан өстенрәк торырлык яхшылык эшләү тиешле.

Гөнаһ кылган кешеләрнең үзләренә тәүбә ирешеп, ярлыкау өметендә калсалар, алар шул гөнаһларын кылганда кигән киемнәрен саф вә чиста итеп юарлар, аннан пакь тәһарәт вә госел алырлар, аннан соң аулак урында дүрт рәкәгать намаз укырлар, кайнар күз яшьләрен ихластан тәүбә белән агызып, йөзләрен җиргә куярлар, чын күңелдән үкенечле тавыш белән гөнаһларын берәм-берәм санап барырлар, нәфесен тыя алмаганлыклары өчен үз-үзләрен каты итеп орышырлар, аннан соң, ике кулларын югарыга күтәреп, Аллаһы тәгаләгә мактау сүзләрен ирештерерләр. Мөхәммәд пәйгамбәр исеменә атап салават әйтерләр, үзләренә, ата-аналарына һәм барча мөселманнарга атап дога кылырлар.

*Аллаһы тәгаләдән тәүбә ирешү өчен сигез әйбер шарт булыр:*

1. Ярлыкау үтенү;
2. Тәмуг газабыннан курку;
3. Гафу өмет итү;
4. Ике рәкәгать намаз уку;
5. Җитмеш мәртәбә: «Йа Аллаһы тәгалә, истигъфар кыл!» (ягъни гафу ит),—дип әйтү;
6. Йөз мәртәбә: «Сөбханаллаһи вә бихәмдүһи»—дип әйтү;
7. Башкалар алдында белдермичә генә яшерен садака бирү;
8. Бер көн ураза тоту.

Боларны эшләгәндә, Аллаһы тәгаләнең гафу итүе өметлерәк дип санала.

## БӘЛАЛӘРДӘН САКЛАНУ ВӘ АВЫРУЛАРДАН ДӘВА

Шәригать хәбәрләренең аңлатуынча, Аллаһы тәгалә үзенең иң яраткан вә өстен күргән колларына гына бәла җибәрә һәм болардан чыгу юлларын күрсәтә, ачып куя, әмма тәүбәгә вә Аллаһы тәгаләгә сыенганга кадәр ул бәндәләре һаман-һаман кыенлыклар күрәләр, соңыннан гына болардан азат булалар. Мөселман кеше белергә тиеш ки, бу дөньялыкта очраган авырлыклар Ахирәт тормышында көткәннән бик тә җиңелләр.

Хәзрәте Гали сәхабә вә хәзрәте Гайшәдән килгән хәбәрләрдән, шулай ук хәдисләрдән билгеле булганча, Аллаһы тәгалә үзенең сөекле колларыннан гөнаһлары иң аз күренгәннәренә тормышта авырлыклар вә кыенлыклар китерә, алардан арыну өчен каза бирә. Гөнаһлары моннан да артык икән, ул вакытта бу колларына авыру вә хасталык ирештерә, әгәр дә кылган гамәлләре тагын да начар вә олуг гөнаһ икән, ул вакытта мондый кешеләргә авырлыклар вә газаплар үлем якасына җиткәч бирелә, кабердә күрсәтелә, инде дә мәгәр артыгы белән гөнаһлы икәннәр, мондый коллар Сират күперен узган вакытларында туктатылалар вә тәмугка озатылып, шунда газапларны күрәләр. Шунлыктан, адәм баласына әгәр дә бәла ирешкән икән,

аны сабырлык белән каршы алырга һәм Аллаһы тәгаләгә сыенырга, Аннан ярдәм көтәргә вә өметтә булырга, шулай ук доганы ун мәртәбә кабатларга кирәк:

*Хәсбәнәл-лаһү вә нигъмәл-вәкилү нигъмәлмәүлә вә нигъмән-насыйру гуфранәкә раббәнә вә иләйкәл-масыйр*

Әгәр дә берәр кеше авырса, моның Аллаһы тәгаләдән ирешкән каза булуын аңласын һәм савыгу өметендә булсын. Авырмыйча тору — хафалык, моның өчен адәм баласы кайгы йотарга тиеш, чөнки авыру — бәндәләргә тиешле булган җәзадан санала. Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк сәхабәдән килгән хәбәрләрдән күренгәнчә, күзе сукырайган вә колагы саңгырауланган кешеләр бар гөнаһларыннан тәмам гафу ителгән булалар, шунлыктан ул бәндәләргә калган гөнаһкярлар ягымлы булырга вә ярдәмнәреннән ташламаска бурычлылар. Мондый бәндәләр Аллаһы тәгаләнең диндар коллары дәрәҗәсендә торып, аларга садака бирү дөрес булыр.

Әгәр дә берәр сырхау-хасталыкка калган адәм баласы үзенә шифа эзләсә, ул иң элек «Фатиха» сүрәсен укыр, чөнки бу сүрәдә барлык авырулардан дәва яшерелгән булыр, аннан соң «Колһуаллаһ»ны укысын.

Әгәр дә бер бәндәнең теше сызласа, бу теш азау теш булса, аңа үзенең бармагын куйсын һәм әйтсен:

*Вә һуал-ләзи әншаъакүм вә җәгалә ләкүмүсәмга вәл-әбсара вәл-әфәидәтә калыйлән мә тәшкүрүнә* — дип.

Әгәр дә кем дә булса үзендә берәр төрле авыру барлыгын сизенсә, ул кеше уң кулы белән йомшак кына итеп шул урынын сыпырсын, бу сүзләрне әйтеп:

*Бисмилләһи әгузү билләһи вә кодрәтиһи мин шарри-ма әҗидү вә ухазиру* — дип җиде кат укысын.

Коръәндәге сүрәләр адәм баласына килгән барлык авыруларга да шифа булырлар, шуңа күрә мөэминнәргә ул сүрәләрне белү вә өйрәнү фарыз. Болардан тыш аерым-аерым догаларны белүчеләр сихәтлек өчен адәм балаларына ярдәм кулларын сузарлар.

Башы авырткан кешегә кан алдыру, кан бирү сөннәт гадәте санала. Ач тору кебек кан алдыру да адәм баласына файдалы. Әмма шуны онытмаска кирәк, кан алдыру бары тик тук тормышта яшәгән кешеләр өчен генә рөхсәт ителә, каны аз булганнарга исә катгый рәвештә тыела. Кан алдыру бик күп авыруларга дәва санала. Азау теш сызлаганда, күз алды караңгыланганда, баш әйләнгәндә, саташу галәмәте күренгәндә кан алдыру, шәригать хәбәрләреннән күренгәнчә, файда бирә. Шулай ук, кан алдыру хәтерне яхшырта, акылны арттыра, озак йоклаудан арындыра. Канны сишәмбе вә якшәмбе көннәрендә алдыру сөннәт санала.

## АВЫРУЛАРНЫҢ һӘМ ТҮШӘККӘ ЯТКАН КЕШЕЛӘРНЕҢ ХӘЛЕН БЕЛЕШҮ

*Кагыйдә*. Әгәр дә кеше үзен мөселман бәндәсе дип уйлый икән, ул һичбер вакытта авыру кемсәнәне калдырып китмәс һәм аның хәлен белешер. Авыруның хәлен белү — сөннәт санала. Тереләр вә сәламәтләр бер-берсенең бәхете белән нурланырлар һәм рухларын ныгытырлар. Башлап сәлам бирүдә ун савап булса, сәлам кайтаруда бары тик бер савап кына бар.

*Йола*. Авыру кешенең хәлен белешкәндә сүзләрне куышы итеп бизәкләмәскә һәм тормыш рәхәтлекләре хакында җәелеп сөйләшмәскә тиешле. Әмма хатирәләрне яңарту кебек изге эшне эшләү бер дә начарлык саналмый, киресенчә, яхшы истәлекләр белән үзара бер-береңне баету мактаулы вә саваплы хәлләрдән.

Сөннәт иясе буларак, хак мөселман бәндәсе авыруның, көн саен кереп, хәлен белергә тиешле түгел. Ике көнгә бер мәртәбә янына килү яки сорашып белү — дөрес. Йорт эчендә булганнар көн саен авыру туганнары өчен ут йотып торсалар да, алар да ике көнгә бер тапкыр аның урыны янына килсеннәр, утырсыннар һәм тәртип белән хәлен белешсеннәр. Авыруның хәлен белүдән өмметләр-

нең күңелләренә авырлык төшмәс, киресенчә, рәхмәт нурына чумарлар.

*Кагыйдә.* Хәл белергә килгән кеше авыруның аяк очына да, баш артына да, урыны өстенә дә утырмасын. Аның урындыгы авыруның гәүдә тирәсенә туры килергә һәм үзе шунда утырырга тиешле. Авыруның тезе каршына утыру бигрәк тә сөннәт санала.

*Кагыйдә.* Хәл белергә килгән кеше авыруның уңына һәм сулына карамасын, шулай ук йөзенә вә күзенә дә текәлеп тормасын. Һәм дә хаста кешегә карап сөйләшү дөрес санала. Үзенең йөзен чытып, караңгыланып тору да хәл белешүче өчен яхшы түгел.

*Йола.* Авыруның хәлен белергә кергән кеше өсбашына бик яңа булмаган, бераз искерәк, әмма керсез кием киеп килгән булса, бу рәвешле булуы яхшы. Сөйләгән сүзе гаҗәеп кызыклы һәм күңелне хушландырырлык дәрәҗәдә сафлык хасил итсен. Шуңа күрә дә гомереңнең озын булуын, тәнеңнең сәламәтләнүен теләп: «Тиздән барыбызны да тазаруың белән сөендер»,—дигән теләкләр белән чын күңелдән сөйләшү—сөннәт.

Хаста кешенең хәлен сораганда арадан берәү, әгәр дә кергән кешеләр күп булсалар, авыруның башына кулын кую яки кулыннан тоту дөрес. Кәеф белешеп килүче үзе генә килгәндә дә шулай эшләр. Моның сәбәбы үзара күрешүгә бәрабәр булып тора.

Авыру кешенең сиңа үз хәленнән хәбәр бирүе—аның сиңа дога багышлавына тиң санала. Ә хастаның догасы фәрештәләрнең догасы вә салаваты кебек.

Хәл белергә килгән кеше авыру алдында бары тик изге сүзләрне генә әйтергә бурычлы.

*Хикмәт.* Хаста кемсәнә һәм кәефен белергә килгән адәм шуны онытмасыннар, мондый кешеләр арасында булган сөйләшү вә теләкләр вакытында фәрештәләр амин тотып торырлар.

*Дога.* Бер өммәт икенчесенең хәлен белешкәннән соң җиде мәртәбә бу сүзләрне әйтергә тиеш:

*Әсьәлүллаһал-газыймә раббәл-гаршәл-газыйм ән йәшфикә*

Шушы догадан соң, китапларның хәбәреннән күренгәнчә, авыру кешенең хастасына шифаны Аллаһы тәгалә юллар һәм колын мәхрүм калдырмас.

Әмма дә ләкин бу дога үлем түшәгендә яткан кешегә файда бирмәячәк. Бу очракта җиде мәртәбә болай дип укырга кирәк:

*Әгузү билләһи вә кодрәтиһи мин шәрри-ма әҗиду мин шәрри-ма ухазиру*

*Кагыйдәләрдән чыгарма,* ягъни хәл белешергә, хәлен сорарга ярамый торган очраклар. Алар өч төрле булырга мөмкиннәр:

1. Күз авыруы булганда һәм теше авыртканда;
2. Тәненә яман шеш чыкканда;
3. Кеше җиңеләйсә, ягъни аңгыраланса.

*Авырган кешенең сөннәте.* Әгәр дә берәү хасталыкка төшә икән, гореф-гадәт буенча ул кеше тәрбиягә мохтаҗ санала һәм аның башын бәйләү, урын җәеп, шунда яткыру, ялгызын калдырмау тиешле эш күрелә. Хәбәрләрдән аңлашылганча, авыру вә хасталык адәм балаларына гөнаһлары өчен Аллаһы тәгаләдән бирелә. Интегеп-газаплану — шул гөнаһларның авырлыгы һәм аларны ярлыкауны сорау Хак тәгалә өстенә йөкләмә кую хакында сөйли.

*Киңәш.* Авырган кешегә үлемнән куркуы ярый торган эш түгел, әмма үлемне исенә төшерергә ярамый дип белдерү дә дөреслеккә хилафлык китерә. Түшәктә ята торган авыру үлемне уена кертә ала, ләкин адым саен яки хәл белергә кергән кеше саен: «Мин үләрмен инде»,— дигән кебек сөйләнү дә мөселманга хас сыйфат түгел. Үлемнән һичбер вакыт куркырга ярамый. Чөнки болай итеп бу кеше үлемне Аллаһы тәгаләгә тиңдәш кыла. Хак мөселман өммәтләре бары тик Алланың үзеннән генә куркырга һәм Аннан гына ярдәм көтәргә бурычлылар. Аларга шәриклек итү — гөнаһ.

Шул ук вакытта үлемне искә төшермичә тору да яхшы түгел. Адәм баласы үлемнең барлыгын, җанының тәннән аерылачагын хәтереннән бер дә чыгарып ташламаска тиеш. Хәдисләрдән күренгәнчә, үлемне исендә тоткан кешеләрне Аллаһы тәгалә зур ялгышлардан вә гөнаһлардан сакларга тыры-

шыр һәм ярдәмен бирер. Үлемне хәтерендә тоткан кешеләр дин юлында йөрерләр, дәрвиш булырлар.

Хаста түшәгенә яткан кеше Аллаһы тәгаләдән үлем көтә икән, ул вакытта изгелек белән китәргә мөмкинлек бирүен үтенсә, үзенең җан тынычлыгы һәм Кыяматтә күрәчәге өчен уңайлык тудырыр.

Үлем авыр булганлыктан, аны тыныч һәм батырлык белән каршы алу сөннәт эшеннән санала.

## ДӨНЬЯ БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ, ҮЛЕМ, ҖЕНАЗА

Үлем түшәгенә яткан бәндә, тормышы белән саубуллашканчы, иң элек, гомерендә кылган һәм кылырга мөмкин булган барлык гөнаһларыннан Аллаһы тәгалә алдында ярлыкау вә гафу үтенсен. Аннан соң, васыятен белдермичә дөньялыктан китүдән курыксын. Алладан ярлыкау эзләү һәм туган-тумачага, балаларына васыять тапшыру сөннәт эшләреннән саналалар.

Үзенең гомере ахырга якынлашкан кешеләр иң элек васыятьнамә төзергә бурычлылар. Ул аерым языла һәм мондый сүзләр белән башланып китә:

*Һәза мә әуса биһи фүланүн әүса вә һуа йәшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ...* — дип.

Бу сүзләрнең башында иман кәлимәсе торганлыктан, аның ияce мөселман булуны күрсәтеп тора. Васыятьнамәдә шушы кеше Кыямәт көне киләчәгенә һәм анда Аллаһы тәгалә каршында булачакларына ышанычын белдерер, шуның белән васыятен калдырган кешеләрдән үзенең соңгы теләкләрен үтәүне, динен вә иманны ныклы вә тотрыклы, пакь хәлендә саклауны таләп итәр, аның васыятен үтәү исәннәр өчен изге эш булыр.

Васыятьнамә калдырган кеше Кыяматтә Аллаһы тәгалә белән очрашуны өмет итәр һәм җир йөзендә кылган гөнаһларыннан азат булачагын уйлар. Шуның өчен ул васыятьнамәне үз янына алып ятар, кирәк дип тапса, үз кулы белән тапшырыр яки аның кайдалыгы хакында хәбәрләрен бирер. Бу васыятьнамәдә үзенең милкеннән күпме өлеше

дип юлына, кайсысы балаларына, туганнарына икәнен күрсәтер. Татулык һәм үзара хөрмәт таләп итәр. Васыятьнамәне бозу — мөселман кешеләр өчен гөнаһ булганлыктан, барчалар аңа буйсынырлар; аның эчтәлеге яшерелмәс.

Үлем түшәгенә яткан кеше үзенең дөньялыкта уздырган гомерен искә төшереп, анда эшләгән эшләрен барлар. Әгәр дә берәр кешегә яманлыгы тигән булса, гөнаһы күренсә, тәүбәләр үтенер, әмма уздырган көннәрен сагынып еламас вә күңеленә андый дөнья уйларыннан авырлыклар кертмәс. Даим саен Аллаһы тәгаләне искәрер вә аның алдында тотачак җавапларын хәтерендә барлар. Аллаһы тәгаләнең исемен һәрвакыт исендә тотар, аңа мөрәҗәгать итеп, хәерле үлемен теләр, ярлыкаудан өметләнер, дөньядан туйганлыгын һәм җанының тынычлыкка ирешәчәген уйлап, Хак тәгаләгә рәхмәт белән догаларын ирештерер, күңелен Ахирәт тормышына юнәлтер.

Елмаеп, күңелдә ниндидер изге бер шатлык галәмәте сизенеп, күз алдында фәрештәләрнең килгәнен күреп үлү — мөэминнәр өчен изгелек санала. Әгәр дә инде кеше җан чыкканда борын тишекләрен җыера, буылгандагы кебек тамагы тараеп гырылдый, маңгайлары тирләп чыга, күзләреннән кайнар суыклык белән яшьләр килеп үлә икән, бу — хәсрәтле үлем, авыр үлем. Мондый китүдән мөселманнар бик саклансыннар, гөнаһларының күплеге вә авырлыгы — җан чыгу авырлыгы вә газабы белән беленер.

Мөэмин-мөселман өчен кинәттән егылып үлү дә хәсрәт санала, чөнки алдан күрелгән әзерлеге булмау, Аллаһы тәгалә исемен теленә алмау, вәгазь вә васыятьнамәләрен калдырмау, гөнаһлардан ярлыкауны үтенмәү — болар дөнья белән саубуллашкан кеше өчен фарыз булмаганлыктан, кинәттән үлеп китү дә бер авырлык галәмәте санала. Шунлыктан Ислам карендәшләре үзләрен һәм якыннарын мондый үлемнәрдән сакларга тырышырлар вә аларга үзләренең ярдәмнәрен биреп, мәңгелеккә җиңеллек белән китәргә мөмкинлек бирерләр. Бу юлдан чыккан кешеләрне авырлык көтми калмас.

Кеше үлем хәленә кергәч, иң элек, җан бирергә җиңел булсын өчен, аякларын кыйблага таба сузып яткырырлар һәм гәүдәсен уң як җилкәсенәрәк салырлар. Шушы рәвештә булсын өчен баш астына йомшак әйбер куярлар. Җан бирүенә, иң элек күзләрен йомдырырлар, бу вакытта болай дип дога укырга кирәк:

*Бисмилләһи вә галә милләтин рәсүлүл-лаһи аллаһүммә йассир галәйһи әмраһү вә саһһил галәйһи-ма багъдаһү вә әсгыйдһү би-ләкаикә вәҗгальма хараҗа әләйһи хәйран миммә хараҗа ганһ*

Авызы ачылмасын өчен ир-атның иягеннән яулык белән бәйләргә, хатын-кыз булса, яулык бөркәндерергә кирәк.

Кеше үлгән вакытта шәһадәт кәлимәсен, ягъни: *Әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ* — сүзләрен янындагылар авыру ишетерлек итеп кат-кат әйтеп торырга кирәк, әмма җан бирүчедән кабатлауны таләп итмиләр, үз ихтыярында.

Әгәр дә иртәнге якта яки өйләдән соң үлгән булса, күмәр өчен әзерләнә башлыйлар. Шәригать буенча мәетне тизлек белән, ашыктырып күмү дөрес санала. Әгәр дә җаныннан кич белән аерылган икән, ул вакытта икенче көнне иртә белән күмү йоласы башкарыла. Үлем хәбәрен башка мөселманнарга тапшырганда вә кабул итеп алганда:

*Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун* — дип әйтәләр, моны ишеткән һәрбер кешенең кайгыга төшүе саваплы була, алар кабер казу вә җеназага катнашу өчен хәстәрлекләрен күрергә бурычлылар.

Җан биргән кешенең күкрәге кабармасын өчен корсак турысына кылыч, яки хәнҗәр, яисә тимер кисәге куела. Кабык яки тактага салына һәм юу өчен әзерләнелә. Бу такта-кабыкны өч, биш яки җиде тапкыр хуш исле әйбер белән хушландыру бик кирәкле вә хөрмәт билгесе булып тора. Шулай ук мәетне юар өчен дип куелган суны да хуш исле үсемлек яки хушбуй белән хушландыру кирәк.

Билгеле булсын ки, юындырганчы, алдан мәет янында Корьән уку киңәш ителмәс. Әмма кич

кунарга туры килгәндә Коръәннән аятьләр уку тыелмый.

Мәет юу — саваплы эш. Әгәр дә кеше суга төшеп үлгән булса, ул мәетне дә юалар. Әгәр дә үле туган булса, юалар, әмма җеназа укымыйлар. Әгәр тере туып үлгән булса, башта исем кушалар, юалар һәм җеназа укыйлар.

Мәетне юар алдыннан эчке тәһарәтен алдыру өчен — өч кисәк, авыз-борынын чистарту өчен — алты кисәк чүпрәк әзерләп куярга кирәк. Мәетне колашага күтәреп салгач, өстендәге күлмәге аяк очыннан югарыга таба, җиңнәре беләзектән югарыга таба киселә. Күлмәген кисмичә салдырып кына алсаң да була. Мәетнең гаурәте каплап куелырга тиеш.

Мәетне юар алдыннан өч кеше кулларына ак чүпрәк урарлар. Асыл юучы сул кулы белән мәетнең астын чистарту, истинҗа алдыру өчен, мәетнең сул ягында булырга тиеш. Юа торган су кан җылысы кебек булсын.

Әүвәл әзерләнгән өч кисәк чүпрәк илә мәетнең тәһарәтен алдыру кирәк. Мәетнең чәчен сүтеп, башын сабынлап юарлар. Сабын күбеген бетерү өчен алгы ягын кабат юу кирәк.

Мәетнең алгы ягы юылып беткәч, әүвәл сул кабыргасына яткырып, аркалары белән уң ягын сабынлап юалар. Колашаны юып мәетне салгач, уң кабыргасына яткырып, аркалары белән сул ягын юарлар һәм колашаны пакьләп, мәетне салырлар. Мәетне юганда су тимәгән урынын калдырмыйлар.

Нәҗесләре чыксын өчен мәетнең җилкәсен әзрәк күтәреп, эченә басып кую кирәк. Шуннан соң камил тәһарәт алдырырлар:

Уң кулы һәм сул кулы юылыр.

Өч чүпрәк белән авызы юылыр.

Өч чүпрәк белән борыны юылыр.

Өч тапкыр йөзе юылыр.

Терсәкләргә хәтле әүвәл уң беләге, аннан сул беләге су белән коендырылыр.

Мәеткә мәсих кылдырылыр.

Госел коендырганда: «Илаһи! Ният кылдым Ахирәт госелен коендырмакка, тәннәрен пакьлә-



8 Ч.330

мәккә, әшһәдү әл-лә иләһә иллал-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ»,— дип әйтелер.

Мәетнең башын бераз күтәргән хәлдә, баш турысыннан колашаны юып җибәрү кирәк.

Мәет уң як җилкәсеннән дә, сул як җилкәсеннән дә ботына кадәр су белән коендырылыр.

Сул ягына яткырылып, уң як җилкәсеннән аркалары госелләндерелгәч, колашаны юып җибәрү кирәк.

Уң ягына яткырылып, аркалары белән сул як җилкәсеннән госелләндерелгәч, колашаны пакьләп, мәетне салырлар.

Уң аягын һәм сул аягын, бармак араларын аралап, госелләндерелер.

Чәчләре ике якка сузып салындырылыр.

Нәҗесе чыгу ихтималы булса, мамыкны чүпрәккә төреп бөке кую һәм ботын бәйләү кирәк. Кабат нәҗесе чыкса, госел яңадан кайтарылмас. Шул урын гына пакьләнер.

Мәетнең сакалын алу һәм кыру, тырнакларын кисү ярамый. Әгәр дә берәр тырнагы сынган икән, аны кисеп алырга кирәк булыр. Шулай ук мәетнең намаз укый торган урыннарына, ягъни кулларына, тезләренә, йөз-башына хуш исле әйбер сөртәләр. Бу вакытларда өстендә дәстәр дип аталган бөркәнчекне тотып, мәетне яман күздән саклау фарыз санала.

Юылып беткәч, пакь җәймә өстенә салып, мәетне корыталар һәм кәфенлек тегәләр. Ирләрне — ирләр, хатыннарны — хатыннар юарлар, мәеткә туры караудан сакланырлар, мөмкин кадәр йомшаклык вә сабырлык күрсәтерләр. Кәфенләү дә мәет юу кебек үк саваплы эш. Әгәр кәфенлеге булмаса, чиста вә ныклы киемнәреннән тегелә. Кәфен өч кат була, барлык катлар да хуш ис белән хушландырыла. Кәфеннең соңгы ике каты баштан-аяктан ашкан булуы шарт.

Чиста урын өстенә кыеклап әүвәл юрган яки одеял, юрганга тап төшмәсен өчен полиэтилен (клеенка) җәелә.

Гүргә иңдерү өчен төрелгән хәлдә 2,5 м озынлыкта 3 сөлге әзерләп куела.

Билбау бил турысына куела. Аның киңлеге ярты иң булырга тиеш.

Кәфеннең ике каты да җәелә. Аннары яулык калдырыла. Болар өстенә ахирәт күлмәге куела.

Мәет әзер кәфен өстенә сузып салына.

Ахирәт күлмәген тулысынча кәфен өстенә куеп, бер катын бөкли-бөкли баш очына кадәр күтәреп куела, мәетне салгач, күлмәк өстенә төшерелә. Ирләргә чалма сарылыр, хатыннарга пәрдә бөркәлер, имиләре тасма итеп ертылган кәфенлек белән бәйләнер, чәче, ике толым итеп, күкрәгенә салыныр.

Мәетнең авызы ачылмасын өчен иягеннән башына кадәр авызын бәйләп куярлар һәм яулыгын бөркәндерерләр.

Беренче кат кәфеннең әүвәл сул ягы, аннан соң уң ягы ябыла. Битләре дә ябылырга тиеш.

Икенче кат кәфеннең сул ягы вә уң ягы ябыла.

Аннары билбау белән мәетнең аягы очындагы кәфене бәйләнә. Әзерләнгән сөлгеләр мәет өстенә куела һәм юрганы белән төрелә, алып барганда таралмасын өчен аяк ягын бәйләргә кирәк.

Юып-кәфенләнгән мәет башы Мәгъриб тарафына (кояш батышы) каратып җиргә куелыр. Соңыннан имам мәетнең күкрәге турысына, җәмәгать имам артында саф-саф булып тезелгәч, җеназа намазы укыла. Намаз укучы, бер генә кеше булса да, мәетнең күкрәге турысында булмак тиештер.

Җеназа намазының шартлары башка намаз укыгандагы шартлардыр, ләкин җеназа намазына билгеләнгән бер вакыт юктыр, дәхи җеназа намазы өчен мәетнең юылган булуы шарттыр.

Җеназа намазының кыйраәте, рөкүгы һәм сәҗдә кагъдәләре юк. Дүрт тәкбир, ике сәлам илә тәмам кылынадыр.

Шул рәвешчә җеназа намазын уку мөселман булган һәрбер мәет өчен фарыздыр. Кирәк, ир, кирәк, хатын, вә кирәк, сабый бала булсын, әгәр җеназа намазы укылмый күмелсә, ул вакыт каберенә укылыр.

Өйдән чыгарылганда, элек, аягы белән каратып йөртерләр, аннан соң баш ягына әйләндерерләр,

ун адым саен күтәреп баручылар урыннарын алмашырлар, шулай кырык адым үтәрләр. Җеназа күтәреп барганны күргән кешеләр аларга йөз белән карап басарлар, көлмәсләр, көрсенмәсләр. Җеназага ияреп бару саваплы булыр. Хатыннарга килү киңәш ителмәс. Җеназаны күтәреп бару илтүчеләр өчен саваплы санала, ерак ара булганда, арба яки машинага куеп илтерләр.

Кабер казу өчен өч аршин җир алыныр.

Кабер кыйблага аркылы, ягъни бер башын кояш чыгышына вә бер башын кояш батышына каратып, мәетнең буена күрә казылыр. Кыйбла тарафыннан ләхет ачылыр, шул ләхеткә мәет уң тарафы илә, йөзе кыйблага, аяклары кояш чыгышына, башы кояш батышына булганы хәлдә яткырылыр.

Берәүнең кабере бервакытта да дошманы янында, яки үпкәсе калган кемсәнә гүре тирәсендә, яки агай-эне ошатмаган урында булырга тиеш түгел. Һәркемнең нәсел-нәсәбе җирләнгән урыны бар икән, мәетне шунда күмү дөрес. Әмма сөяк өстенә мәет кую дөрес түгел. Чиста урын булуы мәслихәт.

Кабер мөмкин кадәр тирән казылыр, тирәнлекнең зыяны вә ялгышы булмас, әмма мөселман өчен ләхет һичбер вакытта да кабернең урта бер җиреннән алынмас, бәлки яныннан алыныр. Ләхетне уртадан алу, хәдисләрдән күренгәнчә, мөселманнар өчен түгел. Ләхет исә кирпеч яки такта белән бикләнерлек булыр.

Ләхет эченә калын камыш түшәрләр, табут кую, җиренә такта җәю дөрес түгел. Әгәр дә инде ләхете торырлык булмаса, ул вакытта мәетне табутка салып кую рөхсәт ителер.

Тәлкыйн әйтелер, мәетне гүргә төшергәч, индерүчеләр:

*Галә милләтән рәсүлүл-лаһ* — дип укырлар.

Мәетне күмү вә җеназа намазын уку мөселманнар өчен тиешле бурыч булыр. Арадан берәү җеназа намазын укыса, өсләреннән бердәй бурычлары төшәр. Җеназада дөнья хәлләрен сөйләшү, көлү, чәч йолкып елау, кычкыру, акыру кебек эшләр тыела.

Елаган кеше дә бик саклык белән, гөнаһтан куркып кына еларга тиеш.

Соңыннан мәетнең рухына Коръән укып таралырлар.

Җеназа, ягъни мәетне җирләү йоласы менә шулардан гыйбарәт.

## ҮЛГӘННӘРНЕ ИСКӘ АЛУ, КАБЕРЛӘРЕН ЗИЯРӘТ КЫЛУ

Бу эш мөселманнар өчен мактаулы вә сөннәт санала. Бары тик гөнаһ иясе кемсәнәләр генә вафат булган карендәшләрен исләренә төшермәсләр, бары тик диннән язган адәмнәр генә туганнарының вә ата-баба, әни-әбиләренең каберләренә килмәсләр. Мондый хөрмәтсезлеккә һичкем лаеклы түгел, бу гадәтләрне белергә, йолаларны үтәргә тиешле.

Туган-тумачалар вә өй җәмәгате вафат булган кешенең искә алу кичәләрен уздырырлар. Монда, шәригать өйрәтүенчә, аш әзерләп, дини-диндарларны, якын-тирә күршене, дус-ишләрне, кардәшләрен чакырып китерерләр. Дин ияләре Коръәннән аятьләр вә төрле мөнәҗәтләр укырлар. Аларга садака өләшү шарт булыр. Бу кичәләрдә тавыш чыгару, юкны-барны сөйләшү, мәетне яманлык белән искә алу кебек нәрсәләр күренмәскә тиеш. Чөнки мондый сүзләр мәетнең рухын вә якыннарының бәгырен таптап китәр, мөселманнар арасында булган татулыкны җимерер.

Мәетнең өчесен, җидесен, кырыгын, еллыгын үткәрү сөннәт санала. Моннан соң да, ел да җыелышып, искә алу кичәсен билгеләп үтү мактаулы эшләрдән күрелә, әмма таләп итеп куелмый.

*Хәбәрләрдән шул билгеле.* Бәндәнең җаны тәненнән аерылганнан соң үзенең шул халәтенә тиз генә ияләшеп җитә алмас, ягъни башка рухлар аны үз яннарына тулысынча кабул итеп бетерә алмаслар, шунлыктан, аны юатыр өчен вә ныклыгын хасил итү теләге белән Коръән багышлату, садака бирү саваплы була. Әйтерләр ки, тәннән аерылган җан җир йөзенә багып торыр, адәмнәрнең яхшы гамәл-

ләрен күреп сөенер, начарлыклардан көенер. Бары тик Коръән аятьләре вә садака гына аны тынычландырыр. Әмма садаканы теләсә кемгә бирү бер дә дөрес эш күрелмәс, бәлки диндар, суфи, мулла, ятим-ятимә, гидай вә мохтаҗларга бирү генә саваплы булыр. Садаканың киме-артыгы юк, көмеш акча да, бакыры да, ничә тиен генә булмасын, Аллаһы тәгалә исемен телгә алып тапшырсаң, күп акча бирү бәрабәренә күрелер. Садаканы әзсенгән (садака алучы) кяферләр хисабына керер, гөнаһ иясе булыр. Шунлыктан садаканы карап алу дөрес санала алмый.

Мөселманнарның изге гадәтләреннән берсе — каберләрне зиярәт кылу, аларны чиста вә пөхтә хәлләрендә саклау! Кабер пычрату кебек эшләр зур гөнаһлар рәтеннән йөриләр. Шунлыктан, каберлек өстенә бина корырга, яки мәсҗид салып, гыйбадәт кылырга, яки киез җәеп, чатыр ясарга, өстенә басарга ярамый. Моны эшләгән кешеләр бәхетсезлек иясе булырлар вә имансыз саналырлар, андыйлар белән аралашу, алар белән күрешү һәркемнең бәхетен киметер.

Каберлеккә зиярәт кылып килгән бәндәләр һичбер авыр сүзләр белән бер-берсеннән көлмәскә, теләсә нәрсә сөйләшмәскә бурычлылар. Алар, иң элек, тәһарәтләнсеннәр, аннан соң ике рәкәгать намаз укысыннар. Беренче вә икенче рәкәгатьнең һәрберсендә башта «Фатиха» сүрәсен, аннан «Аятел-көрси»не берәр мәртәбә. «Ихлас» сүрәсен өч мәртәбә укысын, бу догасының савабын мәет исеменә вә рухына багышласын. Шуннан соң гына каберстанга юнәлсен. Каберлек өстенә килеп җитүгә:

*Вәгаләйкүм-әс-сәламү йа әһләд-дийар минәлмөслиминә вәл-мөэмининә рәхимәл-лаһү тәгаләлмөстәкъ-диминә минкүм вәл-мөстәхәйринә миннә әнтүм линасәләфүн вә нәхнү ләкүм тәбәгун вә иннә иншаал-лаһү бикүм ләхикунә нәсьәлүл-лаһа тәгалә ләна вә ләкүмүл-гафийәһ* — дип укысын.

Мәгънәсе: «Сезләргә сәлам булсын и йорт әһеле мөселман вә мөэминнәрдән булган, Аллаһы тәгалә рәхмәт кылсын үзегездән алдагыларга вә

үзегездән соңгыларга безләрдән, сез безләр өчен алдагылар һәм безләр сезләргә иярүчеләр (ягъни артыгыздан баручылар), Аллаһы теләсә, без сезләргә иярүчеләр, Аллаһы тәгаләдән үзебез өчен һәм сезнең өчен тынычлык сорыйбыз!»

Моннан соң, зиярәт кылып килгән кеше, кабер янына җитеп, мәетнең йөзенә каршы утырыр һәм «Йәсин» сүрәсен укыр. Шушы сүрәне укыгач, аңа җиңел булып китәр. Моннан соң тәсбих әйтер, тагын да дога укыр, боларны мәеткә атар, шуннан соң каберстаннан чыгар, кайтыр.

*Хәбәрләрдән шул билгеле,* зиярәт кылган кешеләргә мөселманнарның рухлары сәлам бирерләр, бу сәламнәре аларга савап буларак килеп ирешер. Каберләр яныннан үткәндә «Колһуаллаһ» сүрәсен унбер мәртәбә укып үтәргә тиешле. Әгәр дә берәү шулай итсә һәм дә аны кабер ияләренә атаса, шул гүрдәгеләр санына тигез дәрәҗәдә бу бәндә Аллаһы тәгалә вә изге рухлар каршысында сөекле булыр.

Каберләр арасында аякларга башмак яки берәр аяк киеме киеп йөрү сөннәт саналмый. Мөхәммәд пәйгамбәр зиярәт кылучыларга каберлек җирендә яланаяк йөрергә боерган.

Вафат булган кешеләрне искә төшерү шулай ук сөннәт санала. Мәетләрне бары тик начар яктан сөйләп хәтердә яңартырга ярамый, ачулану, үпкә белдерү дә киңәш ителми. Ачулану, сүгенү, начарлыгын искә төшерү ул мәетнең хәтерен калдырыр, укылган догаларның савабы кимер, дөньялыкта яшәүче кардәшләре сиңа үпкәләрләр вә рәнҗерләр.

Вафат булган кемнәрне искә алу, каберләрен күреп кайту, алар рухына намаз чыгу, Коръән уку Ахирәт көнен бәндәләрнең исләренә төшерер. Шушы рәвешле аларның иманнары ныгыр вә диннәре тернәкләнер, гөнаһлары саклану кирәклеге күңелләрендә яңарыр, Аллаһы тәгаләнең барлыгына инаныр лар, гүр иясе туганнарын, ата-аналарын сөендерерләр. Бәс, Хак тәгалә адәм балаларына түземлекләр бирсен!

# Хатын-кызларның әдәп вә әхлаклары



● **Хатын-кызларга карата шәфкатьле һәм дә яхшы мөнәсәбәттә булу хакында ● Хатын-кызларның кайбер гадәтләре вә йолалар, тәртипләр хакында ●**

# *Кереш*

*Ислам диненең шәригать хөкемнәре тормышның барлык өлкәләрен дә үз эченә ала. Шуларның берсе — мөслимә хатын-кызларның үз-үзләрен тотышлары, әдәп вә әхлаклары белән бәйләнгән. Иманлы бәндәләр аларны белергә һәм тормышларында ул йолаларны үтәргә, яшәү рәвешләре итәргә тырышырга тиешләр. Шуның белән үзләрен гөнаһтан вә ялгышлардан саклап кала алырлар.*

## ХАТЫН-КЫЗЛАРГА КАРАТА ШӘФКАТЬЛЕ ҺӘМ ДӘ ЯХШЫ МӨНӘСӘБӘТТӘ БУЛУ ХАКЫНДА

Әхлаксызлык — хакыйкый, сукмактан тайгак юлга керү белән бер, кайда егылып башыңны ватасыңны һәм үзеңне харап итәсеңне күз алдына да китерү мөмкин түгел анда.

Ир кешедән шәригать өендәге хатын-кызларга, үз балаларына вә аналарына карата бик тә шәфкатьле вә мәрхәмәтле, яхшы мөгамәләне таләп итә. Шушы ук таләп хатын-кызларга да куела. Алар бер-берсенә карата күркәм мөнәсәбәттә булырга һәм бер-берсен җәбер-золымнан сакларга бурычлылар. Чөнки бу йоланы тоту вә ныгыту гаиләнең бәхетен, башкарган эшләрнең файдасын, кылган кәсепнең хәерле булуын һәм дәвамлылыгын, Ахирәт тормышында савап вә дәрәҗә алу өчен сәбәп хасил итә. Аллаһы тәгалә ирләр ягыннан хатын-кызларга карата күркәмлек белән тереклек кылуны вә мәрхәмәтле, миһербанлы булуны таләп итә: «Хатыннарыгызга күркәм холык вә йомшаклык белән тереклек кылыгыз!» — дип белдерә. Мондый таләпләр куелган аятьләр Коръәндә шактый күп очрый.

Мөхәммәд пәйгамбәр хәтта үлем түшәгенә яткач та, имам Газали хәбәрләренә караганда, мөселман ирләргә васыять итеп: «Бишвакыт намазны вакытында укыгыз, кол вә кәнизәкләрегезнең хакларын бирегез һәм үтәгез, аларга җәбер вә золым

кылмагыз, аларга көчләре вә тәкатьләре җитмәгән эшләрне мәҗбүри эшләтмәгез, хатыннар хакында Аллаһы тәгаләдән куркыгыз, ягъни аларга җәбер вә золым кылмагыз, алар белән мәрхәмәтле булып, алар белән яхшы торыгыз»,—дигән *(Хәдис)*.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Мөхәммәд пәйгамбәр әйтә торган булган: «Җәбраил фәрештә хатын-кызларга карата мәрхәмәтле вә шәфкатьле булуны, яхшылык эшләүне һаман-һаман миңа әмер итеп тапшырды, хәтта мин теләмәсәм дә, Җәбраил галәйһис-сәлам хатыннарны талак кылып аеруны да хәрәм эшләрдән дип күрсәтә» *(Хәдис)*.

Мөхәммәд пәйгамбәр исә үзенең хатыннарына бик тә мәрхәмәтле вә шәфкатьле булган, аларга тавыш күтәреп әмер бирмәгән, сораган үтенечләрен канәгатьләндерергә тырышкан һәм мондый эшләрен хатыннары да аяк астына салып таптамаганнар. Чөнки хатын-кызга карата булган рәхим вә шәфкать-мәрхәмәт ирләргә савап һәм әҗерләр китерә, башкарган хезмәтнең файдасын бирә. Инде дә ул хатын бала анасы икән, мәрхәмәт вә миһербанлык ата һәм ир кешегә икеләтә кайтарыла, бәхетен тагын-тагын да арттыра.

Үз якларыннан хатын-кызлар да затларына бәрабәр рәвештә яхшы холыклы вә йомшаклык иясе булырга хаклылар. Һәрбер ир кеше хатын-кызның шайтанын котыртудан сакланырга вә шәфкать-мәрхәмәт белән аларны иркәләп, күңелләрендәге бер нокта кадәрле каралыкны юар өчен ярдәмнәрен кызганмаска бурычлылар.

Шәригать вә тәфсир китапларыннан күренгәнчә, *ирләр хатын-кызлардан болар белән өстен:* 1) пәйгамбәр булуда; 2) падишаһлыкны тота алуда; 3) акыл вә фикердә; 4) эшне ахырына кадәр күреп, алдан исәпләп башкаруда; 5) олуг галим дәрәҗәсенә ирешү ягыннан; 6) сугышта каһарманлык күрсәтүдә; 7) куәтле вә көчле була алуда; 8) шаһитлыкта; 9) уразада; 10) намазда өзлексез була алуда; 11) азан әйтүдә; 12) хөтбә-нәсыйхәт укуда; 13) намазны җәмәгать белән укуда; 14) җомгага җыелуда; 15) гайд намазын укуда; 16) имам булуда; 17) талак кылуда; 18) талактан кайтуда; 19) никах

та шулай ук ирләр ихтыярында; 20) бер иргә дүрт хатын алуда, әмма хатыннарга берьюлы дүрт иргә хатын булып тору — тыела; 21) хатын өстеннән хуҗа булуда; 22) мирас бүлгәндә, иргә бер өлеш артыграк бирелергә тиешлектә; 23) ирләр өчен яңа никахтан тыелып тору чоры, ягъни гиддәт — юк, талактан соң яки хатыны үлүгә ир кичекмәстән яңа никахка керә ала.

Ирләрнең хатыннардан шушы яклары өстен, әмма башкада алар хатыннар белән бер төсле дип исәпләнә. Хатын-кызларга хас булганча йомшаклык, нәзакәтлелек, нәфислек кебек сыйфатларга ирләргә ирешү бик авыр. Болары хатыннарның өстенлеге хакында сөйлиләр. Әгәр дә Аллаһы тәгалә хатын-кызлар өчен ирләргә бүлгән кадәрле сабырлыкны да биргән булса, алар шул сыйфатлары белән ир-ат халкыннан шактый өстенгә чыгар иде. Шуңа күрә дә алар, ягъни хатыннар даим саен сабырлык камчысы белән үзләрен суктырып торырга тиешләр. Сабыр төбе — саф алтын, диләрме? Сабыр хатын да алтын бәрабәренә тора.

* * *

Мөселман ир үзенең холыксыз хатынына сабырлык күрсәтә икән, бу сабырлыгы ул хатынны тәрбия итәр. Акылы зәгыйфьләнмәгән икән, холыксыз хатын да үз гөнаһын аңлап, күркәмлек юлына басар. Сабыр ир сабыр хатынга да затлы бүләк төсле. Шуңа күрә дә хатыннар сабыр ирләренә сөенергә вә аларның затлылыгына куанып яшәргә, алар өчен авырлык вә яманлык китермәскә зур тырышлыкларын куярга омтылырга тиешләр. Бәхетсезне бәхетле итү — олы куаныч, саваплы эш, ә бәхетлене бәхетсез итү — гөнаһ. Яхшы иргә тиң бүләк — холыклы хатын.

Һәркем белеп торсын, ир өстенә тел озайтып тавыш куптару гөнаһ эшләрдән санала. Ирләр исә мөмкин кадәрле хатыннарын аннан сакларга, мөмкин кадәр сабыр итәргә вә шул рәвешле аларны яман гадәтләреннән кайтарырга, тәрбия кылырга омтылырга бурычлылар. Җаваплылык гаепле ке-

шенең үзенә генә түгел, бәлки шушы гөнаһ эшен вакытында тыя белмәгән, аннан сакланмаган бәндәләр өстенә дә төшә.

Мөхәммәд пәйгамбәребез шулай дип әйткән ки, кайсы хатын үзенең ирен теле белән газапласа, иза чиктерсә, яман сүзләр әйтеп рәнҗетсә, Кыямәт көнендә ул хатынның телен Аллаһы тәгалә җитмеш аршын озынлыгында итеп кыла. Озайган шушы телләре соңыннан ул хатыннарның муеннарына еландай уралып, аларны тәмуг газапларында интектерәчәк. Шуңа күрә дә үзен ир дип санаган кешеләр хатыннарына мөмкин кадәр шәфкатьле вә миһербанлы булырга, аларны чыгырдан чыгармас өчен тырышлыкларын куярга тиешләр, башка юллар — бикле.

*Хәдис:* «Мөэминнәрнең иманда камилрәге — күркәм вә яхшы холыклы һәм җәмәгатьләренә йомшак вә мәрхәмәтлерәк булучы кеше!»

Икенче бер *хәдис:* «Сезнең изге вә яхшырагыгыз — хатыннарына изге вә яхшырак булучылар, мин һәм җәмәгатемә изге вә яхшырак булучыгыздан!».

Мөхәммәд пәйгамбәр мөселманнарга болай дип белдергән: «Кыямәт көнендә минем өммәтләрем булган бер адәмне китерерләр. Ул оҗмахка кертүләрен сорар, әмма анда үтү өчен аның яхшылыгы булмас. Шунда Аллаһы тәгалә: «Ул кешене оҗмахка кертегез, чөнки ул җәмәгатьләренә мәрхәмәтле вә шәфкатьле булды!» — дияр. Ул мөэмин җәннәткә үтәр».

Өй җәмәгатьләрен вә балаларын ташлап киткән ир яки хатын, бер айгамы, ике-өчкәме, әллә бөтенләйгәме, барыбер, ул кеше бик зур гөнаһлы була. Иң олуг шәфкатьсезлек тә шушыннан килә. Ул кемсәнең кылган эшләре уңышсызлык белән тәмамланачак, бәхете, канат какмас дәрәҗәдә калып, төкәнәчәк.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам болай дигән: «Дөреслектә җәмәгать вә балаларыннан качучы, аларны ризыксыз ташлап китүче кеше — хуҗасыннан качкан кол шикелле, аның кире әйләнеп кайтканына кадәр Аллаһы тәгалә бу кешенең догаларын вә

уразасын кабул итми!» Гомерләре буе алар хәер вә бәрәкәт тапмаслар һәм дә ахырда барыбер үз йортларына әйләнеп кайтырлар. Әмма дә ләкин мөлкәтле вә хөрмәт иясе олуг зат булып түгел, бәлки өшәнгән вә фәкыйрьлектә гаҗизләнгән хәлдә кайтырлар.

Мөэмин-мөселман шуны аңларга тиеш: әгәр ул үзе хатынына вә балаларына карата мәрхәмәтле вә шәфкатьле була икән, алар да аның үзенә шул рәвешле яхшы якларын гына күрсәтерләр, яманлык юлына керүдән сакланырлар. Шуңа күрә дә, и мәрхәмәтле ир, әгәр дә син хатыныңның вә балаларыңның бәхетле вә яхшы булуын теләсәң, иң элек үзең холыклы һәм итагатьле бул, нәфесеңне гөнаһлардан пакь кыл. Ул сыйфатлар синең үзеңдә чәчәк атсалар, балаларыңда вә хатыныңда күркәм җимеш бирерләр. Сабырлык юлдашың булсын!

И күркәм хатын, яман ирне яманлык белән җиңә алмассың. Ирнең яхшы сыйфатларын үзеңдә булдырырга тырышу гына мактаулы эш. Таш өстенә орлык сибеп иген җыю мөмкин түгел. Ирең миһербан вә шәфкать иясе икән, яманлык юлына кермә, телеңне озаюдан сакла, юкса, өстеңә олуг гөнаһлар төшәрләр, бәхетең кимер, яман кулына калырсың. Әгәр дә инде ирең миһербансызлар рәтеннән икән, аның юлын сөрмә, сабыр ит, башлап үзең миһербан вә шәфкать әсәрләрен күрсәт.

Нинди генә каты вә төксе ирнең дә бәгырь төбендә йомшак урыны бар. Ташлы җирнең дә арасында балчык, каты ташның да йөзендә бер ярык булмый калмас. Шул ярыкларга агач тамырлары ничек тотынышып үсәләр, синнән төшкән шәфкать орлыгы да шулай тамыр җибәрер һәм ташлык дигән җирең гөлбакча булыр.

## ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ КАЙБЕР ГАДӘТЛӘРЕ ВӘ ЙОЛАЛАР, ТӘРТИПЛӘР ХАКЫНДА

*Кешеләр сорарлар:* «Хатын-кызларга чәч кистереп йөрү яки чәчләренә чәч ялгау дөрес буламы?» — дип. Шәригать китапларыннан күренгәнчә,

чәчне ялгау һәм кисү бик зур гөнаһ эшләрнең берсе санала, хәтта берәр хатын үзенең иреннән рөхсәт сорап бу юлга басса да яисә хайванның кылын яки башка хатыннарның чәчләрен үзенә җыеп, үз чәченә ялгатса да — болар ярамый һәм килешми.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам мөселманнарга хәбәр итеп әйткән: «Аллаһы тәгалә шундый кешеләрне ләгънәт кыла: кемнәр чәчкә чәч ялгап, өеп йөри торган хатыннар, шулай ук кемнәр тән тишеп әйбер төшерүчеләр».

Хатыннарга чәч кистерү, чәч ялгау, чәчне сату кебек эшләр барчасы да хәрәм. Шулай ук ирләргә дә сакалларын төбенә кадәр кисү, кырып ташлау дөрес түгел. Әмма алар чәчләрен кисәргә-кайтарырга тиешлеләр. Моның сәбәбе исә ирләрнең хатыннарга, хатыннарның ирләргә охшамавы аркасында. Шәригать ир кешеләрнең хатын-кыз затына, хатын-кызларның ирләргә охшаш булуын өнәми. Яхшы ир бервакытта да ирләр көче таләп ителгән эшне хатынына йөкләми һәм күркәм хатын да ирләрдән хатын-кыз эшләрен эшләтми вә эшләтмәскә тиеш. Чөнки бу да шулай ук ирнең хатынга, хатынның иргә охшавы кебек гөнаһлы һәм ярамас нәрсә.

*Ирләр* җыелышып килерләр һәм *сорарлар:* «Сакалны ни кадәр озынлыкта йөртсәк яман гадәт булмас?» — диеп. Шәригать китаплары вә ирләр әдәбе кагыйдәләреннән күренгәнчә, сакал озынлыгы бер тотам кадәр озынлыктан да кыскарак булмаса, яхшы. Артык озынга үстерү һәм бөтенләй үк кистермичә йөрү дә мактаулы эшләрдән түгел. Мөселман бәндәләрнең сакал-мыекларын тәртипле итеп йөртү рәвешләре бар.

Мөхәммәд пәйгамбәр Ислам халкына башка милләтләргә охшаудан сакланырга кушкан. Кеше, әгәр дә ул башка берәүгә охшарга тырышып, аныңча киенеп, аныңча кыланып йөри икән, шуның белән аз-азлап, әкренләп кенә үз төсен югалта. Шуның кебек, бер милләт икенче милләттән үрнәк алып, аңа охшарга тырыша икән, үз сыйфатларын югалта һәм үзен һәлакәткә китерә.

Башкаларны үзеңнән өстен күрү аларның рухи дөньясы белән кызыксынуга вә диннән күченүгә китерә. Шунлыктан мөселман бәндәләр чит диннәргә кызыгырга тиеш түгелләр, бәлки Исламны барысыннан да өстен күреп, аның юлыннан тайпылмас өчен Аллаһы тәгаләдән ярдәм үтенергә бурычлылар. Иман исә нәкъ менә шуңа өйрәтә, күңелне ныгыта.

* * *

*Хатыннар* килеп *сорарлар:* «Без күп сөйләшергә яратабыз. Кунак булып килгәч яки мәҗлескә чакырылгач, аш алдында үзебезне зурдан куеп, күп-күп сөйләшербез, көлешербез. Бу эшләребез гөнаһмы-түгелме?» — дип.

И тормышыбызның яме, күңелебезнең хыял бакчасы булган күркәм холыклы хатыннар, белегез, аш янында зурдан кубыпмы, кечедән башлапмы, көлешепме, башкачамы сөйләшсәгез, моның һичбер гөнаһы юк, бары тик гайбәткә генә юл куймагыз. Аш янында күңелле вә җан рәхәте була торган сүзләрне сөйләшеп ашау-эчү — сөннәт, матур гадәт. Тәнегез ризыкланып, җаныгыз да рухи азык белән туклансын. Киресенчә, аш янында авыз салындырып утыру, я булмаса, йоклап китү, яисә боегып калу бер дә ярый торган эшләрдән түгел. Күркәм вә ягымлы сүз белән ризыкның бәрәкәте артыр.

И оялчан вә итагатьле *хатыннар, сез сорарсыз:* «Күрем вакытында бездән кан төшәр. Ирләребездән ул хәлләр күренмәс. Алар пакь һәм чиста килеш безнең яныбызга килеп ятарлар. Моның өчен безгә гөнаһ юкмы?» — дип.

И Аллаһы тәгаләнең мактауга лаеклы затлары булып яратылган хатыннар, хәвефегез урынсыз. Күрем вакытын узучы хатынын яратып, янына ире яткан икән, монда бер дә яманлык вә начарлык күренми. Бары тик якынлыкка гына бармагыз. Күрем вакытында ирләр авызлыкланып торырга вә хатынын борчымаска бурычлылар. Бу хәлгә төшкән хатынына иренең якынлык кылуы шәригать буенча бер дә дөрес эш түгел.

И мөэмин вә мөэминәләр, дин хакында сүз кузгатканда белер-белмәс килеш бәхәсләшү һәм дә телгә салынып сөйләү бер дә ярый торган эшләрдән саналмый, шуңа күрә саклык белән, уйлап кына фикерләреңне бәян итәргә кирәк. Әгәр дә *сез:* «Мөселман хатыннарына ничек итеп киенеп йөрсәләр яхшы? Начардан киенсәкме, яхшыданмы?» — диеп *сорасагыз,* иң беренче, мөслимәләргә пакь вә чиста кием киеп йөрү тиешле, дигән җавапны ишетерсез. Әмма бервакытта да: «Шакшы тәнегезгә агартылган кием киегез»,— дигән киңәшне ишетмәссез. Чөнки керле тәнгә кигән чиста кием керсез тәнгә кигән пычрак кием кебек.

Кайбер хатыннар: «Без — Ислам дине кешеләре, гади итеп киенергә тиешбез»,— диярләр. Әмма мөслимәләргә матур вә яхшы киемнәрнең, зиннәтле әйберләр белән бизәлүнең тыелган эш түгеллеген белмәсләр. Кошларны затлы каурый ничек күркәм итеп күрсәтсә, яхшы кием дә мөслимәләрне шулай ук гүзәл кыяфәткә кертер. Яхшы кием киенгән, төрле зиннәтләр белән бизәлгән хатынның күңеле гөл бакчасына кунган былбыл кебек горур да, тәртипле дә, камил дә булыр. Бу хатын үзенә тиң иптәшләрен эзләр, мәҗлесләрдә үзен-үзе белештереп, дәрәҗәсен саклап кына сөйләшер, үзе кебекләргә иярер. Яхшы вә зиннәтле кием — күркәм әхлак вә өлге булырлык әдәпкә чакыручы әйберләрдән санала. Шунлыктан мөслимәләр мондый рәвешне сайлаудан, шундый киемнәр киенүдән курыкмаска тиешләр. Дөрес, кайберәүләр әйтерләр: «Яхшы киемле бәндәләр арасында яманнары да җитәрлек»,— диярләр. Хәтта дәлил итеп бер-ике мисал да китерерләр. Бу сүзләргә җавап табалмыйча аптырарсыз. Әмма онытмагыз, яман кешедә яхшы кием күркәм утырмый һәм, шулай ук, яхшы кешедә яман кием дә матур күренә. Әйтәләр бит: «Сылу кешегә солы капчыгы да килешә!» — дип, бу сүз дә ялган булмас.

Мөслимә кеше үзенең сайлаган иптәшенә карата бик тә игътибарлы булырга бурычлы. Әгәр дә ул үз теләге белән яман берәүгә кушыла икән, каралыктан саклансын һәм сайлаганы өчен өлге

дәрәҗәсенә ирешсен. Аның чанасына утырдым дип, аның җырын җырламасын. Әгәр дә инде яхшыларга ияргән икән, аның бәхете. Яхшылардан үрнәк алу — фарыз эш, андый дустыңны һич кенә дә югалтма. Яхшыларга кушылу, күркәм холыклы вә әдәпле бәндәләргә иярү — дөнья вә Ахирәт тормышында бәхет-сәгадәт кәсебен бирә, яшәешенә мәгънә өсти.

Әйтерләр ки, явыз юлдашка ияргән бәндә үзен тәмугка кертә, изге кешегә иярү исә җәннәткә илтә, дип. Китапларда явыз юлдаш чага торган кара елан белән генә тиңләнелә.

* * *

Хатыннарның иргә баруы сөннәт эшләреннән санала. Ялгызлык вә гаиләсезлек хатыннарны боза һәм аларның тормышларын терәксез итә. Үзләрен генә яраткан бәндәләр башкалардан аерылып яшиләр һәм бергәлекнең кадерен белмиләр. Хәдисләрдән билгеле булганча, хатын-кыз ирсез калырга тиешле түгел. Һәм дә хатын бала кадереннән вә рәхәтеннән дә мәхрүм тормаска бурычлы. Әгәр дә берәүнең табигате аркасында баласы юк икән, ул вакытта тәрбиягә алып үстерсә, бу хатын күркәмнәр исәбендә саналыр, халык аны һәм баласын хөрмәт итәр. Мондый аналарга аеруча игътибарлы булу таләп ителә. Әгәр дә халык арасыннан берәү мондый пакизәгә шакшы сүз әйтә яки начарлык эшли икән, ул кемсәгә карата һәммәсе ачулы йөз күрсәтергә һәм аны орышырга тиешләр.

Хатын иргә чыкты икән, хәдисләрдән күренгәнчә, ул үзенә хуҗа тапты, дигән сүз. Һәрдаим яхшы мөгамәлә һәм күркәм мөнәсәбәт иң беренче чиратта хатын ягыннан күренсен. Мондый эшләрнең Аллаһы тәгалә каршында саваплы икәнлеген ул хатын бервакытта да онытмаса, бәхетле булыр.

Риваятьләрдә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам заманында ук күрелгән вакыйга дип бәян ителә ки, бер хатын яшәгән һәм һәммә өммәт өчен үрнәк булу аның өстенә йөкләнелгән икән. Кайчан ире эш белән йөреп кайта, бу хатын аны өендә көтеп тора һәм:

— Яхшы иткәнсез, рәхим итегез! — дип каршы ала торган булган. Ул гына да түгел, өстендәге киемен салырга булышып, элеп куя да, башмакларын салдырышып, читкә ала икән.

Әгәр дә шунда ире кәефсез кайтып керсә, бу хатын иң беренче итеп:

— И ирем, ни хәсрәт кайгыландырды сине, әгәр дә борчуларың бар икән, Ахирәт көне өчен дип бел, мондагы авырлык андагы җиңеллек хакына Аллаһы тәгаләдән бәндәсенә җибәргән хәбәредер, — диеп аны юата икән.

Бу хатын хәлләрен Мөхәммәд галәйһис-сәламгә әйткәннәр. Шунда пәйгамбәребез:

— Чын мөэминәләргә үрнәк итеп Хак тәгалә арабызга аны җибәргәндер, үзенә белдерегез, иман китерсен. Ул болай да инде ярты иманлы, ул болай да инде үзен мөселман итеп таныткан икән. Мондый хатыннарга шәһидләрнең ярты савабы иңәр, изге гамәлләре җәннәткә китерер, — дип белдергән һәм үзеннән сәлам тапшыруларын сораган.

Бу риваятьтән күренгәнчә, хатыннарның иманы ирләренә булган мөнәсәбәтләрендә үк чагыла. Яман холыклы хатынны ничек итеп яхшылар санына кертергә мөмкин дә, иман иясе дип күзалларга була? Кешене каргау бәндәнең иманын бетерсә, иргә карата хатынның явызлыгы да шул рәвешледер.

Ирләренә карата яманлык күрсәткән хатыннар, әгәр дә тәүбәгә килмәсәләр, дөньялыктан имансыз хәлләрендә үтәрләр һәм тәмуглы саналырлар.

* * *

Адәм балалары, алар нинди генә булмасыннар, бәлаләнмичә калмыйлар; бәланең зурысы кечесен таптап үтәргә мөмкин. Әмма башны түбән ияргә генә кирәкми. Кайда һәм ничек ялгышканыңны аңлап, тәүбәгә килергә кирәк. Тәүбә — бәладән котылу юлы. Шуңа күрә дә мөселманнар һәм мөслимәләр бер-берсенең хәлләренә керергә, үзара миһербанлылык белән яшәргә, тату торырга һәм, иң кирәге, берсен-берсе гафу итә белергә тиешләр.

Кемнәр гафу хакын онытып, тәүбәгә килгән кешегә сыртларын күрсәтәләр, алар да имансызлыкка таба аякларын атлыйлар дигән сүз. Бәддоганың никадәр гөнаһлы эш икәнлеген күз алдына китерүе кыен түгел, бәддога бәндәне үлгән вакытта имансыз итә, ә үзен Ислам динендә дип санаган кешеләр имансыз калудан куркырга тиешләр. Имансызлык — иң зур гөнаһ. Моның өчен кем гафу итәр дә, кем алдында тәүбәгә егылырсың?

«Ни чәчсәң, шуны урырсың», — диләрме? Кемнәр бәндәләргә бәла-казалар тели, бу аларның үзләренә килә, кемнәр карендәшләренә яхшылыклар сорый, болары да үзләренә килә. Адәм балаларының бәхете — үзара дустанә вә тату торуда, берсен-берсе хөрмәт итүдә һәм ярдәмчел булуда. Кемнәр моны аңламый, аларның иманнары камиллеккә ирешмәс, җаннары караңгыланыр, йөзләреннән нур качар. Коръәнне укыган кешеләр бу сүзләрнең никадәр хаклы икәнлеген белми калмаслар. Тәүбә кешеләрнең рухларын сафландыра, аларның киләчәк көннәренә иминлек бирә, күңелләрендә ышанычны арттыра.

Гаиләнең төзеклеге, тормышның матурлыгы өчен дип, бу урында *хатыннарның ирләре алдында булган хаклары* турында бәян итү кирәкле табылды. Боларның иң *беренчесе* — хатын бишвакыт намазын укырга тиешле, аның бу намазлары үзенә генә түгел, бәлки иренең саулыгы һәм исәнлеге өчен дә кирәк. Намаз укыган хатынны ире орышырга яки аңа караңгы йөзен күрсәтергә тиеш түгел. Әгәр дә ир алай кылана икән, имансызлыктан курыксын, саф мөслимә, иң беренче чиратта, Аллаһы тәгаләнең колы, ә Хак тәгаләнең бәндәсен рәнҗетүдән дә яманрак эшләр юк кебек, гәрчә имансызлыкны һәм денсезлекне исәп төймәсеннән читкә куеп торсак.

Хатыннарның ирләре алдында булган *икенче* хаклары — рамазан аенда ураза (рузә) тоту. Бу вакытта ир кеше хатынына якынлык белән авырлык китерүдән тыелып торырга, аның хәленә керергә, кычкырып дәшмәскә, иркәлектә яшәтергә бурычлы. Моны үтәмәү иргә хәсрәт китерер, онытмасын,

эшләре кыекка китәр, бәласен җыеп ала алмас, саклансын.

Хатыннарның ирләре алдында булган *өченче* хаклары — тәннәрен хәрәмнән саклау. Бу бурыч аның үз өстенә йөкләнелә һәм ул моның өчен тулысынча үзе җавап бирә. Әмма дә ләкин ир кеше үз-үзен тотышы һәм хатынына карата яман мөнәсәбәте, ирсезлеге белән юл ача икән, ул вакытта гаеп икесенә бергә төшәр. Әмма дә ләкин ир хатынына, мөслимәгә башка ирләрдән саклану фарыз булыр, фәрҗен хәрәмнән имин тотсын.

Хатыннарның ирләре алдында булган *дүртенче* хаклары — буйсынучанлык. Ире начармы-яхшымы, әгәр дә ул иманлы бәндә һәм мөселман икән, хатыны тулысынча диярлек аңа коллык кылырга бурычлы. Әгәр дә ире тау-ташны күчерергә боерса да, хатынына шул эшне эшләү өчен көч куярга тиешле. Әмма бу әмере ирнең хатынны җәбер итүе өчен була калса, ул вакытта хатын иреннән зар кылырга, аннан аерылырга хаклы, әгәр дә шәригать таләпләренә туры килсә. Хатынын сөекле күргән ир һич күтәрә алмаслык авырлыкны аңа йөкләмәс һәм хөрмәтеннән, миһербанлыгыннан коры калдырмас. Исерек ирнең исерек халәте дә хатыннар өчен иң авыр йөкләрнең берсе булып тора, моны хатыннан гомере буе күтәрттерү — хәрәм, бу имансыз санала.

*Хатын-кызларның үз-үзләрен тотуларында да кагыйдәләр җитәрлек, аларны шәригатьтә әдәп тәртипләре дип карыйлар.*

Шулардан *берсе* — хатын кайда гына барса һәм өеннән чыгып китә калса, әйтик, берәр йомыш яки эш белән, ул вакытта ире өйдә булса яки эш белән китәргә җыенса, хатыны алдан ук иреннән: «Мин фәлән эш белән фәлән җиргә барасы идем, рөхсәтегез булырмы?» — дип сорарга бурычлы. Ире, әлбәттә, эшнең асылын белеп тә бетермәскә мөмкин, әмма кирәк таба икән, рөхсәт итәр, каршы килмәс.

Хатыннар әдәбеннән *икенчесе* — ирнең түшәген ташламау, ягъни ирне ялгызын яткырмау, хәтта үпкәләшкән вакытлары булса да, ир белән хатын

түшәккә уртак хөрмәтләрен күрсәтергә бурычлылар. Мәгәр дә ир тарафыннан бер тапкыр гына булса «талак» сүзе әйтелгән икән, ул очракта хатын аерым йокларга ирекле саналыр. Әгәр «талак» әйтелмичә торып бергә ятмасалар, ул вакытта араларына талак хөкеме төшүдә шик барлыкка килер.

Хатыннар әдәбеннән *өченчесе* — ирен сөйгән хатын иптәшенә карата ләгънәт әйтергә тиеш түгел, чөнки ирен яманлаган хатынга тәүбә савабыирешмәс.

Хатыннар әдәбеннән *дүртенчесе* — ире белән тормышыннан шөкер кылу, ягъни тормышлары нинди генә авыр күрелмәсен, хатын моңа ризалык тотарга, ире тапкан малны исраф итмәскә бурычлы. Әгәр дә мөслимә алай эшләми икән, ул кяферләр санына чыгар. Хәтта: «Синең белән торуымнан мин мәңге ризамын» — дип исәп тотуы саваплы күрелер, ничек кенә авыр булса да.

Хатыннар әдәбенең *бишенчесе* — үзенең киемен хатыннар иренең өеннән читтә бер генә җирдә һәм башка йортта калдырырга тиеш түгелләр. Шуңа күрә үз киемеңне башкага киеп йөрергә бирү яки башканыкын сорап тору шәригать тарафыннан әдәпсезлек санала, бозыклык дип күрсәтелә.

Хатыннар әдәбенең *алтынчысы* — ирне тыймау, ягъни ире аны үбәргә теләсә, үптерү, якынлык өмет итсә, аны читкә куймау. Әгәр шәригать тәртибендә күрсәтелгән вакытлар яки хәйз, ягъни күрем чоры икән, хатын иренә моны ничек тә белдерергә һәм аны ялгыштан имин итәргә тиешле.

Ирне карау, балаларны тәрбияләү, ашарга пешерү, бергә утырып ашау, кер юу, йортны чиста тоту һәм башка өй эшләре хатын өстенә йөкләнелгән бурычлардан саналыр, ул аны, яки үзе башкарыр, яки башкаручыларныкын күзәтеп торыр, бар нәрсәне тәртиптә саклар, кирәкне иренә әйтер, таләптән ерак булыр, хәлләрдән хәбәрдар итәр.

Билгеле, хатыннарның бурычларын, хакларын, әдәпләрен берәмтекләп санап бетерү берьюлы мөмкин дә түгел, әмма бу таләпләр шәригатьтә иң төп икәнлекне онытмаска кирәк. Изге һәм күркәм мөслимә булу өчен иң төп шартлар шушылар,

кемнәр боларны тотар, бәхетле саналырлар; кайсылары авышырлар, үзләренә авырлык килер, гаиләләре таркалыр.

# Хәрәмнән саклану яки Энҗеләр нуры



● Хәрәм-золым булган эшләр ● Караклык ● Хыянәт ● Гайбәт ● Кешегә яла ягу һәм юк гаебен бар итеп сөйләү ● Сүз йөртү ● Ялган сөйләү ● Көнләшү, ягъни хәсәд ● Хәрәм гайре золыми, золым булмаган хәрәмнәр хакында ● Исерткеч эчүнең хәрәмлеге бәяне ● Никахның хәрәм булу очраклары ● Зина кылуның хәрәмлеге хакында ●

# *Кереш*

*Бәндәләр арасында төрле кешеләр бар. Аларның бер ишеләре үзләренә яманлыкны вә гөнаһ-хәрәм эшләрне юлдаш итеп яшиләр, моның ахыры нинәрсә белән бетәсен күз алларына да китереп карамыйлар, шайтан юлын сөреп йөриләр. Икенче берәүләр исә ничек кенә булса үзләрен хаклык сукмагыннан адаштырырга мөмкинлек куймаска тырышалар, фарыз эшләргә күңел биреп, хәрәм шөгыльләрдән чирканып яшиләр. Боларның беренче төр кешеләре хурлауга лаеклы булса, икенчеләре исә дөнья йөзендә бәндәләрнең хөрмәтен, күкләрдә — җәннәт рәхәтен татырлар. Шуңа күрә дә җир йөзендәге барлык-барлык кешеләр үзләрен хәрәм вә бозык эшләрдән сакларга тырышлык куеп, җәннәт бакчасының татлы җимешләрен өзеп ашарга омтылырга тиешлеләр. Әмма күпләр хәрәмнән фарызны аера алмас дәрәҗәдә «сукыраеп» калганлыктан, аларга хәрәм шөгыльләр, эшләр, сыйфатлар хакында хәбәрләрне бәян итәргә кирәк табылды һәм шуңа күрә дә бу язма «Хәрәмнән саклану» дип аталды.*

*Адәм балалары эшләгән хәрәмнең бер ишесе Аллаһы тәгалә тарафыннан гафу ителер. Әмма моның өчен хак бәндәләр тәүбә үтенеп, кешегә золым эшләгән вакытларында, алардан гафу сорап, Ходай тәгалә каршында тезләнерләр. Яманлык вә хәрәм ияләре бары тик дөньялыкта гына гафу кылынып, гүр ияce булганнан соң моңа ирешә алмаслар, бәхиллек сүзен ишетеп, күңелләрен нурландырудан мәхрүм калырлар. Яманлык вә золым урыны дөньялыкта булган кебек, адәм балаларына тәүбә вә бәхиллек җире дә шушында. Бәдәннән җан аерылганнан соң инде моңа ирешеп була ала торган түгел.*

*И хакыйкать ияce бәндә, әгәр дә син бер-бер ялгышлык белән үз нәфесеңне тыя алмадың һәм кеше өлешенә кердең икән, тәүбә ит, бәхиллек сора. Әгәр дә син кемгә булса да яманлык вә хәрәм эш, золым кылдың икән, ул вакытта рәнҗеткән*

*кешеңнән гафу үтен, бәхиллек сора, шуннан соң гына синең тәүбәң Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәтенә барып ирешер һәм Ул да сине ярлыкар. Башка төрле котылу юлы, чынлыкта, юк. Бары тик шушы рәвешле эшләгәндә генә синең күңелең тынычланыр, бары тик шушы рәвешле эшләгәнең өчен генә син тәмуг, ягъни җәһәннәм утыннан үзеңне саклап кала алырсың. Әмма бел! Синең шундый да бер төрле яман вә хәрәм шөгыльләрең булыр, аларны Аллаһы тәгалә үзе дә һич гафу итә алмас, син инде хак хөкемнән котыла алмассың. Бу эшләреңнең исеме — золым! Дин теле белән әйтсәк: «Хәрәмун золуми», ягъни «хәрәм-золым». Ә гафу вә тәүбә кылына торган хәрәм эшләрне «Хәрәмун гайре золуми» дип атап йөртәләр, ягъни «золым дәрәҗәсендә булмаган хәрәм» диләр. Күренә ки, хәрәмнәрнең иң куркынычлысы — тәүбә үтенеп тә гафу ителми торган хәрәм-золым була да инде. Хәзер без аларны бәйнә-бәйнә карап үтәрбез.*

## ХӘРӘМ-ЗОЛЫМ БУЛГАН ЭШЛӘР

### КАРАКЛЫК

Алар арасында иң куркынычлысы һәм дә иң авыры — караклык. Аннан аеруча нык сакланырга кирәк. Үзенең нәфесен тыя алмыйча, кеше малына кулын сузган һәм аны үзләштергән кешеләр, ягъни ул әйберне бәя белән сатып алмаган кемсәләр карак булалар. Алардан да золымлырак вә яманрак эшне башкаручылар булмаганлыктан, Аллаһы тәгалә алдында вә кешелек каршысында иң зур золымны башкарган кешеләр булып караклар саналалар һәм аларның кылган эшләре һичбер тәүбә вә үтенеч белән гафу ителми. Шуның өчен дә Коръән: ∗Вә лә йәсрикъна∗ — дип караклыктан тыеп килә. Бу бөек кәлименең мәгънәсе татар теленә «Урламагыз» дип тәрҗемә кылына. Шулай ук Мөхәммәд галәйһис-сәлам пәйгамбәребез үзенең хәдис шәрифләрендә:

*Лəгыйнə Аллаһус-саарика* —
дип урлаучы каракларның никадəр куркынычлы вə золымлы эш башкаруларын күрсəтеп бирə.

Бу хəдиснең т а т а р ч а мəгънəсе моннан гыйбарəт: «Урлаган кешегə Аллаһы тəгалə лəгънəт кыла».

Кешенең кечкенə генə берəр əйберсен дə алу, бəһасен түлəмичə үзлəштерү — урлау, караклык була. Əгəр дə берəр кешенең бер саплам җебен, йə булмаса бакчасында үскəн бер генə бөртек җимешен дə сорамыйча, рөхсəттəн башка аласың икəн, болар да караклык хисабыннан йөрилəр, зур гөнаһ хөкемендə йөртелəлəр. Шуңа күрə шəригать тə андый кешелəрне авыр хөкемгə тарта. Ягъни, бер кеше рөхсəтсез, яшертен, хак түлəмичə генə икенче берəүнең малын урлап ала икəн, ул əйбер бер саплам җепме, йə булмаса бер дөя кадəр малмы, башкамы, əгəр дə ул карак җинаятендə тотылса, карак булуы дəлил кылынса, аның кулын кисү талəп ителə. Шəригатьне бозу хəрəм булганлыктан, хак мөселманнар бу хөкемне җиренə җиткереп башкаралар. Чөнки төп кагыйдə: караклык — иң зур гөнаһ, аңа бернинди кызгану, аны берничек тə яклау, гафу итү ярый торган эшлəрдəн түгел. Шуңа күрə Коръəндə:

*Əс-саарику вəс-саарикату фаактагу əйдиййаһума* — дип боерыла.

Я г ъ н и: «Карак ирнең дə, карак хатынның да кулларын кисегез».

Əмма бүгенге көндə кешелеклелек төшенчəсе алга чыгарылганлыктан, каракларга карата мондый җəзаны билгелəмилəр. Шулай да шəригать тарафдарлары вə хак мөселманнарның кайберлəре бу хөкемне җəмгыятьтə ныгытырга тырышалар, чөнки алар Коръəн кушканны бозмый үтəргə омтылалар. Əгəр дə берəр каракның кулын мөселман кеше кисə икəн, Аллаһы тəгалə каршында ул кисүче золым эшлəгəн булып чыкмый. Əмма шунсын да дөрес аңларга кирəк ки, карак вə угрыларның җəзасы моның белəн генə бетми, Кыямəт көнендə алар тагын да зуррак җəзаларны күрəчəклəр əле.

Урлаган кеше шулай ук дөньялыкта да рәхәт тормыштан мәхрүм була.

## ХЫЯНӘТ

Караклык кебек үк хыянәт тә хәрәм булган эшләрнең берсе. Шулай ук хыянәт тә кеше малынаәйберенә кул сузу һәм кеше хакына керү ул. Аның төрле сыйфатлары, аңлатмалары бар, шулардан, әйтик, берәр кеше сиңа сакларга биреп торган әйберне, малны, акчаны һәм башкаларны — ни генә булмасын — үз файдаңа тоту, сарыф итүдер. Монысы *беренче* төр хыянәткә карый.

*Икенче* төрлесе — сату иткән вакытта, үз малыңа хас булмаган сыйфатларны күрсәтеп, ягъни бар кебек итеп сөйләнеп, мактап-мактанып сату итү. Әйтик, ул кеше, ягъни алучы кеше синең малыңның асыл сыйфатларын белеп тә бетермәскә мөмкин. Ә син шуннан файдаланып, ялганны эшкә җигәсең дә, юкны бар итеп күрсәтәсең, хыянәт абзарына кереп, тирескә батасың, димәк.

*Өченче* төр хыянәтләрдән дип яхшы әйбер, сыйфатлы мал белән аралаштырып, яман, начар товарны сатуны әйтәләр, йә булмаса: «Бу малга фәлән кадәр бәһа бирә иделәр, ул шулкадәр кыйммәт тора», — дип ялганлап сатуны да хыянәт дип атыйлар, тагын да: «Бу мал минем үземә фәлән кадәр бәһагә килде, ул фәләннәр кадәрле тора», — дип ялганлау — бу да хыянәт.

Хыянәтнең *дүртенче* төре моннан гыйбарәт: әгәр дә берәр кеше сиңа сер итеп кенә бер-бер нәрсәне сөйли икән, син ул серне кабул итеп алып, аның белән уртаклашып, хәтта бу серне башкаларга сөйләмәм дип сүз бирү яки бирмәвеңә карамыйча, инде дә башка бер кешегә чишәсең икән, бу да авыр золым булып тора.

Башка берәүне алдау, үз файдаң өчен ялган сөйләү — болар да хыянәткә керә — *бишенче* төр буларак карала.

Шулай ук кешедән бурыч алып, аны фәлән көндә түлим яки түләмим дигән сүзеңә карамастан,

ул бурычыңны тапшырмау, түләмичә генә калдыру — бу шулай ук олы золым, *алтынчы* төр хыянәт булып тора.

Хыянәтнең *җиденче* төре: хезмәткә ялланган кешегә аның эш хакын түләмичә калдыру.

Хыянәтнең *сигезенче* төре: гаепсез кеше өстенә яла ягып, ул бу эшне кылучы дип түрәләр алдында ялган сөйләү, кеше өстенә гаеп ташлау.

*Тугызынчы* төр хыянәт: ике дус кешенең арасын бозу.

Хыянәтнең *унынчы* төре: яшерен генә, сер саклап сөйләшкән кешеләрнең сүзләрен тыңлап тору, хәтта аны башка берәүләргә җиткерәсеңме, юкмы, аңа карамый, барыбер хыянәт!

*Унберенче* төре: әгәр бер кешедә һичберәүгә зыяны тими торган гаеп бар икән, моны халык алдында рисвай итеп, хурлыкка калдыру шулай ук хыянәт.

*Уникенче* төр хыянәт: кешегә килешми һәм батмый торган, үзе яратмаган кушамат, үртәү сүзе тагу.

*Унөченче* төр: иптәшләреңә авыр вакытта аларның дошманнары ягына чыгу.

Бу эшләр барсы да хыянәт итү, кешене рәнҗетү булып тора. Шушы унөч төрдән дә артыграклары бар. Аларны һәркем үз уе вә күңеле белән тоя һәм дә «Бу кыланышым хыянәт булмасмы?» дип уйлап эш итәргә, шөгыленең нинди юнәлештә булуын ачык күзалларга мөмкин. Алардан тыелырга, мөмкин кадәрле ерак булырга кирәк!

## ГАЙБӘТ

Гайбәт диеп бер кешенең гаебен үзе юк чагында сөйләшүне һәм аның хәлен тикшерүне атыйлар. Ул — хәрәм-золым булган эшләрнең берсе һәм дә аның белән шөгыльләнү бик тә куркынычлы. Аллаһы тәгалә вә кешеләр каршында гайбәт бәндәләрне зур вә гафу ителмәслек гөнаһларга сала. Шуның өчен дә берәүнең гайбәтен сөйләшүдән тыелырга, хәтта гөнаһлы эше булып та, башкаларга

моның зыяны тиярлек түгел икән, аны да сөйләшмәскә кирәк. Кеше хәлен тикшерү — бу да шул ук гайбәт инде. Шуңа күрә дә боларны мөмкин булган кадәр ул кешенең үзе алдында, үзе булган җирдә сөйләргә вә сөйләшергә омтылырга кирәк.

Үзеннән башка кеше хәлен тикшерү һәм дә аның гаебен күрү шулай ук гайбәт вә хәрәм эш. Моны онытырга ярамый. Кеше хәлен тикшерер алдыннан иң элек үзеңнең кем булуыңны билгеләргә һәм яманнан вә гаептән мөмкин кадәр сакланырга тиешле. Чөнки, әгәр дә син бер кешенең гаебен күреп, аның гайбәтен сөйләсәң, икенче юлы шул кеше синең үзеңнең гаебеңне күрер, гайбәтеңне сатар, даныңны чыгарыр. Сүз артыннан сүз китәр. Дөньяны шушы рәвешле хәрәм вә яманлык басар. Ә төп гаебе үзеңдә булыр. Син моны белми вә аңламый да калырсың. Чынлыкта исә дөньяны бозучы һәм болгатучы кеше син үзең булырсың. Һәм моның гөнаһы артыгы белән күп вә чиксезлеккә ирешер. Шуңа күрә дә белеп тор, уйламадым, сизмәдем дип әйтерлек булма. Кеше гайбәтен сөйләгәндә синең сүзләреңне тыңлап торган кешеләр табылган кебек, синең яман атыңны сатканда да аның сөйләгәнен тыңлап торучылар табылыр. Шулай итеп, арагызда дошманлык китәр, бу дошманлык исә әче камыр кебек кабарыр, тагын да дөньяны басар, күтелмәгән хәлләргә китереп җиткерер.

Коръәндә дә бу хакта аятьләр бар. Мөхәммәд галәйһис-сәлам дә үзенең хәдис-шәрифләрендә, бу хакта бер-берегезнең итен ашаудан никадәр тартынсагыз, гайбәт сөйләүдән дә шулкадәр качыгыз, дип юкка гына әйтмәгән. Гайбәт сөйләү — кеше итен ашау кебек үк чирканчык вә костыргыч бер эш булганлыктан, аннан саклану барлык кешегә дә тиешле!

## КЕШЕГӘ ЯЛА ЯГУ ҺӘМ ЮК ГАЕБЕН БАР ИТЕП СӨЙЛӘҮ

Кешенең гайбәтен сату никадәр яман, начар, кабахәт, хәрәм эш икәнлекне аңлаганнарга яла ягу

һәм юк гаепне бар итеп сөйләүнең никадәр зур золым булуын төшендереп торырга кирәкмидер инде. Аллаһы тәгаләнең бик тә ачуын китергән һәм Кыямәт көнендә иң каты газапка тартылачак кешеләр дә менә шушы юк гайбәтне сөйләп тел тегермәнен тартучылар һәм ялган яла ягучылар булачак. Билгеле ки, бу эшләрдән саклануы артык авыр түгел, моның өчен хакыйкатьне яклаучы вә яратучы бәндә булырга, дөреслеккә ачык күз белән карарга күнегү генә кирәк.

Һәркем белә булса кирәк, Ислам динендә булган кешене ачулану шулай ук хәрәм эшләрдән. Син аның артыннан сүгеп каласыңмы, күзенә карапмы, битенә бәрепме ачуланасың, барыбер, мөселман булган бәндәне, ягъни карендәшеңне үпкәләтү, аны рәнҗетү, йөз суын түгү була. Әгәр дә инде шуның өстенә юк кына бер гаебе өчен алай кылансаң, бу инде бигрәк тә яманрак хәл. Мисал өчен, әгәр дә пакизә, саф бер хатынны: «Син—зиначы» яки «Син—зина кылган, бозылган»,—дип өстенә яла яксаң, ул вакытта гөнаһысы зур була, аннан бернинди тәүбә вә күз яше белән котылып булмый инде. Бу гына да түгел, шушы эшең өчен дөньялыкта да шәригать буенча өстеңә җәза төшәчәк. Шушы хәрәм вә яманлыгың өчен сине яткырып суктырырга вә чыбыкларга тиешләр. Сак бул! Мондый эшләрдән үзеңне коткар.

## СҮЗ ЙӨРТҮ

Сүз йөртү дә хәрәм-золым булган эшләрнең берсе. Шуңа күрә дә ике кеше арасында сүз йөртүдән бик тә сакланырга кирәк. Әгәр дә сиңа килеп, ни хикмәт, берәү башканы яманлый икән, ул хурланган адәмгә барып: «Фәлән берәү сине яманлап сөйли»,—дип әләкләп, сүз өләшеп йөрсәң, кая барып чыгасың? Башкалар алдында нинди кадерең кала? Шәригать каршында нәрсә табасың? Аңларга кирәк, болай сүз йөртү бер дә ярый торган эш түгел. Нинди генә сүз ишетсәң дә аны эчеңә бикләп куярга вә сакларга гына кирәк. Хак мөселман бәндә шулай эшләр.

Шулай ук мөнафикълык та килешә торган нәрсәләрдән түгел. Берәү янында — бер төрле, икенчеләр каршында — башкача кыланып йөрү вә сүз ташу мөнафикълык була инде. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың дигән мәкальгә буйсынып гомер кичерүче бәндәләр барчасы да икейөзле мөнафикълардан булалар. Аларны Аллаһы тәгалә дә сөйми һәм Коръәндә дә:

*Иннәл-мөнәфикыйнә фиддәркил-әәсфали минән-наар. Вәлән тәҗидә ләһүм насыйраа* — дип белдерә.

Мәгънәсе: «Дөреслектә икейөзле адәмнәр тәмугның иң түбәнге катында газапланырлар һәм үзләренә һичбер ярдәмче тапмаслар».

## ЯЛГАН СӨЙЛӘҮ

Хәрәм эшләрнең берсе, хәрәм-золым — ялган сөйләү. Ялганлап сөйләгән сүз барыбер үз хәлендә кала алмый, аның дөресе килеп чыга, ялганның ялган булуы кайчан да бер беленә. Шулай итеп ул ялган сүз ялганчының үзенә зыян китерә. Ялганлап сөйләүнең тагын да бер начарлыгы бар, ул башка кешеләргә дә зур зыян ясый. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам:

*Әл-кәәзибү гадүүл-лаһи* — дип хак мөселманнарны ялган сөйләүдән читләшергә чакырган.

Мәгънәсе: «Ялганчы кеше — Аллаһы тәгаләнең дошманы!»

## КӨНЛӘШҮ, ЯГЪНИ ХӘСӘД

Аллаһы тәгаләнең берәүгә биргән байлыгыннан көнләшү, яки кемнең дә булса дәрәҗәсен күпсенү, яисә бер кешенең эше алга киткәннән тарлану, бәхетен күпсенү һәм гомумән көнләшү — болар хәрәм-золым булып торалар. Бер адәм үзендә күренмәгән сыйфатларны башка берәүдә таба һәм көнчелек кыла башлый икән, ул аңа аяк чалу ягын эзләнергә тотына. Монысы инде хәрәмнең дә хә-

рәме, иң әшәкесе. Чит берәүнең бәхетен бикләргә тырышу — бигрәк яман эшләрнең берсе. Мөселманнар андый көнче кешеләрне «хасид» дип йөртәләр.

Мөхәммәд пәйгамбәребез андыйлар хакында:

*Әл-хасидү лә йәдхулүл-җәннәтә* — дип белдергән.

Мәгънәсе: «Кешедән көнләшкәннәр оҗмахка кермәс!»

Әгәр дә берәү: «И, яхшы икән, шундый ук нәрсә минем үземдә дә булса, ничек шәп, ничек аны табарга!» дисә, бу эше вә кыланышы бер дә көнчелек галәмәте түгел, бәлки омтылыш билгесе генә. Кешедән көнләшмичә генә шундый ук әйберне үзеңдә булдырырга тырышу бер дә көнчелек түгел, бәлки кызыгу гына. Мондый сыйфат мөселманнарга хәрәм түгел.

Шулай ук, берәр иманлы бәндәгә бәла вә каза килсә, бу хәленә куану бер дә ярый торган эшләрдән була алмый. Әгәр дә кешегә бәла-каза килсә, мөселман бәндә үзе дә аның өчен кайгырырга, ярдәм кулын сузарга, ярдәм итәргә ашыгырга тиеш.

Кайберәүләр үзендә булган әйбернең башкаларга кермәвен вә килмәвен теләрләр, башкаларда булуын күпсенерләр. Бу сыйфатлары да көнләшү галәмәтенә керә һәм зур гөнаһлардан исәпләнә, алар моны белеп торырга тиешләр. Мөселман кешегә үзендәге кебек бәхет, белем, байлык, мал кебек күңелгә вә акылга хуш килә торган нәрсәләрнең башкаларда да булуын теләү бик фарыз вә саваплы. Хәтта, кулыңнан килгәндә, изгелек белән ярдәм кулы сузып үзеңнән ким булганнарга теләктәшлек — яхшы сыйфат. Мөселман менә шундый сыйфатка ия булганда гына үзен Хак бәндәләреннән дип исәпли ала. Шуңа күрә Мөхәммәд галәйһис-сәлам:

*Лә йөъминү әххадүкүм хәтта йөхиббә ли-әхибиһи-ма түхиббә ли-нәфсиһи* — дип белдергән.

Мәгънәсе: «Үзең сөйгән нәрсәнең мөселман булган кешедә дә булуын сөйгәнчегә кадәр һичберегез дә мөселман түгел!»

Шулай итеп, мөселман булган кеше фарызны тоту белән генә түгел, бәлки хәрәмнән саклану

кебек зур эшләрне башкару белән дә башкалардан өстен торырга тиеш. Ничек кенә булса да адәм баласы гөнаһтан сакланырга омтылса, аны башкалар ярдәменнән ташламас.

Бозыклыктан вә хәрәмнән сакланырга өйрәткән шәригать китаплары тагын да шундый гөнаһлы эшләрдән дип малларын сакларга кулларыннан килмәгән ятимнәрнең малларын суеп ашауны, аларның өлешенә керүне, җир-суларыннан мәхрүм итүне катгый тыя. Болар да хәрәм-золым булып исәпләнәләр. Аллаһы тәгалә тарафыннан һичкайчан мондый гөнаһлар гафу ителмиләр. Коръәннән күренгәнчә, ятимнәр өлешенә кергән кешеләр—ут ашаучылар, аларның урыны тәмугта икәнлеге билгеле.

Шулай ук үзеңә зыян итү яки итмәвенә карамастан, кешегә бәддога уку, аны каргау, явыз дога кылу—болар да хәрәм-золым. Башкаларга карата «Ходай суксын, каһәр төшсен» кебек сүзләрне дә әйтергә ярамый, бу да зур гөнаһ. Чөнки син каргаган бәндә мөселман булып, иманлы икән, ул каргышларың аның өстенә килмәячәк һәм үзеңә әйләнеп кайтачак.

Үчләшеп яисә малына кызыгып кешене үтерү дә зур гөнаһ, артык олы хәрәм эшләрдән санала. Андый хәлләрдән бик тә сак булырга кирәк! Әгәр дә инде берәр кешедә үчең бар икән, хәтта сине рәнҗеткән булса да, гафу итеп, онытырга тырыш! Моның өчен Аллаһы тәгалә әллә никадәр әҗер вә саваплар бирер. Әгәр дә мөселман кардәшең белән искәрмәстән сүзгә кергәнсең, яки үз-үзеңне белештермичә кыйнашкансың, яисә рәнҗетелгәнсең икән, үзең дә гафу үтенергә һәм үзең дә гафу итәргә кирәк. Моны бер дә озакка сузарга вә кабаттан кайтып кузгатырга, чыраеңны сытып искә алырга һич ярамый. Бер-ике көн эчендә үзеңне тәмам тынычландырып, бу хәлләрне бөтенләй онытырга тырышу урынлы булыр. Гөнаһтан котылу һәм качуның башка төрле юлы юк. Дошманлыкны саклаудан да хурлыклырак сыйфат адәм балаларында була алмас. Мөселман, ягъни иман иясе кеше һәрвакыт дуслыкны өстен күрергә тиеш.



9 Н 330

Кешенең начарлыгына кагылмаган гаебен үзенә белдерү, кыланып күрсәтү, мыскыл итү кебек эшләр дә хәрәм-золым булып исәпләнәләр. Әйтик, ни сәбәптән булса да гариплəр рәтендә йөргән кешедән көлү-мыскыллау — бу инде зур гөнаһ.

Шуның белән бергә, кул астында эшләгән, хезмәт иткән берәүне, яки балаңны, яисә хатыныңны, хәтта гаепләре булса да, күтәрелеп тирги башлау, рәнҗетеп ташлау кебек хәлләр дә хәрәм вә олы гөнаһлардан санала. Шулай ук, ишек төбенә йомыш белән килгән кешегә каты итеп эндәшү, авыр сүз әйтү, күңелен кайтару, зарлыларга караңгы чырай күрсәтү — болар да мөселманлык йортына сыеша торган эшләрдән вә фигыльләрдән түгел. Иманлы бәндә миһербанлык вә шәфкать иясе булырга бурычлы.

## ХӘРӘМ ГАЙРЕ ЗОЛЫМИ, ЗОЛЫМ БУЛМАГАН ХӘРӘМНӘР ХАКЫНДА

Башка кешеләргә вә хайваннарга зыян һәм җәбер китерми торган кешенең үзе өчен генә начарлык китергән эшләр — золым булмаган хәрәм дип аталалар. Болар Аллаһы тәгалә белән кешенең үзе арасында гына булалар. Шуларның иң беренчесе, әлбәттә, Аллаһы тәгаләгә камил дәрәҗәдә һәм дөрес итеп иман китерә белмәүдән килә. Бу очракта бу гафил адәмнәр Аллага тиңдәш итеп берәр бөек затны куя, яки үзен артык тәкәббер вә өстен итеп күрсәтә, яисә ышанып җитмәгән хәлендә Алланың барлыгын таный. Үзебезгә ашар өчен ризыкларны бар кылган, эчәр өчен төрле тәмлелектәге суларны биргән, һәрвакыт адәм балаларын тәрбиясендә тоткан һәм пәйгамбәрләре белән халыкка хакыйкый вә тугры юлны өйрәткән Аллаһы тәгаләгә бер тиңдәшне куеп сөйләшү яки ул шулай дип аңлау — хәрәм. Аңа тиңдәшлек тоткан кеше зур хаталар ясый һәм имансыз була. Бу хакта Коръәндә мондый аять бар:

*Иннәл-лаһү лә ягъфирү ан йүшрәкә биһи вә ягъфирү маадүүнә зәликә лиман йәшаа-у*

М ә г ъ н ә с е: «Аллаһы тәгалә үзенә тиндәш тотканнарны ярлыкамас, моннан башка гөнаһ кылган адәмнәрнең Аллаһы тәгалә үзе теләгәнен ярлыкар».

Имансыз кешеләрнең урыннары тәмугта була. Мөселман бәндәләр: «Безне бар кылган Аллаһы тәгалә һәрвакыт яши, һәр нәрсәне Ул гына яраткан, Аның безгә җибәргән китаплары хак, ул китапларның барсындагы хөкемнәр дә дөрес» дип иман китергәннән соң үзенең Мөхәммәд пәйгамбәр аша килгән Ислам динендә торганлыгын белдерә һәм Аллаһы тәгаләгә тиндәш тоту кебек гөнаһ эшләрдән качарга омтыла, фарызны үтәү өчен бар тырышлыгын бирә. Шулай итеп ул кеше иманлы була. Әмма үзеңә-үзең тулысы белән ышанып та китәргә ярамый. Дөнья булгач, акка да, карага да очрыйсың, төрле хәлләр була. Ялгыштан саклану бик зур җаваплылык сорый. Кеше үзе дә белмичә Аллаһы тәгаләгә тиндәшлек юлларына кереп китәргә мөмкин. Аның ише эшләр сизелеп эшләнмиләр. Туры юлдан язу — көферлек арбасына утыру белән бер ул. Әле шул көе тәүбә итмичә генә үлеп тә китсәң, бәла аяк астында гына, ул вакытта дөньялыкта кылган яхшылыкларыңны да югалтырсың, Кыямәт көнендә ул яхшылыкларың исәпкә дә алынмаслар. Хәлең бик тә, бик тә яман булыр. Тәүбәсез бәндә — тәмугка барып керүче кяферләр рәтенә баскан кеше ул. Хәрәм эшләрне башкару исә шулай ук кяферлеккә китерә.

Бар нәрсәдән шомланып курка калу һәм, гомумән, куркаклыкның төрле дәрәҗәләре, эшнең ахырын яманга юрау — болар мөселман кеше өчен иң ярамас әйберләр булып торалар, чөнки куркаклык, шомлылык, яманга юрау — барчасы да Аллаһы тәгаләгә ышанып иман китерүнең асылын җимерәләр һәм дә көферлеккә төшерәләр. Җимерек иманлы бәндәгә мәңге ярлыкау вә гафу фарыз түгел. Кылган эшләренең савабы булмый. Бер шөгыльгә ябыша калса, эше таркала. Сәүдәгә тотынса, сәүдәсе җимерелә. Пычакка үрелсә, кулы киселә. Андыйларның өметләре китек була. Кешенең күңеленә шулар сәбәбе белән көферлек төшә, юлларыннан

яздыра, якты иманнары җаннарыннан аерыла. Мөшкел, бик мөшкел хәл! Шуңа күрә дә һичвакыт куркуга төшәргә ярамый. Мөселман кеше дөрес итеп аңларга һәм белергә бурычлы: адәмнәр башына төшкән барча бәла-казалар бары тик Аллаһы тәгаләнең үзеннән генә, башка һичнәрсәдән түгел. Хак тәгалә теләсә, ярлыкар, ул бәла-казалардан сине аерып алыр, теләсә, мәңге шулай калдырыр. Әгәр дә сезгә берәр бәла-каза килә кала икән, куркуга төшеп, һичкемгә вә һичнәрсәгә үпкәләмәгез, сәбәпне бары тик үзегезнең берәр гөнаһ кылуыгыз аркасында гына дип белегез, чөнки бәла-казаның асылы нәкъ менә шул гөнаһ эшләр аркасында. Шуның өчен дә башка беркемгә ярдәм сорап ашыгып килергә кирәкми. Бары тик Аллаһы тәгаләнең үзенә генә сыенырга, Аңа гына ышанырга, Аннан гына ярдәм көтәргә, Аны һәрвакыт үзеңнең яныңда дип хис итәргә, ташламаска кирәк. Бәла-каза килгән вакытта да мөселман кеше үзенең кылган гөнаһлары бармы-юкмы икәнлеген барларга һәм гафу үтенеп тәүбәгә килергә тиешле. Үзенең хак юлдан баручы мөэминнәрен ул ташламас, сыендырыр, ярдәменнән өлеш чыгарыр. Юкса бөтенләй авыр, куркынычлы гөнаһларга батып, Кыямәттә хурлыкка калырсың. Шуның өчен дә һәрвакыт йөрәкле, батыр булырга вә Аллаһы тәгаләне ташламаска кирәк.

Ә менә эш ахырын яхшылыкка юрау — дөрес әйбер. Юраган юш килә диләрме әле? Яманлыкка юрау — начарлык теләү белән бер булган кебек, яхшылыкка юрау — теләгеңә ирешү дигән сүз.

Шулай ук Аллаһы тәгалә таләп иткән вә Ислам динендә булган хөкемнәрне җиңелгә генә санап йөрү дә Аллаһы тәгаләнең боерыкларын санга сукмау кебек була. Бу да иманны җимерә, дәрәҗәсен төшерә. Шуңа күрә дә диндәге фарызны тотарга, хәрәмнән качарга барлык көчне сарыф итү сорала. Моны үтәмәсәң, дөньялыкта вә Ахирәттә бик күп бәла-казаларга очрарсың, хур булырсың.

## ИСЕРТКЕЧ ЭЧҮНЕҢ ХӘРӘМЛЕГЕ БӘЯНЕ

Исерткеч эчү гайре золыми булган хәрәм эшләр рәтеннән санала. Исерткеч эчемлекләр нинди генә җимештән һәм кайсы гына яхшы дип күрелгән әйберләрдән ясалмасыннар, нинди генә исем белән аталып йөртелмәсеннәр, аларны куллану барыбер — хәрәм. Тәмам шартлаганчы эчсәң дә яки бер генә тамчысын капсаң да, аңа карамый, хәрәмлеге кимеми. Дөньялыкта эчемлек эчеп, тәмам исереп, адәм мәсхәрәсе булып йөрүдән дә хурлыклырак башка халәт юк. Моны барлык мөселманнар шулай дип белә һәм аның дөреслеген таныргa тиешләр. Юкса, иманнары таркау булыр!

Коръәндә һәм хәдис китапларында исерткеч эчүдән мөселманнарның тыелуын таләп иткән сүзләр бик күп. Мөхәммәд пәйгамбәр:

*Мән шәрабәл-хәмрә хәрәҗә мән җәвүфиһи* — дип белдергән.

Мәгънәви тәрҗемәсе моннан гыйбарәт: «Әгәр дә бер кеше исерткеч эчемлек эчсә, аның эченнән иман нуры качар».

Аңлашыла булса кирәк, күңеленнән иман нуры качкан адәмнәр көферлек базына төшәләр һәм үзләрен һәлакәткә китерәләр. Алай гына да түгел, аракы вә шәраб кебек эчемлекләрне куллану, исерек баш булып йөрү — үзеңне генә түгел, якын-тирә танышларыңны, дусларыңны, туганнарыңны да авыр хәлгә куя, алар өстенә борчулар йөкли.

Исерткеч эчү тәсле оятлы вә гөнаһ эшләрнең берсе — отышлы уеннар уйнау. Шәригать китапларында шулай хәбәр ителә ки, адәмнәр арасында үзара орыш-талаш вә дошманлыклар менә шул отыш уены вә исереклек аркасында килеп чыгалар, чөнки исерткеч тә, отыш уеннары да, дини билгеләмәләрдән күренгәнчә, шайтан тарафыннан кешеләр арасына таратылган әйберләр. Алар бәндәләрне догадан вә намаздан аеру өчен уйлап чыгарылганнар. Исерткеч эчү, отыш уеннарын уйнау — болар шайтанга ияргән кешеләрнең эшләре. Мөселманнар бер-берсенә кардәш дип исәпләнелгәнлектән, алар мөмкин булган кадәрле бу эшләр-

дән тыелырга тиешлеләр. Шулай ук әфьюн (наркотик) куллану, тәмәке тарту да дөрес эш түгел. Аларны да Ислам дине катгый рәвештә тыеп кылә.

Мөселманнар өчен, шулай ук, дуңгыз итен ашау, үләксәдән авыз итү, кан эчү, Аллаһы тәгалә исемен телгә алмыйча чалынган малның итен ризык өчен файдалану — хәрәм. Хак мөселманнар вә иманлы бәндәләр моның ише эшләрдән сакланырга, бу төр ризыклардан авыз итмәскә тырышалар. Чөнки хәрәмнән саклану — мөселманның иң беренче һәм изге бурычы.

## НИКАХНЫҢ ХӘРӘМ БУЛУ ОЧРАКЛАРЫ

Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең хатыннарына бик мәрхәмәтле булган. Яраннары-дин карендәшләре хатыннарына карата аның усалрак булуын үтенгәч, пәйгамбәребез: «Җәбраил фәрештә аларга бик мәрхәмәтле һәм киң күңелле булуны таләп итә. Никах кылынган хатынны талак белән аеруны кабул итми. Талакны кире кага һәм мәрхәмәтсезлеккә саный», — дип белдерә.

Хатын алган ир, ягъни никах белән өйләнгән кеше үз хатынына яхшы мөнәсәбәттә булырга бурычлы. Ул гына да түгел, үзен чын мәгънәдә мөселман дип исәпләгән кеше хатын-кыз затына бик миһербанлы булырга тиеш. Шәригать шуны таләп итә. Исламда хатын вә ир мөнәсәбәте шушыннан чыгып билгеләнгән.

Шәригать нигезендә, ир вә хатын мөнәсәбәтләрен төзү — гаиләнең бәхетле тормышы вә рухларның тынычлыгы өчен кирәк. Шуңа күрә, дин тотучылар гына түгел, бәлки һәркем бу кагыйдә вә кануннарны яхшы белергә һәм тормышта аларны файдалана алырга тиешләр.

Никахның хәрәм булу очраклары шәригатькә генә түгел, бәлки нәсел-нәсәп вә тыйб фәне өчен дә әһәмиятле булып тора.

Нәселдән өйләнү хәрәм булган очракларны *бишкә* бүлеп була: 1) Бер ата вә бер анадан туган кешеләр; 2) Аларның нәселеннән булган кешеләр,

никадәр буыннары ерак булса да; 3) Бабалары вә әбиләре; 4) Баба вә әбиләренең балалары; 5) Үз нәселеннән булганнары.

Бер сүз белән әйткәндә, туган-тумачага өйләнү дин буенча хәрәм санала. Алар аерым *кагыйдәләргә* бүленеп аңлатылалар.

*Беренче кагыйдә*. Хатын итеп үзенең анасына һәм анасының анасына ир кешегә никахлану хәрәм. Шулай ук үзенең атасының анасына никахлану хәрәм. Хәтта буыннары никадәр ераграк китсә дә хәрәмлеге югалмый.

*Икенче кагыйдә*. Хатын итеп үзенең кызын һәм баласының кызын, оныкларын (нукаларын) никахлау ир кешегә хәрәм, хәтта оныклары никадәр буын бер-берсеннән ерагайсалар да, кагыйдә үз көчендә кала.

*Өченче кагыйдә*. Ир кешегә хатынлыкка үзенең сеңлесен, тутасын, кыз карендәшен никахлау хәрәм.

*Дүртенче кагыйдә*. Хатын итеп ир кешегә үзенең кыз карендәшенең кызын алу хәрәм була.

*Бишенче кагыйдә*. Хатын итеп шулай ук үзенең атасы белән бертуган кыз карендәшләрен алу ир өчен хәрәм.

*Алтынчы кагыйдә*. Хатын итеп ир кешегә үзенең әнисенең карендәшләрен алу хәрәм.

*Җиденче кагыйдә*. Ир кешегә үзе белән бертуган абый-энеләренең кыз балаларына никахлану шулай ук хәрәм.

*Сигезенче кагыйдә*. Ир кешегә хатынының анасын һәм хатынының анасының анасын никахлау шулай ук хәрәм.

*Тугызынчы кагыйдә*. Әгәр дә бер хатын, элеккеге иреннән аерылып, икенче иргә чыкса һәм үзе белән ияртеп бер кыз бала алып килсә, ул кыз бу иренә дә хәрәм булыр. Шулай ук элеккеге ирендә тәрбиядә калса да, барыбер бу иренә — хәрәм.

*Унынчы кагыйдә*. Әгәр дә ир баланың үги әнисе булса һәм әтисе үлсә яки аны аерса, бу ир балага ул үги ана шулай ук хәрәм була.

*Унберенче кагыйдә*. Шулай ук ир кешегә үз атасының атасы (ягъни бабасы) хатынын һәм әнисенең

атасының хатынын (ягъни әбисен) никахлау да хәрәм.

*Уникенче кагыйдә.* Шулай ук ир кеше өчен угыл балалары(улының уллары)ның хатынын никахлау хәрәм.

*Унөченче кагыйдә.* Әгәр дә сөт анасы ят бер кешенең баласын күкрәге белән ашатып үстерсә, бу баланың ир булып җитлеккәч сөт анасына никахлануы шулай ук хәрәм.

*Үндүртенче кагыйдә.* Сөт карендәш кызлар шулай ук сөт карендәш ирләргә хәрәм булып тора. Әмма шәригатьтә бу мәсьәлә катлаулылардан санала. «Нәселдә хәрәм булганнар сөт карендәшлектән дә хәрәм булыр, мәгәр, бәгъзесе генә нәселдә хәрәм булса да, ризыкта хәрәм булмас», дип аңлатыла.

*Унбишенче кагыйдә.* Әгәр дә араларында никах ярамаган ике карендәш булса, берсе ир заты, икенчесе хатын-кыздан исә дә, иргә аларны җәмәгать кылырга(өйләнергә) ярамый.

*Уналтынчы кагыйдә.* Ир кешегә үзе зина кылган хатын яки кыз кешенең әнисе белән никахлану ярамый, шулай ук үзе кызыгып йөргән кызның әнисен хатынлыкка алу да хәрәм.

*Унҗиденче кагыйдә.* Шулай ук, әгәр дә ир бер хатын белән зина кылган яки бергә торган икән, ул вакытта бу хатынның кызына никахлану да дөрес түгел.

*Унсигезенче кагыйдә.* Әгәр дә бер ир үз хатынын талак кылып аерса, ул хатынның яңа никахтан тыелып тору чоры тулмыйча, бу иргә талак кылынган хатыны карендәшенә никахлану шулай ук хәрәм.

*Унтугызынчы кагыйдә.* Әгәр дә кәнизәк, кол хатын мөслимә өммәтеннән булса (шулай ук асрау хатын, өй хезмәтчесе хатынга да карый), бер ир аңа хуҗа икән, ул кәнизәкнең кызына хуҗаның никахы хәрәм.

*Егерменче кагыйдә.* Кол кешегә үзенең хуҗасы-хатынга шулай ук никахы дөрес түгел.

*Егерме беренче кагыйдә.* Мөселман булмаган иргә утка табынучы мәҗүси хатынны никах кылып хатынлыкка алу дөрес түгел, хәрәм.

*Егерме икенче кагыйдә.* Шулай ук потларга табынучы хатынга мөселман ирнең никахы дөрес булмас.

*Егерме өченче кагыйдә.* Шулай ук йолдызга табынучы хатын белән мөселман ирнең никахы дөрес түгел.

## ЗИНА КЫЛУНЫҢ ХӘРӘМЛЕГЕ ХАКЫНДА

Зина кылу — халыкны вә җәмгыятьне бозучы иң яман эшләрнең берсе санала. Үзенең тәкатен тыя алмаган, нәфес колы булган бәндәләр мөселманнарны бик авыр хәлләргә калдырып, аларның бәхетләренә кул салучан булганлыктан, зина белән кәсеп итүче, зина белән гомерен үткәрүчеләр иң каты җәзага мохтаҗ кешеләр. Шуңа күрә дә андыйларга Аллаһы тәгаләнең ләгънәте төшә.

Зина кылу — бик начар кабахәт бер эш булуы һәм андый кешеләргә Кыямәт көнендә ни рәвешле газаплар ирешүе хакында Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрендә бик күп сөйләнелә. Коръәндә:

*Вә ләә тәкърәбүүз-зина иннәһү кәәнә фаахишәтән вәсәъә сәбийләән* — дигән аять бар.

Аның мәгънәви тәрҗемәсе моннан гыйбарәт: «Зинага якын бармагыз, чөнки зина кылу — бик-бик кабахәт эш һәм иң явыз юл».

Шушы рәвешле зина кабахәт вә явыз юл булганлыктан, бәндәләргә мондый эшне кылу түгел, аңа китерә торган хәлләрдән дә ерак булырга кирәк. Шуңа күрә дә мөселман кешегә ят хатыннарның йөзләренә карау, гәүдә, буй-сыннарына кызыгу, аулак өйләрдә ялгыз очрашу, тел сандугачын сайратып, аларның күңелләрен адаштыру кебек эшләрдән сакланырга кирәк. Шулай ук хатын-кызларга да ирләр вә егетләр алдында җәелеп китү, аларның кармагына төшү килешә торган эшләрдән түгел. Зинадан саклану өчен Аллаһы тәгалә адәм балаларына орлыкларын сипкән һәм никах шартларын биргән.

Ислам дине өйрәтүенә караганда, хәрәм эшләр төрле булырга мөмкин. Акчаңны-байлыгыңны шәригать кушмаган җирләргә әрәм-шәрәм, сарыф

итү, Аллаһы тәгалә биргән малны тиешле эшләргә файдаланмыйча, җыеп, асырап, яшереп яту, тиешенчә балаларыңны вә фәкыйрьләрне тәрбияләмәү, бирәүгә ярдәм итеп тә: «Мин аларга шуны бирдем, фәлән дә төгән!» — дип мохтаҗның йөзенә бәреп әйтү яки кеше аша ишеттерү, башкаларны яхшылыктан вә шәригать эшләреннән тыю, яман вә начарлыклар кылырга өндәү, кызыктыру — болар хәрәм, алардан сакланырга кирәк.

Адәм балалары өчен иң тыелган эшләрнең берсе — иманның ныклыгын бозу. Иман ныклыгын ватa торган эшләрнең берсе — вәгъдәне тотмау. Юкка гынамы: «Вәгъдә — иман», — дип әйтмәгәннәр. Шуңа күрә дә, вәгъдә биргәнсең икән, боз яки таш яуса да, үтәргә кирәк. Вәгъдәңне боздың икән, димәк, хәрәмгә таба атлап киттең һәм, китапларда шулай күрсәтелер ки, хәрәм эшләгән кеше тәмуг утында яначак.

Ант итү дә, шулай ук, вәгъдә төсле үк изге сүзләрдән санала. Син Алла исеме беләнме, түгелме, барыбер, ант итү — Алла алдында сүз бирү дигән мәгънәгә ия. Ялган сүз белән ант итү, булмаганны булды дип белдерү, шуның кебек башка эшләр — хәрәм.

Әйтерләр, бу дөнья — гөнаһ урыны, әмма аңа карап кеше хәрәмгә юл куярга тиеш түгел. Үзеңне яман вә хәрәмнән азат итәсең килсә, күңелеңне нык тотып, иманыңа тугры калырга гына кирәк. Ә бу — мөмкин эш. Андый бәндәләрен Хак тәгалә юлларыннан кире кайтармас, галәм эчендә, ягъни дөньялыкта һәм Ахирәт тормышында аларга ярдәмен бирер. Хәбәрләр шулай дип сөйлиләр.

*Озын сүзгә нокта булып килгән шигырь:*

Без — мәңгелек үлек, без — мәңгелек терек,
Тән пагенә җирдә мунча бар!
Ә җаннар соң нигә кара безнең?
Тамугыда Сират күпер — тар!
Шул ялкынмы алыр каралыкны,
Шул ялкынмы бирер сафлыгын?
Ник дөньяга Сират күпер аша

Килмибез соң алып пакьлеген?
Гөнаһысыз сабый... Ә башында
Мең уе бар — аклы-каралы.
Без яшәргә килдек исә җиргә,
Өнәмәсен җаннар караны!

بسم الله الرحمن الرحيم ۝
تبرك الذى بيده الملك وهو على كل شىء قدير ۝١ الذى خلق
الموت والحيوة ليبلوكم ايكم احسن عملا وهو العزيز
الغفور ۝٢ الذى خلق سبع سموت طباقا ما ترى فى خلق
الرحمن من تفوت فارجع البصر هل ترى من فطور ۝٣ ثم
ارجع البصر كرتين ينقلب اليك البصر خاسئا وهو حسير ۝٤
ولقد زينا السماء الدنيا بمصبيح وجعلنها رجوما للشيطين
واعتدنا لهم عذاب السعير ۝٥ وللذين كفروا بربهم عذاب
جهنم وبئس المصير ۝٦ اذا القوا فيها سمعوا لها شهيقا وهى
تفور ۝٧ تكاد تميز من الغيظ كلما القى فيها فوج سالهم خزنتها
الم ياتكم نذير ۝٨ قالوا بلى قد جاءنا نذير ۝ فكذبنا وقلنا ما
نزل الله من شىء ان انتم الا فى ضلل كبير ۝٩ وقالوا لو كنا
نسمع او نعقل ما كنا فى اصحب السعير ۝١٠ فاعترفوا بذنبهم فسحقا
لاصحب السعير ۝١١ ان الذين يخشون ربهم بالغيب لهم مغفرة

واجر كبير ۝١٢ واسروا قولكم او اجهروا به ۭ انه عليم بذات
الصدور ۝١٣ الا يعلم من خلق وهو اللطيف الخبير ۝١٤ هو الذى
جعل لكم الارض ذلولا فامشوا فى مناكبها وكلوا من رزقه ۭ واليه
النشور ۝١٥ ءامنتم من فى السماء ان يخسف بكم الارض فاذا هى
تمور ۝١٦ ام امنتم من فى السماء ان يرسل عليكم حاصبا ۭ فستعلمون
كيف نذير ۝١٧ ولقد كذب الذين من قبلهم فكيف كان نكير ۝١٨
اولم يروا الى الطير فوقهم صافت ويقبضن ۭ ما يمسكهن الا
الرحمن ۭ انه بكل شىء بصير ۝١٩ امن هذا الذى هو جند لكم
ينصركم من دون الرحمن ۭ ان الكفرون الا فى غرور ۝٢٠ امن
هذا الذى يرزقكم ان امسك رزقه ۚ بل لجوا فى عتو ونفور ۝٢١
افمن يمشى مكبا على وجهه اهدى امن يمشى سويا على صراط
مستقيم ۝٢٢ قل هو الذى انشاكم وجعل لكم السمع والابصار
والافئدة ۭ قليلا ما تشكرون ۝٢٣ قل هو الذى ذراكم فى الارض
واليه تحشرون ۝٢٤ ويقولون متى هذا الوعد ان كنتم صدقين ۝٢٥
قل انما العلم عند الله ۠ وانما انا نذير مبين ۝٢٦ فلما راوه زلفة

سيئت وجوه الذين كفروا وقيل هذا الذى كنتم به تدعون ۝ ٢٧
قل ارايتم ان اهلكنى الله ومن معى او رحمنا فمن يجير
الكفرين من عذاب اليم ۝ ٢٨ قل هو الرحمن امنا به وعليه
توكلنا فستعلمون من هو فى ضلل مبين ۝ ٢٩ قل ارايتم ان اصبح
ماؤكم غورا فمن يأتيكم بماء معين ۝ ٣٠

## *«Әлмөлек» сүрәсе («Тәбарәк»)*

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Тәбаарәкәлләзии бийәдиһил мүлкү вә һүвә гәләә күлли шәйиң кадиир. Әлләзии халәкал мәүтә вәл хәйәәтә лийәбьлүвәкүм әййүкүм әхсәнү гәмәлә. Вә һүвәл гәзиизүл гафүүр. Әлләзии халәка сәбьгә сәмәәвәәтиң тыйбәәка. Мәә тәраа фии халькыйр-рахмәәни миң тәфәвут. Фәрҗигил бәсара һәл тәраа миң фүтуур. Сүммәрҗигил бәсара кәрратәйни йәңкалибь иләйкәл бәсару хаасиәү вәһүвә хәсиир. Вәләкадъ зәййән-нәссәмәәәә әддөньйаа би мәсаабиихә вәҗәгәл-нәәһәә руҗүүмәллиш-шәйаатыйн. Вә әгтәдънәә ләһүм гәзәәбәс-сәгиир. Вәлилләзиинә кәфәруу бираббиһим гәзәәбү җәһәннәм. Вә биьсәл мәсыйр. Изәә үлкуу фииһәә сәмигүүләһәә шәһиикаү вәһийә тәфүүр. Тәкәәдү тәмәййәзү минәл гайз. Күлләмәә үлкыййә фииһәә фәүҗүң сәәләһүм хазәнәтүһәә әләм йәътикүм нәзиир. Каалүү бәләә кадьҗәәәә әнәә нәзиир. Фәкәззәбүнәә вә кульнәә мәә нәззәләәллааһү миң шәйиң. Ин әңтүм илләә фии даләәлиң кәбиир. Вә каалүү ләү күннәә нәсмәгү әү нәгкыйлү мәә күннәә фии әсхәәбиссәгиир. Фәгтәрафүү бизәмбиһим. Фәсүхкалли әсхәәбиссәгиир. Иннәлләзиинә йәхшәүнә раббәһүм билгайби ләһүм

мәгъфиратү вә әжърун кәбиир. Вә әсирруу кауләкүм әвижъһәруубиһ. Иннәһүү гәлимүм бизәтиссудүр. Әләә йәгләмү мәң халәкъ. Вәһүвәл-лътыйфүл хабиир. Һүвәлләзии җәгәләләкүмүл әрда зәлүүләң фәмшүү фии мәнәәкибиһәә вәкүлүү мирризкыйһ. Вә иләйһиннүшүр. Әәминтүм мәң фиссәмәәәи әййәхсифә бикүмүл әрда фәизәәһийә тәмүүр. Әм әәминтүм мәң фиссәмәәәи әййүрсилә гәләйкүм хәәсыйбә. Фәсәтәгләмүүнә кәйфә нәзиир. Вәләкадъ кәззәбәл-ләзиинә миң кабьлиһим фәкәйфә кәәнә нәкиир. Әвәләм йәрау илөттайри фәүкаһүм саааффәәтиү вә йәкъбиднә, мәә йүмсикүһүннә илләр-рахмәән. Иннәһүү би күлли шәйиң бәсыйр. Әммән һәәзәлләзии һүвә җүңдүлләкүм йәңсурукүм миңдүүнир-рахмәән. Инил кәәфируунә илләә фии горуур. Әммән һәәзәл-ләзии йәрзукүкүм иң әмсәкә ризкаһ. Бәлләжҗүү фии гүтүви вә нүфүр. Әфәмәй йәмши мүкиббән гәләә вәжъһиһии әһдәә әммәййәмши сәвиййән гәләә сыйраатыйм-мөстәкыйм. Куль һүвәлләзии әңшәәкүм вәжәгәлә ләкүмүссәмгә вәл әбъсаара вәл әфъидәһ. Калииләммәә тәшкүрүун. Куль һүвәлләзии зәраәкүм фил әрдый вә иләйһи түхшәруун. Вә йәкуулүүнә мәтәә һәәзәл вәгдү иң күңтүм саадикыйн. Куль иннәмәл гыйльмү гиндәллааһи вә иннәмәә әнә нәзиирум-мүбиин. Фәләммәә раәүһү зүлфәтәң сииииәт вүжүүһүл-ләзиинә кәфәруу вә кыйлә һәәзәлләзии күңтүм бињии тәддәгүүн. Куль әраәйтүм иң әһләкәнийәллааһү вә мәм мәгийә әү рахимәнәә фә мәй йүҗиируль кәәфириинә мин гәзәәбин әлиим. Куль һүвәр-рахмәәнү әәмәннәә биһии вә гәләйһи тәвәккәлнәә. Фәсәтәгләмүүнә мәң һүвә фии даләәлим-мүбиин. Куль әраәйтүм ин әсьбәхә мәәәәүкүм гаураң фәмәййәътиикүм би мәәәәим мәгиин*

## Мәгънәсе:

Мәрхәмәтле, рәхимле, шәфкатьле Аллаһы тәгаләнең исеме белән башлыйм эшемне.

Аның кулында ике дөньяның патшалыгы — Аллаһы тәгалә мөбарәк вә олугъ. Ул — Аллаһы тәгалә һәрнәрсәгә көче җитүчедер.

черәк яки Коръән вә сөннәт белән танышып, хак белән батыйль арасын аерып, туры юлны карап, күреп барган кешеме хак юлга күнелүчерәк?

Әйт: «Ул — Аллаһы тәгалә сезне юктан бар кылды, вә сезгә хак сүзне ишетмәк өчен колак бирде, вә гыйбрәтләрне күрмәк өчен күз бирде, вә фикерләп хак белән батыйльне аермак өчен күңел бирде, бу нигъмәтләргә караганда сезнең шөкер итүчеләрегез бик аздыр».

Әйт: «Ул — Аллаһы тәгалә сезне җирдә яратты, вә Аның хозурына кубарылырсыз».

Кяферләр әйтәләр: «Вәгъдә ителгән Кыямәт көне кайчан була, дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, әйтегез?» — дип.

Әйт: «Шиксез, ул Кыямәтнең вакытын Аллаһы тәгалә генә белер, вә мин фәкать хисап вә газап белән куркытучы гынамын».

Һәм газапны бик якыннан күргәннәре вакытта хакны инкарь итүче кяферләрнең йөзләре каралыр, вә аларга әйтелер: «Бу — шул газаптыр, сез аны ашыгып көтәдер идегез!»

Әйт: «Ничек уйлыйсыз, әгәр Аллаһы тәгалә мине һәм минем белән бергә булган мөэминнәрне һәлак итсә яки рәхмәт итеп безне исән калдырса, хакны инкарь итүче кяферләрне рәнҗетүче каты газаптан кем коткарыр?»

Әйт: «Ул — безнең Раббыбыз барча нәрсәгә ирешүчедер, вә без Аңа иман китердек һәм Аңа тәвәккәл кылдык. Тиздән күрерсез, кем ачык адашып саташуда икәнлеген!»

Әйт: «Ничек уйлыйсыз, әгәр сезнең суыгыз һич ала алмаслык тирән җир астына киткән булып әверелсә, кем китерер сезгә кайнап агучы чишмә суларын?»



بسم الله الرحمن الرحيم
الله جل جلاله
محمد عليه السلام
ابو بكر عمر رضي الله عنهما
عثمان علي رضي الله عنهما
حفظهما وهو العلي العظيم


„Бисмилла" дыр һәрбер эшнең башы, „Бисмилла" дыр оҗмахларның ачкычы...!

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ إِنَّا أَنْزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ وَمَا أَدْرَاكَ مَا
لَيْلَةُ الْقَدْرِ ۞ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِنْ أَلْفِ شَهْرٍ
تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِمْ مِنْ كُلِّ أَمْرٍ
سَلَامٌ هِيَ حَتَّى مَطْلَعِ الْفَجْرِ

# قدر کیچ

(«سورهٔ قدر»دن)

بو قدر کیچ یلده بر کیچ، بارچه کیچلر ایزگیسی؛
صافلانر طاپدن بو کیچ مؤمن کوکللر کوزگیسی

صافلانر اول، پاکلانر، بیك زور خدا اینك دولتی،
هم توشه راول کوزگیلرگه کوك قاپوغی شه وله‌سی

شول قپوغدن کوند ررمز تگرمزگه بر تلەك،
بو قدر کیچ، تکری قارشنده، مك آیدن ایزکیره‌ك

جون، مامقدای ئه یله نورلر بیرده بو کیچ ارواح و روح،
هم فرشته صفلاری یورور مکلر گروه:

اول ملائکلر جیارلر طول، یتملر یاشلرن،
بارچه کوچسزلر، ضعیفلرنك آهن، قارغشلرن:

کوز یاشندن، تورلی رنجشدن یاصاب زور انجیلر،
اول ملائك عرش، کورسینی بیزه رهم انجله ر.

طاك صزلغانچه یورورلر ئه یتملچه هیچ بر کلام،
تیك دیورلر بارچه مؤمنگه- مسلمانغه سلام!

عبد الله توقای

۱۹۱۲ نچی سنه


Рамазан гаете мөбарәк булсын!
رمضان عیدی مبارك بولسون!

بسم الله الرحمن الرحيم

الله لا إله إلا هو الحي القيوم

# بسم الله

هر زمان سوز باشلانر بسم الله دن

هر وقت اش باشلانر بسم الله دن

## بسم الله الرحمن الرحيم

ياخشيلار بسم الله سز اش قيلماغان

اش تمام بسم الله سز هيچ بولماغان

مفتاح الدين آقوالا

لا تأخذه سنة ولا نوم له ما في السموات وما في الأرض من ذا الذي يشفع عنده إلا بإذنه

يعلم ما بين أيديهم وما خلفهم ولا يحيطون بشيء من علمه

إلا بما شاء وسع كرسيه السموات والأرض ولا يؤده حفظهما وهو العلي العظيم

كتب [illegible] نقاش

## ЭЧТӘЛЕК

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ
Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
*Иман китерү* . . . . . . . . . . . . . . 6
Шәһадәт сүзләре . . . . . . . . . . . . . 6
Иман китерү сүзләренең ачык мәгънәсе . . . . 6
Кәлимәи шәһадәткә инанганнан соң тиешле эшләр 8
Җир йөзенә адәм нәселенең килүе . . . . . . 9
Иманның тәфсилле аңлатмалары . . . . . . 14
Китап мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . 18
Нәсел-нәсәп мәсьәләсе . . . . . . . . . . 20
Кыйбла мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . 21
Мәзһәб мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . 21
Иманга ирешү мәсьәләсе . . . . . . . . . 24
Шәригать таләпләре буенча иманның шартлары . 25
Иманның төрләре мәсьәләсе . . . . . . . . 27
Иманның дәлилләре . . . . . . . . . . . . 27
Галәвият . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Сәфәлият . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Кешенең үзендә күренгән галәмәтләр . . . . 29
Иманның сыйфатлары . . . . . . . . . . . 29
Аллаһы тәгаләнең сыйфатларына әһеле сөннәт һәм җәмәгать гадәтенчә инану юлы . . . . . . . 38
Шәригать дәлилләре . . . . . . . . . . . 46
Балигълык яшенә җиткән бәндәләрнең гамәлләре 47
1. Фарыз . . . . . . . . . . . . . . . . 49
2. Важиб . . . . . . . . . . . . . . . . 51
3. Сөннәт . . . . . . . . . . . . . . . . 51
4. Мөстәхәб . . . . . . . . . . . . . . . 52
5. Мөбах . . . . . . . . . . . . . . . . 53
6. Хәрәм . . . . . . . . . . . . . . . . 53
7. Мәкруһ . . . . . . . . . . . . . . . . 54
8. Мөстәкрәһ . . . . . . . . . . . . . . 54
*Бишвакыт намазның тәртипләре* . . . . . . 55
Иртәнге намаз . . . . . . . . . . . . . . 55
Өйлә намазы . . . . . . . . . . . . . . . 56
Икенде намазы . . . . . . . . . . . . . . 57
Ахшам намазы . . . . . . . . . . . . . . 57
Йәсигъ (ястү) намазы . . . . . . . . . . . 57

Намазның шартлары . . . . . . . . . . . . . 59
Намазның беренче шарты — тәһарәт алу . . . . 60
Госелнең фарызлары 60
Госелнең сөннәтләре . . . . . . . . . . . . 61
Госелнең мәкруһлары . . . . . . . . . . . 62
Тәһарәт фарызлары . . . . . . . . . . . . 62
Тәһарәтнең сөннәтләре . . . . . . . . . . 63
Тәһарәтнең мәкруһлары . . . . . . . . . . 64
Читеккә мәсех итү . . . . . . . . . . . . . 64
Хәйз мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . 66
Хәйз хөкеме . . . . . . . . . . . . . . . 67
Тәһарәтнең бозылу очраклары . . . . . . . . 68
Тәһарәт тәртипләре һәм догалары . . . . . . 72
Тәйәммүм мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . 77
Намазның икенче шарты — нәҗасәттән тәһарәт . 80
Намазның өченче шарты — гаурәт җирләрне яшерү 83
Намазның дүртенче шарты — кыйбла . . . . . 84
Намазның бишенче шарты — вакытлар . . . . . 86
Намаз укуның мәкруһ булган вакытлары . . . . 87
Сәҗдәи тилавәт . . . . . . . . . . . . . . 87
Намаз кылу мәкруһ саналган биш вакытның калган икесе мәсьәләсе . . . . . . . . . . 89
Намазның алтынчы шарты — ният . . . . . . . 89
Намаз эчендә булган алты фарыз. Беренче фарыз 92
Намаз эчендәге икенче фарыз . . . . . . . . 93
Намаздагы өченче фарыз — Коръән уку . . . . . 94
Намаз эчендәге дүртенче фарыз — рөкүгъ . . . . 97
Намазның бишенче фарызы — сәҗдә . . . . . . 99
Намазның алтынчы фарызы — намаз тәмамланганнан соң бераз утырып тору . . . . 100
Намаздан чыгу мәсьәләләре . . . . . . . . . 102
Намазда хәрәкәттән тыелу мәсьәләсе . . . . . 103
Намазның важибләре, ягъни таләп ителгән тиешле эшләре . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Намазның сөннәтләре . . . . . . . . . . . 107
Азан шәрифнең укылу рәвеше . . . . . . . . 108
Намазның әдәпләре . . . . . . . . . . . . 116
Сәҗдәи сәһү яки намазларда ялгышлыклар хакында һәм аларны төзәтү . . . . . . . . 117
Намазны бозучы әйберләр . . . . . . . . . 119
Намазны үтәгәндә киңәш ителми торган, ягъни мәкруһ булган гамәлләр хакында . . . . . 124

Намазда тәһарәтнең бозылу очраклары хакында . 130
Намазда Коръәнне ялгыш уку мәсьәләсе . . . . 133
Мөсафирлар хакында . . . . . . . . . . . . 135
Каза мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . 137
Мәсҗид һәм җәмәгать . . . . . . . . . . . 140
Җомга намазы мәсьәләсе . . . . . . . . . . 141
Җеназа намазы . . . . . . . . . . . . . . 147
Гайд, ягъни Бәйрәм намазы . . . . . . . . . 153
Корбан мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . 156
Тәравих намазы хакында . . . . . . . . . . 162
Нәфел намазлары . . . . . . . . . . . . . 164
*Ислам диненең нигезләреннән өченчесе — рузә (ураза)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Фитра садакасы хакында . . . . . . . . . . 169
*Ислам диненең дүртенче нигезе — зәкәт* . . . . . 171
*Ислам диненең нигезләреннән бишенчесе — хаҗ* . . 176
Хатыннарның хаҗы һәм ирләрнең хаҗы арасында аермалар . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Зәмзәм суын эчү . . . . . . . . . . . . . . 182

ИСЛАМ ДИНЕНДӘ ЙОЛА ВӘ ӘДӘП

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Дөньяга килү . . . . . . . . . . . . . . . 186
Бәби туе . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Исем сайлау . . . . . . . . . . . . . . . 192
Йорт салу . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Урамда йөрү . . . . . . . . . . . . . . . 198
Юлга чыгу вә сәфәр . . . . . . . . . . . . 202
Никах . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Күршелек һәм күршеләр белән тору хакында . . 211
Тәүбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Бәлаләрдән саклану вә авырулардан дәва . . . . 217
Авыруларның вә түшәккә яткан кешеләрнең хәлен белешү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Дөнья белән саубуллашу, үлем, җеназа . . . . 222
Үлгәннәрне искә алу, каберләрен зиярәт кылу . . 229

ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ӘДӘП ВӘ ӘХЛАКЛАРЫ

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Хатын-кызларга карата шәфкатьле һәм дә яхшы мөнәсәбәттә булу хакында . . . . . . . . . 233
Хатын-кызларның кайбер гадәтләре вә йолалар, тәртипләр хакында . . . . . . . . . . . . . 237

ХӘРӘМНӘН САКЛАНУ ЯКИ ЭНҖЕЛӘР НУРЫ
Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Хәрәм-золым булган эшләр . . . . . . . . 249
Караклык . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Хыянәт . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Гайбәт . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Кешегә яла ягу һәм юк гаебен бар итеп сөйләү . 253
Сүз йөртү . . . . . . . . . . . . . . . 254
Ялган сөйләү . . . . . . . . . . . . . 255
Көнләшү, ягъни хәсәд . . . . . . . . . . 255
Хәрәм гайре золыми, золым булмаган хәрәмнәр хакында . . . . . . . . . . . . . . . . 258
Исерткеч эчүнең хәрәмлеге бәяне . . . . . . . 261
Никахның хәрәм булу очраклары . . . . . . 262
Зина кылуның хәрәмлеге хакында . . . . . . . 265
«ӘЛМӨЛЕК» СҮРӘСЕ («ТӘБАРӘК») . . . . . 268